Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ 6

Методик әсбап



Г. Н. Мөхәрләмова, Д. М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**6 нчы сыйныф**

Методик әсбап

Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
2024

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
М92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында эшләнде

**Мухарлямова Г. Н.**
М92 Родная (татарская) литература. Туган телдәге әдәбият. 6 класс. Методическое пособие : для преподавателей образовательных организаций основного общего образования, работающих с обучающимися, владеющими родным (татарским) языком / Г. Н. Мухарлямова, Д. М. Абдуллина. — Казань, 2024. — 138 б.

Методик әсбапта 6 нчы сыйныфта «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметыннан дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, предметны өйрәнүдә планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап урта сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024
© Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. 2024

# ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

Әлеге методик ярдәмлек дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максатыннан әзерләнде.

Әдәбият гуманитар фәннәр арасында шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсешенең дәрәҗәсен билгели торган төп предметларының берсе булып санала. Матур әдәбият күп функцияләргә ия һәм ул төрле чорларның иҗтимагый тормышын образлы формада тулы рәвештә чагылдыра ала. Икенче төрле әйткәндә, әдәбият сәнгать чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы сурәтен тудырып, аңа билгеле бер мөнәсәбәт булдырып, эмоциональ тәэсир итү көченә ия. Шуңа күрә әдәби әсәрне уку һәм өйрәнү әхлакый идеаллар турында күзаллауны, кешенең үзенә һәм дөньяга иҗтимагый һәм эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәтен формалаштыра һәм шул исәптән телне үзләштерүдә дә төп җирлек булып тора.

Әдәбият дәресләрендә шәхси үзүсеше өчен әдәбиятны өйрәнүнең әһәмиятен аңлый торган, үз фикерен дәлилләп җиткерә, фикерләрен телдән һәм язмача дөрес тәкъдим итә белә торган китап укучы тәрбияләнә. Алай гына да түгел, укучы дөньяны һәм бу дөньяда үзен танып белү өчен даими китап уку ихтыяҗы кирәклеген аңлый.

Мәктәптә әдәбият укытуның максаты шулай ук әдәби текстны эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әдәби әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдырудан гыйбарәт. Моннан тыш әдәби әсәрләр укучыларның телен баету, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда төп чыганак та булып тора.

Бүген мәктәптә сүз сәнгате яңа эчтәлектәге уку фәне — «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә. Бу туган (татар) телдәге әдәбият укытуның мөмкин-

лекләрен киңәйтте, ягъни әлеге предмет татар баласын туган телдәге әдәбиятка якынайта, сәнгатьнең бер төре булган әдәбият аша укучыны татар теле, тарихы, мәдәнияте, әхлагы, милли холык, милли кыйммәтләр белән таныштыра. Шуннан чыгып, аның максат-бурычлары да яңа нигездә корыла.

Бүген урта сыйныфларда төп эш — вакыт һәм сәнгатьнең төрләре арасындагы бәйләнешне күзәтү аша, әдәбиятның төр һәм жанрлары проблемасын карау. Аерым алганда, 6 нчы сыйныфта игътибар үзәгендә сүз сәнгатенең бер күренеше буларак образлылык, аның хасиятләре, образ төрләре, образлылыкның әдәби төр һәм жанрларда үзенчәлекле чагылышын тикшерү тора.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программаларында курсның эчтәлеге белән бергә планлаштырылган предмет нәтиҗәләр дә яңадан каралды. Аерым алганда, төп мәктәптә, ягъни урта сыйныфларда укучыларда формалаштырылырга тиешле предмет нәтиҗәләр әдәбият белән бәйле мәсьәләләрне киңрәк планда хәл итүгә йөз тота. Шул рәвешле, укучыларда Россия Федерациясендәге рус булмаган халыклар әдәбиятлары арасында туган телдәге әдәбиятның урынын һәм ролен, үзүсеш өчен әһәмиятен, сүз сәнгате буларак әдәбиятның образлы табигатен аңлау; әдәбият әсәрләрен эстетик кабул итү; эстетик зәвык формалашу; төрле стиль һәм жанрдагы текстларны укый белү; үз фикереңне дәлилләү, фикер алышуда катнашу; әдәби әсәр турында фикер алышканда элементар әдәби терминологияне белү; тематика, проблематика, образлар дәрәҗәсендә төрле халыкларның фольклор һәм сәнгать әсәрләре арасындагы бәйләнешләрне билгеләү (охшашлык һәм аерымлык принцибы буенча); сүзләрне эстетик функциясендә аңлау; әдәби әсәрне анализлау: аның әдәби төргә һәм жанрларга каравын билгели алу; темасын, идеясен аңлау; әдәби геройларга характеристика бирү, бер яисә берничә әсәр геройларын чагыштыру кебек предмет нәтиҗәләр алга чыгарыла.

Әдәбият дәресләрендә төп бурычларның берсе — укучыларны матур, төзек, төгәл, дөрес итеп сөйләргә өйрәтү. Бу, үз чиратында, әдәбиятны яхшырак, тирәнрәк аңлау-төшенүгә ачкыч ролен үти.

Укучыларны аралашу эшчәнлегенә тарту өчен әдәби әсәр текстларыннан файдаланабыз. Әдәби әсәрнең теле аларны әдәби телдә сөйләргә, телнең матурлыгын тояргa, байлыгын аңларга өйрәтүдә аеруча мөһим роль уйный. Шуны да истә тотарга кирәк: кешенең телдән һәм язмача сөйләм дәрәҗәсе аның фикер йөртү дәрәҗәсенә бәйле.

Мәктәптә әдәби белем бирү сөйләм үстерү белән бергә алып барыла. Сөйләм үстерү өчен махсус сәгатьләр бүленеп бирелә. Шул ук вакытта әдәбиятны өйрәнү барышында дәрестән дәрескә, һәрдаим бу эш башкарыла бара.

Әдәби әсәрне өйрәнү дәресендә сөйләм үстерү берничә төрле башкарыла ала. Әсәр белән танышу барышында, ягъни укучы әсәрне укыганда аның текстны аңлап укуы таләп ителә. Аңлау-аңламавын әсәр турындагы беренче тәэсирләрне уртаклашканда белеп була. Бу вакытта кыска гына җавапларга канәгать булып калмыйча, укучыларның фикерләре мөмкин кадәр тулы, төзек булуга ирешү сорала. Балаларның укыганны ни дәрәҗәдә аңлауларын әсәрнең эчтәлеген сөйләткәндә дә билгеләргә мөмкин. Эчтәлек сөйләү сөйләм телен үстерүдә әһәмиятле алым санала. Әсәрнең эчтәлеген сөйләү — укыганны яңадан хәтердә тергезеп, кабатлап сөйләү ул. Бу укучыга сөйләмен баетырга, эзлекле, матур һәм стилистик яктан дөрес итеп төзергә булыша. Бу алымны кулланып эшләгәндә эчтәлек сөйләүнең сюжетны кыскача сөйләү, аерым вакыйгаларның эчтәлеген сөйләү, кайбер өлешләргә мөнәсәбәт белдереп сөйләү, эчтәлекне иҗади сөйләү, текстка якын итеп сөйләү (эпик, лирик әсәрләрне өйрәнгәндә), планга нигезләнеп, аналитик, катлаулы, комментарийлар белән сөйләү кебек төрләрен кулланырга мөмкин. Эчтәлек сөйләгәндә текстта урын алган образлы гыйбарәләрне, аерым лексиканы, синтаксик конструкцияләрне кулланып сөйләү шарт булып тора. Шулай ук укучының хикәяләү эзлеклелеген, билгеле бер тәртипне, логиканы бозмавын таләп итәргә кирәк. Укучы текстның эчтәлеген эмоциональ итеп сөйләсә, тыңлаучыга ул сөйләгәннәрне аңлау җиңелрәк булачагын истә тотарга тиеш.

Балага эчтәлек сөйләү билгеле бер авырлыклар тудыра икән, план буенча, ягъни ачкыч (төп) моментларны билгеләп

сөйләтеп була. Сөйләгәндә текстны кыскартуны мөмкин кадәр чикләргә кирәк. Укучыга төп фикерләрне билгеләп, текстны җиңелдән катлаулыга таба, ягъни киңәйтеп сөйләргә өйрәтү мөһим.

Шунысы да әһәмиятле: укучының эчтәлекне механик рәвештә ятланган текст итеп түгел, ә бәлки җанлы сөйләвенә ирешү зарур. Шул ук вакытта эчтәлек сөйләгәндә авторның үрнәк стиле дә сакланырга тиеш. Укучыларның эчтәлек сөйләве дөрес сөйләм формалаштыра, әдәби зәвыкны, телне тоюны үстерә, аларда әхлакый-эстетик сыйфатлар формалаштыра.

Укучы сөйләргә башкаларны тыңлап өйрәнә. Шуңа күрә баланы сөйләмне тыңларга, кабул итәргә өйрәтү зарур. Монологик сөйләмдә иң әһәмиятлесе — мәгънә, эчтәлек. Телдән сөйләмне кабул итәргә өйрәтүне иң элек ишетеп аңлаудан башларга кирәк. Сөйләгәнне тыңлаган вакытта фактларны язып алу, план һәм тезислар төзү, конспектлаштыру һ.б. шундый эш төрләреннән файдалану яхшы нәтиҗә бирә.

Актив тыңлау алымнарына 5 нче сыйныфтан ук өйрәтә башлыйбыз. Мәсәлән, кереш дәрестә үк тактага укытучының сөйләмендә очрый торган аерым сүзләрне (ачкыч сүзләрне) язып куябыз. Бу сүзләр укучыга игътибарын төп моментларга юнәлтергә, укытучының зур булмаган лекциясен игътибар белән нәтиҗәле тыңларга мөмкинлек бирә. Алга таба 6 нчы сыйныфта ачкыч сүзләрне даталар белән катлауландырып бирергә мөмкин. Бу, үз чиратында, укучыларга укытучының сөйләвен яхшырак истә калдыру, хәтердә тергезеп, дөрес, төгәл итеп сөйләү мөмкинлеге бирәчәк. Укучылардан эчтәлек сөйләгәндә гади җөмләләр генә кулланып түгел, ә катлаулы җөмләләр дә кушып сөйләүләрен таләп итү сорала. Мондый сөйләү булганда образлы сөйләмгә игътибар итү зарур, төрле сурәтләү чараларын кулланып сөйләү, логик эзлеклекне саклау да — барысы да хикәяләүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итәчәк.

Әңгәмәдә (диалогта) катнашу алу осталыгы җавап бирә бирә белүдә чагылыш таба. Укучы дөрес, тулы, төгәл, җавап бирсен өчен укытучы һәрдаим аның җавабына игътибар бирергә тиеш. Кирәк булганда төзәтергә, ачыкларга, хупларга

да кирәк. Укучылардан кыска җавап түгел, ә киңәйтелгән җавап алуга ирешү мөһимлеген бик яхшы аңлыйбыз. Бу вакытта балаларның кыска җавапларын киңәйтелгән җаваплар белән чагыштырып күрсәтеп өйрәтү отышлы алым санала. Укучылар аерманы күрәләр, тулы җавап бирүнең мөһим булуын аңлыйлар һәм алга таба шул рәвешле тулы итеп җавап бирергә күнегәләр. Шулай ук сорау бирергә өйрәтү дә әһәмиятле. Моның өчен үзара аралашканда, әңгәмә корганда укучыларга бер-берсенә сорау бирү мөмкинлеген тәэмин итәргә кирәк.

Бәйләнешле сөйләм үстерүдә хикәя төзү, тасвирлап хикәяләү, рәсем-иллюстрацияләр, караган спектакль, кинофильмнар, укылган китап буенча сөйләү дә нәтиҗәле алым булып тора.

Алда әйтелгәннәр килеп туган каршылыкларны үтеп чыгарга, әдәбият фәнен укытуның нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итәчәк.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» УКУ ПРЕДМЕТЫННАН ФЕДЕРАЛЬ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

1. «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы (предмет өлкәсе — «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият») (алга таба — туган (татар) телдәге әдәбияттан программа, туган (татар) телдәге әдәбият, татар әдәбияты) туган (татар) телдә һәм рус телендә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) телдә сөйләшүче укучылар өчен эшләнде, һәм аңлатма язуын, уку-укыту эчтәлеген, туган (татар) телдәге әдәбияттан программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен үз эченә ала.

2. Аңлатма язуы туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең төп максатларын, уку планы структурасындагы урынын, шулай ук эчтәлекне сайлап алуга, планлаштырылган нәтиҗәләрне билгеләүгә юнәлешләрне чагылдыра.

3. Уку-укыту эчтәлеге төп гомуми белем дәрәҗәсендә һәр сыйныфта мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән эчтәлек юнәлешләрен ача.

4. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә барлык уку чоры өчен шәхескә бәйле, метапредмет нәтиҗәләрне, шулай ук һәр уку елы өчен предмет нәтиҗәләрне үз эченә ала.

5. Аңлатма язуы.

5.1. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программа укытучыга белем бирүдә заманча тенденцияләргә һәм актив укыту методикаларына юнәлдерелгән эш программасын булдыруда методик ярдәм күрсәтү максатыннан эшләнде.

5.2. «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгели торган гуманитар белем бирү юнәлешендәге төп предметларның берсе булып тора. Туган телдәге әдәбиятны өйрәнү тормышны танып белергә һәм чынбарлыкны модельләштерергә ярдәм итә, сүз-сурәт чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы картинасын булдыра һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт тудыра, югары дәрәҗәдәге эмоциональ тәэсиргә ия.

Әдәби белем укуның һәм әдәбиятны өйрәнүнең үзенең шәхси үсеше өчен әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилли һәм аны телдән һәм язма формада тәгъбир итә алган, шулай ук кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, дөньяны тану һәм үзен бу яшәештә күрә белү чарасы буларак системалы рәвештә укуга ихтыяҗы формалашкан укучы тәрбияләү белән бәйле.

5.3. 5—9 нчы сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү укучыларның татар әдәбияты әсәрләрен үзләштерүен, художестволы форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып шәрехләү һәм анализ күнекмәләрен үстерүне; милли үзаңны үстерү, этник чыгышны аңлау, системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыру үз халкының тарихы, теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе турындагы белемнәрне тәэмин итә.

5.4. Уку предметы гуманитар циклга караган башка уку предметлары белән, аеруча «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият» уку предметлары белән предметара бәйләнешләрне тәэмин итә.

5.5. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаның эчтәлегендә түбәндәге эчтәлек юнәлешләре аерып чыгарыла:

халык авыз иҗаты (әкиятләр (тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр), мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар, бәетлар; татар фольклоры 5—8 нче сыйныфларда тәкъдим ителә);

чорлар буенча татар әдәбияты (әдәби әсәрне мөстәкыйль сәнгать әсәре һәм катлаулы әдәби процессның бер чылбыры буларак карау; татар әдәбиятын аның үсеш этапларына туры китереп өйрәнү, Урта гасырлар, XVIII гасыр, XIX—XX гасырлар әдәбиятларыннан башлап хәзерге татар әдәбиятына кадәр; туган телдәге әдәбиятта тарихи вакыйгаларның чагылышын күзәтү, тарихи барышта татар әдәбиятының роле турында күзаллауларны киңәйтү);

әдәбият теориясе (конкрет әдәби әсәрләрне өйрәнү процессында теоретик-әдәби төшенчәләрне үзләштерү: вакыт һәм сәнгать формалары арасындагы өзелмәс бәйләнешне күзәтү процессында әдәбият төрләре һәм жанрлары проблемасын карау, 5 нче сыйныфта аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма үзенчәлекләре өйрәнелә, 6 нчы сыйныфта лирик әсәрләрдә, хикәядә һәм повестьта, лиро-эпик әсәрләрдә, драма әсәрләрендә, шулай ук фантастик, автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала, 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма, лирик һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен беләләр), 8 нче сыйныфта өйрәнү объекты булып әдәби алымнар (пейзаж, портрет, символ, нәфис деталь һәм башкалар) тора, 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты тарихы өйрәнелә.

5.6. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

туган мәдәниятнең мөһим өлеше буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләү;

укучыларны үз халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә якынайту;

үзбелем чарасы буларак үз уку эшчәнлеген куллана алган грамоталы укучы формалаштыру.

5.7. Программаны гамәлгә ашыруның куелган максатларына ирешү туган (татар) телдәге әдәбият буенча түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүне күздә тота:

әдәби текстка комментарийлар бирү, анализлау һәм шәрехләү күнекмәләрен үстерү;

укучыларны әдәбият белемендәге анализлау элементларын кертү, аерым теоретик-әдәби төшенчәләр белән таныштыру аша сүз сәнгате буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка якынайту;

татар әдәбиятының барышы белән танышу һәм аның тарихи барыш белән бәйләнешенә төшенү;

укучыларның коммуникатив күнекмәләрен (татар телендә сөйләм һәм язма диалогик һәм монологик сөйләмнәрен) үстерү;

уку күзаллауларын формалаштыру;

укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру;

укучыларның туган (татар) телдә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү;

гомум уку күнекмәләрен һәм универсаль уку гамәлләрен үзләштерү.

5.8. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләрнең гомуми саны — 170 сәгать: 5 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 6 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 7 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 8 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 9 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать).

7. 6 нчы сыйныфта уку-укыту эчтәлеге.

7.1. Гимн. Россия гимны. Татарстан гимны.

7.2. Халык авыз иҗаты.

7.2.1. Татар халык җырлары.

Татар халык җырлары, аларны классификацияләү (лирик җырлар, тарихи җырлар, уен һәм йола җырлары, такмаклар). Халык җырларының поэтик үзенчәлекләре, образлар һәм аларны иҗат итү үзенчәлекләре. Җырның кешеләр тормышындагы урыны.

Җырлар: «Иске кара урман», «Гөлҗамал», «Татарстан кызлары».

7.3. Татар әдәбияты.

7.3.1. Лирик әсәрдә образ. Лирик геройның хис-кичерешләрен чагылдыру чаралары.

Р. Рәкыйпов, «Мин яратам сине, Татарстан». Туган ил образы. Туган җиргә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре.

Г. Тукай, «Туган авыл». Кеше тормышында туган як. Туган авыл образы, туган як табигате.

Ф. Яруллин, «Туган ягы кирәк кешегә». Лирик геройның туган иленә югары хисләре.

Р. Вәлиева, «Гүзәл җирем».

Дәрдмәнд, «Кил, өйрән». Туган телнең кеше тормышындагы роле. Башка телләрне өйрәнүнең әһәмиятен аңлау. Туган телнең чисталыгы өчен көрәш.

Р. Фәйзуллин, «Туган тел турында бер шигырь».

Р. Фәйзуллин, «Гадиләргә гимн». Тормыш мәгънәсе һәм кешенең җәмгыятьтәге урыны. Хезмәт кешесенә хөрмәт хисе.

Ф. Яруллин, «Сез иң гүзәл кеше икәнсез». Әдәбиятта укытучы образы. Лирик геройның аңа мөнәсәбәте.

Ф. Кәрим, «Ватаным өчен». Әсәрдәге патриотизм. Ватанны саклаучы образы. «Сибәли дә, сибәли». Табигать күренешләре, аларның образны иҗат итүдәге роле, психологизмның көчәюе.

Л. Лерон, «Фашист очып үтте». Сугыш чоры күренешләре. Трагизм. Дошман образы.

Ш. Галиев, «Пәрәмәч». Лирик әсәрдә комиклык тудыру алымнары.

Х. Такташ, Пи-би-би-бип («Әй, җырлыйсы килә шушы җырны»). Кече Ватан образы. Үткәнне, бәхетле балачакны сагыну.

7.3.2. Фантастик әсәрләрдә образлар системасы.

К. Насыйри «Әбүгалисина». Ибн Сина образы. Повестьның фантастик сюжеты. Әсәрдә мәгърифәтчелек идеяләре. Яхшылык һәм явызлык чагылышы. Җәмгыятькә изге ниятләргә хезмәт итә торган белем кирәклеге идеясе. Әсәр композициясендә антитезаның роле.

7.3.3. Аллегорик образлылык.

Г. Рәхим. «Яз әкиятләре». Шартлылык һәм аллегорик образлылык.

И. Гази. «Кояш артыннан киткән тургай».

7.3.4. Автобиографик әсәрләрдә образлар системасы.

Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (автобиографик әсәрдән өзек). Кечкенә Тукай образы. Әдәби герой хатирәләренең шартлылыгы.

7.3.5. Биографик әсәрләрдә образлар системасы.

Биографик әсәр. Жанр хасиятләре. Ә. Фәйзи. «Тукай» (өзекләр). Романда шагыйрь образы. Тукайның язмышы.

7.3.6. Хикәя һәм повесть жанрларында образлылык.

Г. Ибраһимов. «Алмачуар». Хикәядә образлар системасы. Әсәр героеның атка мәхәббәте. Әдәби геройларның характерларын ачуда психологизмның роле. Татар авылы образы. Татар авылының әхлакый нигезләре.

Ә. Еники. «Матурлык». Кешенең рухи матурлыгы. Ана белән улы арасындагы мәхәббәт хисе. Бәдертдин образы.

Р. Мөхәммәдиев. «Беренче умырзая». Табигать образы. Табигатькә сакчыл караш. Буыннар бәйләнеше. Ниятләрнең изгелеге.

М. Галиев. «Җиңәсем килде». Намус, гаделлек һәм хөрмәт төшенчәләре.

7.3.7. Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы.

М. Җәлил. «Сандугач һәм чишмә». Совет солдатының батырлыгын данлау. Табигать образлары. Баллада жанры.

7.3.8. Драма әсәрләрендә образлар системасының үзенчәлекләре.

Г. Камал. «Беренче театр». Әсәрдә конфликтның көлкеле характеры. Комик образларны тудыру алымнары. Комедиядә мәгърифәтчелек идеяләре.

7.4. Әдәбият теориясе.

Гимн, җыр, автор образы, метафора, инверсия, идея, проблема, шигырь төзелеше, ритм, рифма, шигырь, строфа, фантастик образ, антитеза, гипербола, аллегория, автобиографик әсәр, комедия, характер, тип, критик реализм, баллада.

# ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү баскычында «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметын өйрәнү укучыларда түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне формалаштырачак:

1) ***гражданлык тәрбиясе:***

гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү, гаилә, белем бирү оешмасы, җирле берләшмә, туган як, туган ил тормышында актив катнашу, шул исәптән әдәби әсәрләрдә чагылдырылган вакыйгалар белән чагыштыру аша да;

экстремизм, дискриминациянең теләсә кайсы формаларын кабул итмәү, кеше тормышында төрле иҗтимагый институтларның ролен аңлау, гражданның төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын, күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә шәхесара мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый нормаларын һәм кагыйдәләрен күзаллау, шул исәптән туган (татар) телдәге әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да; мәктәп үзидарәсендә актив катнашу, гуманитар эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***2) патриотик тәрбия:***

татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, туган телне (татар телен) һәм туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну;

Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү;

Россия символларын, дәүләт бәйрәмнәрен, тарихи, табигый мирасны һәм һәйкәлләрне, илебездә яшәүче төрле халы-

кларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү, аларның татар әдәбиятында чагылдырылуына игътибар бирү;

***3) рухи-әхлакый тәрбия:***

әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү;

үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен, аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу;

җәмгыятьтә кабул ителмәгән гамәлләрне тулысынча кире кагу, шәхси һәм иҗтимагый киңлек шартларында шәхес иреге һәм җаваплылык;

***4) эстетик тәрбия:***

үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау;

аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау;

Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау;

сәнгатьнең төрле төрләрендә үзеңне чагылдырырга омтылыш;

***5) физик тәрбия, сәламәтлек һәм эмоциональ иминлек культурасын формалаштыру:***

тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау, үз сәламәтлегенә җаваплы карау һәм сәламәт яшәү рәвеше (сәламәт туклану, гигиена кагыйдәләрен үтәү, дөрес оештырылган эш һәм ял режимы, даими физик активлык) алып бару;

начар гадәтләрнең (спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллану, тәмәке тарту) һәм физик-психик сәламәтлеккә башка зыян салу формаларын аңлау һәм кире кагу, шул исәптән интернет-мохиттә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү:

стресслы ситуацияләргә, үзгәрүчән социаль, информацион һәм табигать шартларына җайлашу, шул исәптән үз

тәҗрибәсеннән чыгып һәм алга таба максатлар да куеп, үзеңне һәм башкаларны битәрләми кабул итә белү сәләтенә ия булу;

әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы, рефлексия күнекмәсе формалашкан булу, әдәби геройларның гамәлләрен бәяләү аша үзеңнең, башкаларның хаталану хокукы булуын тану;

***6) хезмәт тәрбиясе:***

технологик һәм социаль юнәлештәге практик мәсьәләләрне (гаилә, мәктәп, шәһәр, төбәк кысаларында) хәл итүдә актив катнашу максатын кую, мондый эшчәнлекне башлап җибәрү, планлаштыру һәм мөстәкыйль башкара алу сәләтенә ия булу;

өйрәнелгән предмет белемнәрен куллануга һәм әдәби әсәрләрдә геройларның эшчәнлеге белән танышуга да нигезләнеп, һөнәрләрне һәм хезмәт төрләрен гамәли яктан өйрәнү белән кызыксыну;

уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү;

һөнәри мохиткә яраклаша белү; хезмәтне һәм хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен хөрмәт итү, шул исәптән татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрен өйрәнгәндә дә, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне, ихтыяҗларны исәпкә алып, белем алуның һәм тормыш планнарының индивидуаль траекториясен аңлы рәвештә сайлау һәм төзү;

***7) экологик тәрбия:***

иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү;

экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау;

экологик проблемалар күтәрелгән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу;

табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау, экологик юнәлештәге практик эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***8) фәнни танып белү кыйммәтләре:***

үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек;

дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу;

әдәби белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләрен үзләштерү, тәҗрибә, күзәтү, эш-гамәлләрне аңлауга юнәлгәнлек һәм шәхси, коллектив иминлеккә ирешү юлларын камилләштерү омтылышына ия булу;

***9) укучының үзгәрүчән социаль һәм табигый мохит шартларына яраклашуын тәэмин итү:***

укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне, төркемнәрдә һәм җәмгыятьтә, шул исәптән гаиләдә, һөнәри эшчәнлек буенча оештырылган төркемнәрдә һәм берләшмәләрдә, шулай ук башка мәдәни мохит кешеләре белән үзара социаль бәйләнеш кысаларында иҗтимагый тормыш формаларын үзләштерүе, әдәби әсәр персонажларының социаль рольләрен өйрәнүе һәм бәяләве;

билгесезлек шартларында үзара бәйләнештә эш итә белү, тәҗрибә тупларга һәм башкаларның белемнәренә таянырга әзер тору, билгесезлек шартларында эш итү сәләтенә ия булу, гамәли эшчәнлек аша үзенең компетентлык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән башка кешеләрдән өйрәнә алу, уртак эшчәнлектә башкаларның тәҗрибәсеннән яңа белем, күнекмә һәм компетенцияләргә төшенү;

образларны ачыклау һәм үзара бәйләү күнекмәсе, яңа белемнәр формалаштыру сәләте, билгеле булган һәм моңа кадәр билгесез объектлар һәм күренешләр турында идеяләр, төшенчәләр, гипотезалар тәгъбирләү, үзендә белем һәм ком-

петенцияләрнең җитенкерәмәвен аңлау, үз үсешен планлаштыру;

тотрыклы үсеш концепциясе өлкәсендә төп төшенчәләр, терминнар һәм күзаллаулар белән эш итә белү;

табигать, җәмгыять һәм икътисадның үзара бәйләнешләрен анализлый һәм ачыклый алу;

әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне, максатларга ирешү һәм мөмкин булган каршылыкларны җиңүне, глобаль нәтиҗәләрне исәпкә алып, үз гамәлләрен бәяли алу;

стресслы ситуацияне аңлый, тормыш һәм укучы тәҗрибәсенә таянып, дөньяда бара торган үзгәрешләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бәяли алу, стресслы ситуацияне кире кагарлык чара күрелергә тиешле чакыру буларак кабул итү, стресслы ситуацияне бәяләү, кабул ителгән карарларны һәм гамәлләрне үзгәртү, килеп туган куркынычларны һәм аларның нәтиҗәләрен тәгъбирләү һәм бәяли алу, моның төрле юлларын эзләү, билгеле бер ситуациянең уңай ягын таба белү, уңышка ышаныч булмаганда да эшләргә әзер тору.

11.2. Төп гомуми белем дәрәҗәсендә туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә укучыда танып белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре, регулятив универсаль уку гамәлләре, уртак эшчәнлек осталыгы формалаштырылачак.

11.2.1. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге төп логик гамәлләр формалаштырылачак:

объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү;

классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, үткәрелгән анализ критерийларын билгеләү;

тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, аларны ачыклау өчен, критерийлар тәкъдим итү;

куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау;

әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, дедуктив һәм индуктив фикерләүне, охшашлык буенча фикерләүне кулланып нәтиҗәләр чыгару, аларның үзара бәйләнешләре турында гипотезалар тәгъбирләү;

текстларның төрле төрләре белән эшләү барышында уку мәсьәләсен чишү ысулын мөстәкыйль сайлау (чишелешнең берничә вариантын чагыштыру, мөстәкыйль билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, иң кулаен табу).

11.2.2. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак укучыда түбәндәге төп тикшеренү гамәлләре формалаштырылачак:

әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану;

ситуациянең, объектның реаль һәм кирәкле халәте арасындагы аерманы теркәргә ярдәм иткән сорауларны тәгъбирләү, нәрсәнең бирелгәнлеген, ә нәрсәне эзләп табарга кирәклеген мөстәкыйль билгеләү;

үз һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү;

әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү;

тикшеренү (эксперимент) барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү;

үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; алынган нәтиҗәләрнең һәм гомумиләштерүләрнең ышанычлылыгын бәяләү коралларына ия булу;

вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау, шулай ук аларның яңа шартларда һәм контекстларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә дә үсеше турында фаразлар тәкъдим итү.

11.2.3. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда мәгълүмат белән эш итүнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

чыганаклардан тәкъдим ителгән уку бурычын һәм, бирелгән критерийларны исәпкә алып, әдәби һәм башка төр мәгълүматны эзләү һәм сайлау барышында төрле инструментлар, ысуллар һәм табу алымнарыннан файдалану;

төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү;

төрле мәгълүмат чыганакларында (бер үк идеяне, версияне раслаучы яки кире кагучы) охшаш аргументлар табу;

әдәби һәм башка төр мәгълүматны тәкъдим итүнең оптималь формасын мөстәкыйль рәвештә сайлау һәм гади схемалар, диаграммалар, башка график һәм аларның комбинацияләре ярдәмендә чишелергә тиешле уку мәсьәләләрен тасвирлап бирү;

әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү;

мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру.

11.2.4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге коммуникатив күнекмәләр формалаштырылачак:

фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үзеңне (үз фикереңне) телдән һәм язма текстларда белдерү;

аралашуның вербаль булмаган чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын белү һәм тану, әдәби әсәрләрдә охшашлыклар табып, конфликтлы ситуацияләрне көйләү, сөйләшүләр алып бару;

башка кешеләрнең ниятләрен аңлау, әңгәмәдәшкә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү һәм үзеңнең килешмәгәнлегеңне әдәп белән тәгъбир итү, уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү;

уку мәсьәләсен хәл итүгә юнәлдерелгән идеяләрне җиткерү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау; үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау;

үткәрелгән тәҗрибә (әдәби эксперимент, тикшеренү, проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү;

презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

11.2.5. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге үз-үзеңне оештыру күнекмәләре формалаштырылачак:

матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау;

карарлар кабул итүдә төрле алымнарга (индивидуаль, төркемдә карар кабул итү, төркем тарафыннан карарлар кабул итү) юнәлеш тоту;

уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, булган ресурсларны һәм үз мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку мәсьәләсен чишү ысулын сайлау, тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын дәлилләү;

эш-гамәлләр планын (билгеләнгән чишү алгоритмын гамәлгә ашыру планын) төзү, һәм өйрәнелә торган әдәби объект турында яңа белемнәр алуны исәпкә алып, тәкъдим ителгән алгоритмны үзгәртү;

сайлау һәм карар чыгаруда җаваплылыкны үз өстеңә алу.

11.2.6. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда үз-үзеңне контрольдә тоту, эмоциональ интеллект, үзеңне кабул итү һәм башкаларны тануда түбәндәге күнекмәләр формалаштырылачак:

әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү;

уку ситуациясенә тиешле бәя бирү һәм аны үзгәртү планын тәкъдим итү;

контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру;

эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү;

яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү;

башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү;

хисләрнең сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау;

үз хисләрен белдерү ысулын көйләү;

әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау;

хаталанырга хокукыңны һәм башкаларның да шундый ук хокукын тану;

үзеңне һәм башкаларны гаепләмичә кабул итү;

үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу;

тирә-юньдәге бар нәрсәне контрольдә тота алмауны аңлау.

11.2.7. Укучыда уртак эшчәнлекнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау;

бергәләп уку эшчәнлегенең максатын аңлау, аңа ирешүдә күмәк рәвештә гамәлләр булдыру: рольләрне бүлү, килешүләр төзү, бергәләп эшләү барышы һәм аның нәтиҗәсе турында фикер алышу;

берничә кешенең фикерен гомумиләштерә белү, җитәкчелек итүгә, йөкләмәләрне үтәүгә, буйсынуга әзерлек күрсәтү;

туган (татар) телдәге әдәбият дәресендә бергәләп эшне оештыруны планлаштыру, үз ролен билгеләү (аралашуда катнашучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып), команда әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирү, төркем эшендә (сөйләшү, фикер алышу, «аң штурмы» һәм башкалар) катнашу;

эштә үз өлешеңне башкару, үз юнәлешең буенча сыйфатлы нәтиҗәгә ирешү һәм үз гамәлләреңне команданың башка әгъзалары белән координацияләү;

әдәбият дәресләрендә катнашучылар тарафыннан тәгъбир ителгән критерийларга таянып, гомуми нәтиҗәгә керткән өлешеңнең сыйфатын бәяләү;

нәтиҗәләрне башта куелган бурыч һәм һәр команда әгъзасының нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлеше белән чагыштыру, җаваплылык өлкәсе белән уртаклашу һәм төркем алдында хисап бирергә әзерлек күрсәтү.

11.3. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең предмет нәтиҗәләре.

6 нчы сыйныфны тәмамлаганда укучы:

*татар телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программа тарафыннан билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның өлешләрен яттан сөйләргә;

укыган әсәрләрнең темасын, төп фикерен, проблемасын билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әдәби геройны характерларга, аны авторның тасвирламасы һәм сәнгатьле детальләр нигезендә телдән сурәтләргә, бер әсәрнең персонажларын охшашлык һәм аерма яклары буенча чагыштырырга;

укылганнар, шул исәптән язучының тормыш юлы һәм иҗаты буенча мәгълүматтан файдаланып, әңгәмәдә катнашырга;

үз карашын формалаштырырга һәм башкалар фикерен аңларга;

эчтәлек сөйләү төрләреннән файдаланып, әдәби текстның эчтәлеген сөйләргә (тәфсилле, кыскартып, сайлап, иҗади);

әдәби әсәрнең гади планын төзергә, шул исәптән өземтәләрдән файдаланып;

әдәби әсәрне шәрехләргә;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (автор образы, проблема, характер, тип, метафора, гипербола һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

шәхси кичерешләргә нигезләнеп, картина, тәкъдим ителгән әдәби тематика (бер әсәрне кулланып) буенча инша язарга.

*рус телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнәчәк:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программа тарафыннан билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның өлешләрен яттан сөйләргә;

укыган әсәрләрнең темасын, төп фикерен, проблемасын билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әдәби геройны характерларга, аны авторның тасвирламасы һәм сәнгатьле детальләр нигезендә телдән сурәтләргә, бер әсәрнең персонажларын охшашлык һәм аерма яклары буенча чагыштырырга;

үз карашын тәгъбир итәргә һәм башкаларның фикерләрен аңларга;

эчтәлек сөйләүнең төрләреннән файдаланып, әдәби текстның эчтәлеген сөйләргә (тәфсилле, кыскартып, сайлап, иҗади);

әдәби әсәрнең гади планын төзергә, шул исәптән өземтәләрдән файдаланып;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (автор образы, проблема, характер, тип, метафора, гипербола һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

шәхси кичерешләргә нигезләнеп, картина, тәкъдим ителгән тематика буенча инша язарга.

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

## 6 класс — 34 сәгать
## (рус телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |
| | | **Кереш** | | |
| 1 | Гимн (1 сәгать) | Гимн. Россия гимны, Татарстан гимны. | 1 | Дәреслек белән танышу, аның белән эшләү тәртибен үзләштерү.<br>Гимннарның текстларын тыңлау һәм уку.<br>Уку: интонация белдерү чараларын сайлау һәм куллану |
| | | **Татар халык авыз иҗаты** | | |
| 2 | Татар халык җырлары (3 сәгать) | Җыр — моң да, тарих та ул (Татар халык җырлары, аларны классификацияләү. «Татар халык җыры «Иске кара урман») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәре тексты белән эшләү: укыган җыр текстларының эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, халык җырларына хас сәнгать алымнарын ачыклау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Җыр — халкыбызның рухи юлдашы (Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре. Татар халык җыры «Гөлҗамал») | 1 | Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау, җыр жанрының үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, эшне башкару, чыгыш ясау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | «Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» (Проект эшен яклау) | 1 | |
| | **Татар әдәбияты** | | | |
| 3 | Лирик әсәрдә образ тудыру алымнары (11 сәгать) | Иң изге хис — туган җиргә (Лирик әсәрдә образ. Р. Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан») | 1 | Уку: шигырьнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, үз карашын булдыру һәм башкалар әйткән фикерләрнең мәгънәләрен аңлау.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текcттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. Тематикасы буенча якын шигырьләрне чагыштыру. |
| | | Тау башына салынгандыр безнең авыл (Г. Тукай. «Туган авыл») | 1 | |
| | | Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз илаһи бит, изге (Дәрдмәнд. «Кил, өйрән» Р. Фәйзуллин. «Туган тел турында бер шигырь») | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Укытучы — һәркемнең юлдашы, һәр эшнең юл башы (Ф. Яруллин. «Сез иң гүзәл кеше икәнсез») | 1 | Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эше: картина буенча инша язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Контроль эш / Тест | 1 | |
| | | Фашизмның яшәргә хакы юк (Л. Лерон. «Фашист очып үтте») | 1 | |
| | | «Фашист самолёты очып үтте» (Иҗади эш: А. Пластовның «Пролетел фашистский самолёт» («Фашист самолёты очып үтте») картинасы буенча инша) | 2 | |
| | | Бәлеш нинди хисне белдерә? (Ш. Галиев. «Пәрәмәч») | 1 | |
| | | Иң матур хатирә, иң якты хис (Һ. Такташ. «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны») | 1 | |
| | | Үткән теманы кабатлау. | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Фантастик әсәрләрдә образлар системасы (3 сәгать) | Иң зур хезмәт — үз халкыңа хезмәт (К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. К. Насыйри. «Әбүгалисина») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Виртуаль экскурсиядә катнашу |
| | | Хыял дөньясы чынбарлыкка якынмы? (Фантастик әсәрләрдә образлар системасы. К. Насыйри. «Әбүгалисина») | 1 | |
| | | Әгәр мин тылсымчы булсам... (К. Насыйриның «Әбүгалисина» повестенда Әбүгалисина образы) | 1 | |
| 5 | Аллегорик образлылык (1 сәгать) | Кояшны капларлык ялган (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. Г. Рәхим. «Яз әкиятләре») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Виртуаль экскурсиядә катнашу |
| 6 | Автобиографик әсәрләрдә образлар системасы үзенчәлекләре (3 сәгать) | Үзем турында үзем (Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. |
| | | Иң авыр һәм иң кадерле мизгелләр (Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Үткән теманы кабатлау.<br>Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый (Иҗади эш: Л. Фәттаховның «Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый» картинасы буенча сөйләм үстерү) | 1 | Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәр героена бәя бирү, сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерү чараларын сайлау һәм куллану, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү.<br>Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү.<br>Хикәяләү: телдән сурәт тудыру.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| 7 | Хикәя һәм повесть жанрларында образлылык (7 сәгать) | Бер мәхәббәтнең тарихы (Г. Ибраһимованың тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Ибраһимов. «Алмачуар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әсәр героена бәя: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр ярдәмендә геройның портретын телдән тудыру, анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Хикәяләү: телдән сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм). |
| | | Максатыңа ирешү бәхетле итәме? (Хикәя жанрында образлар системасы. Г. Ибраһимов. «Алмачуар») | 1 | |
| | | Матурлык — рухи халәт ул (Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Хисләрнең дә үз йөзе, үз төс бар (Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Мәңгелек агышында Чишмә һәм Умырзая (Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестенда образлар системасы) | 1 | |
| | | Туган җирдә яшәү — зур бәхет (Р. Мөхәммәдиев. «Беренче умырзая») | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 8 | Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы (1 сәгать) | Батырлык кечкенә булмый (Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы.<br>М. Җәлил. «Сандугач һәм чишмә») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү, балладада хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре (3 сәгать) | Сәхнә — тормышның көзгесе (Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре. Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү: анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Иҗади эш: инша язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Биби көләме, көлдерәме? (Көлкеле образлар тудыру алымнары. Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | |
| | | Яңалык каршылык тудыра (Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | |
| 10 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Нәтиҗәләр чыгару. Контроль эш. | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Үтелгәннәрне гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

## 6 класс — 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Кереш** | | | | |
| 1 | Гимн (1 сәгать) | Гимн. Россия гимны, Татарстан гимны. | 1 | Дәреслек белән танышу, аның белән эшләү тәртибен үзләштерү.<br>Гимннарның текстларын тыңлау һәм уку.<br>Уку: интонация белдерү чараларын сайлау һәм куллану |
| **Татар халык авыз иҗаты** | | | | |
| 2 | Татар халык җырлары (3 сәгать) | Җыр — моң да, тарих та ул (Татар халык җырлары, аларны классификацияләү. Татар халык җыры «Иске кара урман») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укыган җыр текстларының эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, халык җырларына хас булган сәнгать алымнарын ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау, җыр жанрының үзенчәлекләрен билгеләү. |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Җыр — халкыбызның рухи юлдашы (Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре. «Гөлҗамал», «Татарстан кызлары») | 1 | Проект эше: проект эшен башкару өчен материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, эшне башкару, чыгыш ясау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | «Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» (Проект эшен яклау) | 1 | |
| **Татар әдәбияты** | | | | |
| 3 | Лирик әсәрдә образ тудыру алымнары (10 сәгать) | Иң изге хис — туган җиргә (Лирик әсәрдә образ. Р. Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан») | 1 | Уку: шигырьнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, үз карашын булдыру һәм башкалар әйткән фикерләрнең мәгънәләрен аңлау.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек |
| | | Тау башына салынгандыр безнең авыл (Г. Тукай. «Туган авыл») | 1 | |
| | | Туган җирнең төсе нинди? (Ф. Яруллин. «Туган ягы кирәк кешегә», Р. Вәлиева. «Гүзәл җирем») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз илаһи бит, изге (Дәрдмәнд. «Кил, өйрән», Р. Фәйзуллин. «Туган тел турында бер шигырь») | 1 | чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. Тематикасы буенча якын шигырьләрне чагыштыру. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Иҗади эше: картина буенча инша язу. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү. Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Гимнга лаек һөнәрләр (Р. Фәйзуллин. «Гадиләргә гимн») | 1 | |
| | | Укытучы — һәркемнең юлдашы, һәр эшнең юл башы (Ф. Яруллин. «Сез иң гүзәл кеше икәнсез») | 1 | |
| | | Дәһшәтле утка керәмен... (Ф. Кәрим. «Ватаным өчен», «Сибәли дә сибәли») | 1 | |
| | | Фашизмның яшәргә хакы юк (Л. Лерон. «Фашист очып үтте»; иҗади эш: А. Пластовның «Пролетел фашистский самолёт» («Фашист самолёты очып үтте») картинасы буенча инша) | 1 | |
| | | Бәлеш нинди хисне белдерә? (Ш. Галиев. «Пәрәмәч») | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Иң матур хатирә, иң якты хис (Һ. Такташ. «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны») | 1 | |
| 4 | Фантастик әсәрләрдә образлар системасы (2 сәгать) | Иң зур хезмәт — үз халкыңа хезмәт (К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. К. Насыйри. «Әбүгалисина») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Виртуаль экскурсиядә катнашу |
| | | Хыял дөньясы чынбарлыкка якынмы? (Фантастик әсәрләрдә образлар системасы. К. Насыйри. «Әбүгалисина») | 1 | |
| 5 | Аллегорик образлылык (2 сәгать) | Кояшны капларлык ялган (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. Г. Рәхим. «Яз әкиятләре») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Виртуаль экскурсиядә катнашу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Нык ихтыярга көчләр буйсына (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. И. Гази. «Кояш артыннан киткән тургай») | 1 | |
| 6 | Автобиографик әсәрләрдә образлар системасы үзенчәлекләре (3 сәгать) | Үзем турында үзем (Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәр героена бәя бирү, сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерү чараларын сайлау һәм куллану, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү.<br>Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү.<br>Хикәяләү: телдән сурәт тудыру. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Иң авыр һәм иң кадерле мизгелләр (Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Үткән теманы кабатлау.<br>Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый (Иҗади эш: Л. Фәттаховның «Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый» картинасы буенча сөйләм үстерү) | 1 | |
| 7 | Биографик әсәрләрдә образлар системасы (2 сәгать) | Шул вакытта мин китап алам (Ә. Фәйзинең «Тукай» романында образлылык тудыру чаралары) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру.<br>Укылган әсәр проблемасын формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: кыскача һәм җентекләп сөйләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Текст буенча сораулар төзү |
| | | Җырлап торам, торган җирем тар булса да (Ә. Фәйзи. «Тукай») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Хикәя һәм повесть жанрларында образлылык (7 сәгать) | Бер мәхәббәтнең тарихы (Г. Ибраһимованың тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Ибраһимов. «Алмачуар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әсәр героена бәя: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр ярдәмендә телдән геройның портретын тудыру, анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Хикәяләү: телдән сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм).<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Максатыңа ирешү бәхетле итәме? (Хикәя жанрында образлар системасы. Г. Ибраһимов. «Алмачуар») | 1 | |
| | | Матурлык — рухи халәт ул (Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | |
| | | Хисләрнең дә үз йөзе, үз төс бар (Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | |
| | | Намусыңны яшьтән үк сакла (М. Галиев. «Җиңәсем килде») | 1 | |
| | | Мәңгелек агышында Чишмә һәм Умырзая (Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестенда образлар системасы) | 1 | |
| | | Туган җирдә яшәү — зур бәхет (Р. Мөхәммәдиев. «Беренче умырзая»)<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы (1 сәгать) | Батырлык кечкенә булмый (Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы.<br>М. Җәлил. «Сандугач һәм чишмә») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, балладада хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү |
| 10 | Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре (2 сәгать) | Сәхнә — тормышның көзгесе (Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре.<br>Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү:<br>анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Биби көләме, көлдерәме? (Көлкеле образлар тудыру алымнары. Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Иҗади эш: инша язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 11 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Нәтиҗәләр чыгару. Контроль эш. | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Үтелгәннәрне гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

6 нчы сыйныфта туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүгә тәкъдим ителә торган дәреслек төп гомуми белем бирү өчен яңартылган Федераль белем бирү стандартына туры китереп һәм федераль эш программаларына нигезләнеп эшләнде.

Дәреслекнең төзелеше, материалның күләме, фәнне өйрәнү өчен кирәкле төшенчәләр белән таныштыру яңа калыпка салынды. Дәреслектәге материал телне бик аз белгән укучыдан алып югары әзерлекле укучының дә ихтыяҗын канәгатьләндерә ала. Икенче төрле әйткәндә, дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус) күздә тотып төзелгән, төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материалар аерып бирелә. Татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен алар өстәмә рәвештә дәреслекнең чите буйлап график сурәт (пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Ике дәрәҗәгә аерып бирү әсәр ахырыннан соң урнаштырылган сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба. Телне белү һәм әдәби үсеш дәрәҗәләрен исәпкә алып, татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен әдәбият материалда чагыштырмача күләмлерәк тәкъдим ителә.

Укытучы өчен методик әсбапта предметны тирәнтен өйрәнү буенча киңәшләр, аерым темалар зәңгәр төс белән билгеләнә.

Дәреслектә тәкъдим ителгән сорау һәм биремнәр, укучыларда билгеләрне аерып чыгару максаты белән, объектларны анализлау, синтезлау — өлешләрдән бөтен төзү, объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын сайлау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, фикер йөртүнең логик чылбырын төзү, фикерләрне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән һәм язма формада төзү кебек универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга йөз тота. Дәреслектәге биремнәр артык кыенлыклар тудырмыйча әсәрнең эчтәлеген, хасиятләрен белү, геройларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешенә игътибар итү белән бәйле. Татар телендә белем бирә торган мәктәпләрдә укучылар өчен сораулар бераз катлаулырак, укучыларның иҗади сәләтләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне төшенүгә юнәлтелгән булачак. Тексттан

соң бирелгән сүзлекчәдә таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта — урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә.

Әдәбият дәресләрендә халыкның матди һәм рухи кыйммәтләре белән танышу аша буыннан буынга тапшырыла торган тарихи, мәдәни, әхлакый һәм эстетик тәҗрибәне актив үзләштерү алып барыла. Шул рәвешле, әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнгән вакытта укучыларда туган телдәге әдәбиятны милли мәдәниятнең бер өлеше буларак аңлау белән бәйле мәдәният белеме компетенциясе формалаша. Этномәдәни материал яңа УМКларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең барлык этапларында да тәкъдим ителә, моны дәреслекләрнең эчтәлегендә дә ачык күреп була. Мәсәлән, укучылар әдәби-тарихи материал белән танышкан вакытта, комментарий-аңлатмалар, шул исәптән теге яки бу вакыйга, мәдәни объект, күренеш яки төшенчә турында тарихи мәгълүматлар да бирелә. Бу укучыларның танып белү кызыксынуларын арттыруга, шул исәптән татар халкының мәдәнияте, тарихы турында белемнәрне киңәйтергә ярдәм итә. Моннан тыш, биредә милли мәдәниятнең халык тарихы белән генә түгел, ә гомумән ил тарихы белән дә үзара бәйләнеше күзәтелә.

Дәреслектә милли-мәдәни һәм тарихи характердагы комментарийлар әдәби әсәрләрне уку барышында бирелеп бара. Әдәби текстта очрый торган теге яки бу сәбәпләр аркасында укучыларга таныш булмаган аерым сүзләр, милли-мәдәни компонентлы төшенчәләр әлеге рубрикада чагылыш таба. Сүз, беренче чиратта, архаизмнар, тарихи сүзләр, татар халкының һәм гомумән Россиянең ерак үткәнендә булган төшенчәләр һәм күренешләр турында бара. Комментарийлар укучыларны төрле сәнгать төрләре әсәрләре белән таныштыру максатыннан да тәкъдим ителә. Милли-мәдәни компонент дәреслектәге иллюстрацияләрдә сурәтләнгән киемдә, бизәнү әйберләрендә, көнкүрештә, йортларның бизәлешендә, интерьерда чагылыш тапкан.

Дәреслектә сүз белән эшләү максатыннан әдәби текстларда очраган фразеологизмнарга, канатлы сүзләргә, образлы гыйбарәләргә аңлатма махсус рубрикада бирелә.

Шулай ук дәреслектә урын алган «Бу кызыклы», «Файдалы фикер» рубрикалары белән танышу укучыларның дөньяга карашларын, белемнәрен киңәйтә.

«Шәхесләребез» рубрикасында татар халкы тарихы, сәнгате, әдәбияты өлкәсенә зур өлеш керткән шәхесләребез турында кыска гына, гомуми күзәтү ясала. Дәреслектә программа өйрәнүне күздә тоткан аерым язучыларыбызның тормыш юлы һәм иҗатын киңрәк яктыртуга урын бирелә. (Укучыларны таныштыру максатыннан, төрле чорда яшәгән күренекле шәхесләребезнең биографиясенә бәйле фотоархив белән белән https://photo.miras.info/№ сылтамасы буенча кереп танышырга мөмкин).

Дәреслек заман укучысына гына түгел, заман укытучысына да яраклаштырылды. Дәреслекнең тулы электрон варианты, видеодәресләр, өстәмә материалны табу һәм куллану өчен чыганаклар һәм методик ярдәмлек тә шуңа хезмәт итә. Дәреслекнең электрон вариантында, төп материал белән беррәттән, һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Текст белән эшләгәндә электрон дәреслектәге аудиоязмаларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 6 нчы сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры килә һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты — укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда укучының уку материалын мөстәкыйль үзләштерүе барышында да файдаланырга мөмкин булачак. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә дә аларны уңышлы кулланып була.

Әлеге видеодәресләр һәм шулай ук туган (татар) телдәге әдәбиятны уку-укыту барышында кулланыла торган норматив документлар, федераль эш программалары, дәреслекләрнең электрон вариантлары, методик әсбаплар, медиамате-

риаллар, татар балалар әдәбияты антологиясе белән «Мәгърифәт» медиаплатформасында (https://magrifat.antat.ru) танышып була.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ[1]

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә. Методик әсбапта тәкъдим ителгән дәрес үрнәкләрендәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомуми һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, ул үзе теләгәнчә эшли ала. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема:** Гимн. Россия гимны. Татарстан гимны.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — Россия символларын хөрмәт итү, Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Россия һәм Татарстан гимннарының сүзләрен белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Ка-

[1] Кайбер дәрес үрнәкләре берләштереп тәкъдим ителә.

зан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—7.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес кереш сүздән башланып итә. Дәреслектә авторларның укучыларга мөрәҗәгате бирелгән. Шулар белән таныштырганнан соң, «Гимн. Россия гимны, Татарстан гимны» темасын өйрәнүгә күчәбез.

Дәрес башында әңгәмә оештырабыз:

*Укучылар, безнең Ватаныбыз ничек атала? Ул нәрсәләр белән данлыклы?*

*Кече Ватаныбыз турында нәрсәләр әйтә аласыз?*

*Илебезнең кайсы дәүләт атрибутларын күрсәтә алабыз?*

*Гимн нәрсә ул, беләсезме? Россия гимнының сүзләре белән сез танышмы?*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләнгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектә Россия һәм Татарстан гимннары текстлары бирелә. Аларны иң элек аудиоязмадан тыңласак (Россия гимнын рус һәм татар телләрендә), уңышлырак була. Укучылар гимн яңгыраганда аягүрә торып басарга тиешлеген аңлыйлар. Гимн төшенчәсен аңлату максаты белән, аның турында мәгълүмат биреп китәбез.

Алга таба һәр ике гимнның эчтәлеге буенча эш башкарыла. Укучылар аларда нәрсә турында сүз баруын ачыклыйлар. Бу вакытта дәреслектә бирелгән сорау-биремнәр ярдәмгә килер.

Россия, Татарстан гимннарының авторлары турында мәгълүмат бирү сорала. Бу вакытта дәреслектәге материалны тулыландырып сөйләргә мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Музыкаль язмага кушылып, гимнны җырлатырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Гимннарның сүзләрен ятларга. Дәреслектә бирелгән QR-код аша гимннарның текстларын тыңларга тәкъдим итәргә була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җыр — моң да, тарих та ул (Татар халык җырлары, аларны классификацияләү. Татар халык җыры «Иске кара урман»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татарларның бай мираска ия халык булуын аңлау; татар җырына, моңына карата уңай мөнәсәбәт һәм соклану хисе туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — татар халык җырлары турында төшенчә алу, аларның төрләрен белү, татар халык җыры «Иске кара урман»ның эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 8—11.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Татар халык җырын тыңлатабыз (ирекле сайлана).

3. Дәрес башында бирелгән *Җыр ничек туа? Аны кем иҗат итә?* кебек проблемалы сораулар биреп була, алар укучыларны проблемалы әңгәмәгә тартып, теманы өйрәнүгә юнәлеш була ала. Бу вакытта сораулар (*Укучылар, ничек уйлыйсыз, автор һәм халык җыры арасында нинди аерма бар? Халык җыры ничек языла? Ни өчен халык җырлары төрле вариантта җырлана? Ни өчен халык җыры искерми?*) биреп һәм халык җырларын тыңлап, үзенчәлекләрен аерырга өйрәнгәч, сез бу сорауларга җавап табарсыз, дип, теманы өйрәнүгә кызыксыну уятабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге зур тема татар халык җырларын өйрәнүгә багышлана. Моның өчен «Иске кара урман», «Гөлҗамал», татар телендә белем бирү мәктәпләрендә «Татарстан кызлары» җырларының текстлары алынды. Әлеге җырларның структурасы, эчтәлеге, жанр үзенчәлеге, образлар системасы, тел-сурәтләү чаралары тикшерелә. Шушы җырларны өйрәнү нәтиҗәсендә, укучылар халык җырларына аңлатма бирүгә, аларның поэтик үзенчәлекләрен билгеләүгә, тематик яктан җырларның төрләрен аера белүгә, кеше тормышында җырның әһәмиятен аңлауга ирешәләр. Нәтиҗәдә, укучы мөстәкыйль рәвештә халык җырының поэтик һәм структур үзенчәлекләрен тикшереп, проект эше башкара, җырларга иллюстрация ясый алачак.

Теманы өйрәнүне түбәндәгечә оештыра алабыз:

Бүген җыр иҗат итүче җырны кәгазьгә я аудиоязмага яза һәм автор буларак җырны үз исеменә терки. Әби-бабайлар нинди шартларда җыр иҗат иткәннәр икән? Әйе, укучы-

лар, борынгы заманнарда әби-бабайларның барысына да белем алу насыйп булмый. Татар халкы гомер-гомергә җир эшкәртү, игенчелек, терлекчелек кебек авыр хезмәт белән шөгыльләнә. Ул табигать белән тыгыз мөнәсәбәттә яши. Элек авылларда язу танучылар санаулы була. Шуның өстенә фикер, уйларыңны, күңелдә туган иҗади әсәрләрне кәгазьгә төшерү өчен, һәр өйдә кәгазь һәм язу карасы да булмый. Элек каләм урынына сыек язу карасы кулланганнар. Аның белән язганда бик пөхтә, игътибарлы булырга һәм ашыкмыйча эш итәргә кирәк. Татар тарихында бик күп сугышлар булган, су транспорты яки ат белән, ерак юллар кичеп, чит илләргә йөрүчеләр дә күп булган. Болар халык җырлары туууга алшарт булып торгандыр. Ерак сәфәрләргә чыгып, юлда барганда, канкойгыч сугышларда, авыр хезмәт башкарганда күңелдә моң туган, сагыш-борчудан җыр барлыкка килгән. Җырны кешеләр бер-берсенә җырлаганнар, шул рәвешле ул таралган, һәркем аны төрлечә үзгәрткән, я үзенчә исендә калдырган.

Халык җырлары — халык иҗат иткән, телдән телгә күчеп таралган, һәркем үзгәртеп җырлый ала торган көйдән һәм шигъри сүзләрдән торган музыкаль әсәр. Аларда халыкның хис-кичерешләре, авыр язмышы, үткәне, бүгенгесе өчен сызлану, туган җирне сагыну, сөйгән ярга мәхәббәт хисе белдерелә.

Татар халык җыры «Иске кара урман» белән таныштырабыз. Бу урында видеодәрес материалын уңышлы кулланырга мөмкин. Анда Илһам Шакиров башкаруында әлеге җырның видеоязмасы урнаштырылган. Алга таба текстны укучылар үзләре укыйлар.

Әсәрне анализлау барышында түбәндәге сорауларны бирә алабыз: *Иске кара урман җыры» нәрсә турында? Анда нәрсәләр турында әйтелә*? дигән сорауга җавап биргәндә, укучылар авыр тормышта дусларның, якын кешеләрнең кирәк булуы, ялгыз башыңа авыр булуы турында җырлануын, аның дус-ишләрдән аерылмыйча, бергәләп яшәргә чакыруын билгелиләр.

*Дуслар кайсы вакытта кирәк, диелә җырда?* дигән сорауга укучылар *дуслар дөнья көтәргә кирәк,* дип, җыр сүзләре

белән җавап бирәчәкләр. Бу урында дөнья көтү турында төшенчә биреп китсәк, яхшы була.

Җырны тыңлаганда нинди хисләр тууын ачыклап, иң элек укучыларның моңсулануларын әйттерәбез. Укучылар урманның каралыгы, караңгы төн, кара елан һәм лирик геройның шул урманда ялгыз йөрүе күңелдә курку, шомлану хисе уятты, ә дустына эндәшеп, *аерылмаек, дускаем,* дигәндә, җырда җылылык, яктылык сизелде, дияргә мөмкиннәр.

Җыр тексты белән эшләгәндә, образларны барлап, аларның нинди мәгънә ачыклавын да билгеләтергә кирәк. Бу вакытта укучылар «Иске кара урман» җырында кара урман, караңгы төн, кара елан, пар каен, пар усак, яхшы ат кебек табигать образлары кулланылганлыгын күрәчәкләр. Без, ярдәмгә килеп, кара урман — татар халкының авыр тормышы, караңгы төн — билгесез киләчәк, пар каен, усак агачлары — дус-иш, яхшы ат якын дус мәгънәләрендә килүен әйтәбез. Төп мәгънә табигать образларына яшереп бирелгәндә, ул җырны тагын да серле, уйландыргыч итә, күңел халәтен тирәнрәк ачарга ярдәм итә, дип нәтиҗә ясыйбыз.

Дәреслектә татар мәктәпләре өчен бирелгән материал өлешендә җырда *Лирик геройның урманга кергәндә пар каен һәм пар усак кисеп алуы нәрсәне аңлата*? дигән сорау бирелә, аңа укучылар дус-иш, иптәш кирәк булуны аңлата, дип җавап бирәләр.

Татар мәктәпләрендә *Җыр ни өчен яхшыга өмет, ышаныч белән тәмамлана*? дигән сорау биреп, укучыларны фикерләшүгә алып чыгабыз.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта дәреслектә «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасында бирелгән карурман, кара урман символик образы турында мәгълүмат нигезендә әңгәмә оештырып була.

«Кара урман» төшенчәсе халык иҗатында еш очрый. Кара төс татар фольклорында начарлык, сынау, авырлык, кайгы мәгънәләрен ачыклый. «Иске кара урман» җырында кара төс берничә тапкыр кабатлана. *Игътибар ит, ул нинди сүзләр белән янәшә кулланыла*? соравын биреп, *Кара урман,*

*караңгы төн, кара елан сүзләре белән кулланыла*, дигән җавап алачакбыз.

**V. Өй эше бирү.**

«Иске кара урман» җырын укырга, сорауларга җавап бирергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җыр — халкыбызның рухи юлдашы (Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре. «Гөлҗамал», «Татарстан кызлары»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар халкының бай мираска ия халык булуын аңлау; татар халкының үткәненә, хәзергесенә хөрмәт хисе уяну, Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — җырлар турында мәгълүматлы булу; «Гөлҗамал», «Татарстан кызлары» җырларының эчтәлеген белү, идеяләрен аңлау.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 12—16.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә үткән материалны искә төшерү. «Иске кара урман» җыры турында сорауларга җавап бирү.

2. Укучылар белән кешеләрнең элек ничек күңел ачулары турында әңгәмә үткәрергә мөмкин. Элек-электән кызлар, җыелышып, кич утыра торган булганнар. Алар анда төрле кул эшләре белән шөгыльләнгәннәр, җырлаганнар, серләшкәннәр. Татар яшьләре ялын оештыруның борынгыдан килгән төре — аулак өйләргә тукталып, биредә халык җырларының да башкарылуы турында сөйләшеп була. Бу вакытта күрсәтмәлелек тә кулланылса, тагын да яхшырак.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәрдән чыгып, дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Гөлҗамал» җырын өйрәнү аны тыңлау, уку һәм анализлауны күздә тота. Укучыларның җырдан алган беренче тәэсирләре дөрес формалашсын өчен, әлеге җырның язмасын Интернеттан табып тыңлатырга була.

Җырны тыңлаганнан соң, укучылар кызлар өчен борчылу, сагышлануларын әйтә, кызларның билгесез киләчәк өчен сызланулары, аларның авыр тойгысы күңелгә үтте, дип җавап бирергә мөмкин.

*Җыр нәрсә турында?* дип сораганда, укучылар «Гөлҗамал» җыры кызларның авыр язмышы, аларның билгесез киләчәк өчен борчылулары турында, дип җавап бирәчәк. Бу урында кызлар *нинди егеткә барырбыз* дип пышылдашалар, моның үзенең ризалыгыннан башка гына кызны кияүгә бирү гадәтенә ишарә булуын аңлату зарур. Пышылдап кына сөйләшүләрен, аларның сабыр, тыйнак булу кебек сыйфатлары белән бәйләргә кирәк. Биредә тыйнаклык сыйфатының асылын аңлатуга юнәлеш биргән әңгәмә оештырырга мөмкин.

Кызларның киндер җеп эрләү белән шөгыльләнүләренә игътибар иттереп, бу эшнең асылын аңлатып китү файдалы булачак. Шулай ук бирнәлек, сөйгәненә кульяулык чигүнең мәгънәсен аңлату отышлы булачак.

Шәмдәлләрдә янган утларның кызларның өметен чагылдыруын ачыклап китәбез.

Дәреслектә тәкъдим ителгән 3 нче сорауда элеккеге заман кызлары белән бүгенге кызларны чагыштыру сорала. Бу вакытта дәреслектәге иллюстрациягә дә игътибар иттерү файдалы булачак.

Дәреслектә җыр текстыннан соң бирелгән сораулар калган башка якларны да ачыклап бетерергә мөмкинлек бирәчәк.

Татар мәктәбендә «Татарстан кызлары» җыры өйрәнелә. Моның инде чагыштырмача яшь халык җыр булуын ассызыкларга кирәк. Бу очракта дәреслектә бирелгән 1 нче сорау һәм шуңа мөнәсәбәтле «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасында Татарстан Республикасы турында мәгълүмат ярдәмгә килер.

Укучылар җыр тексты белән танышкач, аның нәрсә турында булуын билгеләп, җырда тырыш, җитез, өлгер, чибәр кызлар сурәтләнүен, аларның бер эштән дә курыкмаулары, батыр, көчле булулары ачыклана.

«Татарстан кызлары» җырын тыңлагач туган хисләрне билгеләткәндә, кызларга карап соклану, аларның уңган, тырыш, чибәр булулары һәм хезмәтләренең орден һәм медальләр белән бәяләнүе шатлык, горурлык хисләре уятуга басым ясыйбыз. «Татарстан кызлары» җырында, кызларны сурәтләгәндә, аларның нинди сыйфатларына басым ясалуын ачыклатып була.

Җырдагы аерым образларга, детальләргә, күренешләргә, аларның мәгънәләренә игътибар юнәлтү дә мөһим. Әйтик, яз җиткәч, Иделдә бозлар киткәч, колхоз кырларында эшләр гөрли, техниканы эшкә җигәләр, кыр өстендә сары күбәләкләр уйный, диелә. *Ничек уйлыйсың, җырда күбәләк образы нәрсәне аңлата?* дигән сорау биреп, кырда тормыш кайнау турында сүз баруын ачыклап була. *Иделдә боз китү нәрсәне аңлата?* дигән сорауга укучылар *Яз җитә, кырда эшләр башлана,* дип җавап бирәчәк.

Дәреслектә бирелгән «Татарстан кызлары» — халыкның шактые укый-яза белгән чорда иҗат ителгән җыр. *Ничек уйлыйсың, ул ни өчен халык авыз иҗаты әсәре булып киткән?* дигән проблемалы сорауга җавапны бергәләшеп эзлибез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта татар халык җырларының төрләрен карап үтәргә мөмкин. Дәресләрдә үтелгән җырларны искә төшереп, аларның төп үзенчәлекләрен билгеләтеп, кайсы төргә каравын ачыклатып була. Бу вакытта укытучыга түбәндәге мәгълүмат ярдәмгә киләчәк.

Халык җырларын, башкарылу стиленә һәм эчтәлегенә карап, лирик, тарихи, уен-йола җырларына һәм такмакларга бүләләр. Лирик җырлар халыкның күңел халәтен, хис-кичерешләрен, борчу-сагышларын, рухи дөньясын ача. Бу төр җырларда халыкның авыр язмышы, туган як, читтә бәхет эзләү, дуслык-туганлык, мәхәббәт, татар хатын-кызының катлаулы тормышы кебек темалар яктыртыла. Лирик геройның күңел дөньясын ачу өчен табигать образлары кулланыла. Лирик җырларны озын салмак көйгә дә, тиз ритмлы күңелле көйләргә дә башкаралар.

Халык җырларында халыкның үткәне, авыр язмышы сурәтләнә. Илдәге хәл, иҗтимагый-сәяси, тарихи вакыйгалар фольклорга да үтеп керә. Тарихи җырларда ил, халык язмышында эз калдырган зур тарихи вакыйгалар, халык бәхете өчен көрәшүче онытылмас шәхесләр яктыртыла. Тарихи даталар, билгеле кешеләрнең кылган батырлыклары, онытылмас вакыйгалар җырда лирик геройның хис-кичереше белән үреп бирелә. Бу җырларда вакыйга да, хис тә бар.

Татарлар электән үк җор, үткен, чая телле була. Кич утырганда алар еш кына кара-каршы такмак әйтешкәннәр. Такмаклар биегән вакытта, күңел ачканда җырлап яисә тиз ритмда әйтелә. Элек такмаклар үзенә күрә уен коралы, гармун вазифасын үтәгән. Такмакның нигезендә дустыңнан аерылып көлү, аны үчекләү, шаяру кебек көлкеле вакыйгалар ята. Әлеге материал дәреслектә бирелгәннәргә өстәмә булып бара ала.

Мисалга дәрестә өйрәнелгән җырны алып, шуның нигезендә билгеле бер төрнең үзенчәлекләрен күзәтергә мөмкин. Әйтик, «Гөлҗамал»ны лирик җырларга кертеп карыйлар, дип, анда лирик җырга хас билгеләрне табып әйтергә кушабыз. Укучылар «Гөлҗамал» җырында кызларның җыелышып кич утырулары, кул эшләре белән шөгыльләнүләре, эч серләре белән бүлешүләре яктыртылуын билгелиләр. Кызлар сөйгән ярлары булмаганга, билгесез киләчәкләрен уйлап, кемгә кияүгә чыгарбыз инде дип борчылалар, сагыш-моңнары белән уртаклашалар. Җырда күңел халәте, лирик уйланулар һәм хис-кичерешләр сурәтләнүен билгелиләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Төркемнәргә бүленеп, татар халык җырлары буенча тикшеренү үткәреп, аны «Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» темасына 9—10 битлек проект эше әзерләп килергә кушабыз. Аны сыйныфташлары алдында якларга әзерләнергә кирәклеген әйтәбез (бу эшне алдагы дәресләрдә үк биреп куеп була).

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: «Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» (Проект эшен яклау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — җырның кеше тормышындагы ролен аңлау, татар халык җырларының үзенчәлегенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; үткәрелгән проект нәти-

җәләрен башкалар алдында тәкъдим итү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — җыр турында алган белемнәрне гомумиләштерү.

**Материал: Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 8—16.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Моң төшенчәсе, татар моңы турында сөйләшү үткәреп була. Моңа бәйле Габдулла Тукайның милли көй турындагы шигырь юллары белән таныштырабыз.

*Ишеттем мин кичә: берәү җырлый*
*Чын безнеңчә матур, милли көй;*
*Башка килә уйлар төрле-төрле, —*
*Әллә нинди зарлы-моңлы көй.*

*Татар җырына моң хас. Нәрсә ул моң? Бу төшенчәне аңлатып кара. Бәлки сиңа моңсу, моңлану дигән кебек сүзләр ярдәмгә килер.*

Укучылар әлеге сорауга җавап бирә алмасалар, укытучы сөйли. Моң сүзе татар җырларына мөнәсәбәтле кулланыла. Ул моңсуланганда, күңел сагыш белән тулгандагы халәткә туры килгән җырларга карата әйтелә.

Мисалга «Иске кара урман» җырын китерергә мөмкин. *Әлеге җырда моңсулану-сагышлану нинди сүзләр, җөмләләр ярдәмендә белдерелә?* дигән сорауга укучылар «Иске кара урман» җырында *кошлар сайраган чакта, бигрәк моңсу шул чакта; заманалар авыр, юллар ябык; ялгыз башым, юк юлдашым кебек юлларда* лирик геройның моңсулануы, сагышлануы чагылыш таба, дип җавап бирәләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучыларга әлеге дәрестә җыр турында алган белемнәрне кабатлап гомумиләштерү турында җиткерелә, әзерләп килгән проектларны якларга тәкъдим ителә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Әлеге этапта укучылар «Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» проектларын яклыйлар. Алар аны индивидуаль яки төркемләп башкара алалар.

Дәрес ахырында фольклорчы галим, татар җырларын махсус өйрәнгән Ким Миңнуллинның җыр турындагы (дәреслектә дә бирелгән) фикере белән таныштырабыз.

Алга таба *«Бүген җырлар күпләп иҗат ителә, аларның авторлары мәгълүм. Ни өчен хәзер халык җырлары язылмый диярлек?* дип, проблемалы сорау биреп, сыйныфта фикер алышу үткәреп була. Укучылар хәзерге заманда җырлар иҗат иткән шагыйрь, композитор, җырчыларның авторлык хокуклары алуларын, аларның рөхсәте булмаса, җырчыларның ул җырны башкара алмавын, шуңа күрә дә бүгенге көндә халык җырлары туып тормавын аңларга тиешләр.

**V. Өй эше бирү.**

Җыр турында алган белемнәрне кабатларга.

**VI. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Иң изге хис — туган җиргә (Лирик әсәрдә образ. Роберт Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — кече Ватаныбыз Татарстанга, татар халкына, аның тарихына, танылган шәхесләренә карата уңай мөнәсәбәт һәм алар белән горурлану хисе булу, Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан» шигыренең эчтәлеген белү, идеясен билгеләү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 17—20.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Иң элек, *Ни өчен кеше тормышында туган җир мөһим урын тота?* дигән проблемалы сорауны куеп, укучыларны уйландырабыз, фикерләрен әйттерәбез.

Алдагы нәтиҗәне ясыйбыз. Кеше дөньяга килгән урын аның туган җире була. Туган җир төшенчәсе дә кеше белән бергә үсә һәм байый бара. Син сабый чакта ул туган йорт булса, аннары туган авыл, туган республика, өлкә һәм Ватан буларак күз алдына килә башлый. Әмма тәүге адымнар ясалган, күбәләкләр күреп сокланган, йолдызларга карап хыялланган, җанга якын авазлары белән хәтергә уелып калган урын гел үзенә тартып торачак. Зур Ватаныңның гаме белән янып, аның белән горурланып яшәгәндә сагыну дигән искиткеч татлы да, газаплы да бер хис сине гомер буе озата барачак. Туган җирне сагыну өчен хәтта читкә китәргә дә

киpәкмидер. Кыш көне язлары, ә җәй көне кышның бураннары сагындыра. Кеше рухы, тамырлары белән туган җиренә береккән. Тамырлары өзелгән гөлләр дә, мәһабәт агачлар да корый. Рухи тамырлары туган җирдән аерылганнар да корыган гөл кебек (сөйләгәндә слайдларда Татарстан турында иллюстрация-рәсемнәр күрсәтеп барырга мөмкин).

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә туган җир турында сүз барачагын фаразлыйлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу дәрестә лирик әсәрдә образлылыкны өйрәнүгә багышланган яңа теманы башлап җибәрәбез. Тема башында *Хис образ була аламы?* дигән проблемалы сорауга игътибар юнәлтеп, аны өйрәнеп бетергәндә, бу сорауга җавап алачагыбызны әйтәбез. Иң элек, образның нәрсә аңлатканын искә төшерәбез. Бу вакытта 5 нче сыйныфта алган белемнәребезне искә төшерәбез. Шулай ук бу урында хис төшенчәсен аңлатып китү сорала.

Роберт Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан» шигыре һәм тирәнтен өйрәнүчеләргә Габдулла Тукайның «Туган авыл», Фәнис Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә», Разил Вәлиевнең «Ватаным», Резеда Вәлиеваның «Гүзәл җирем» шигырьләре аша лирик әсәрләрдә туган җир образын гәүдәләндерүдә, лирик геройның туган җиренә булган хисләрен белдерүдә кулланылган сурәтләү чаралары карала, ягъни тематик яктан охшаш әсәрләрдә образ тудыруның үзенчәлекләре өйрәнелә. Аларның эчтәлеге нигезендә укучылар лирик әсәрнең темасын, идеясен ачыклыйлар, лирик герой һәм автор төшенчәләрен аерырга өйрәнәләр. Лирик әсәрләрдә образлылык, сурәтләү чараларының вазифасын күзәтәләр. Яңа төшенчә буларак инверсия, гипербола белән танышалар. Нәтиҗәдә лирик әсәрдә тема, идея һәм образлар системасындагы бөтенлекне анализларга өйрәнәләр, лирик герой хисләрен гәүдәләндергән тел-сурәтләү чараларын аңлатып бирә алалар.

Р. Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан» шигырен өйрәнә башлаганчы, әсәрнең исеменә нигезләнеп, аның нәрсә

турында булуын билгеләтергә мөмкин. Укучылар шигырьне беренче тапкыр укытучы укуында-сөйләвендә тыңлыйлар. Аннан соң җыр рәвешендә бирелгән вариантны аудиозмадан тыңлатырга кирәк. Бу урында видеодәрес материалын да кулланырга мөмкин.

*Шигырьдә Татарстан турында нәрсәләр әйтелә?* дип, укучыларның шигырьдән алган беренче тәэсирләрен белешәбез.

Шигырьдә чагылган хисләрне, аларның сәбәпләрен строфалап ачыклатабыз.

Р. Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан» шигырендә табигать матурлыгы, аның горур халкы, татар теле, батыр һәм талантлы кешеләре Татарстанны яратуның сәбәпләре буларак атала. Болар арасында матди байлыклар юк. *Ни өчен шагыйрь Кеше һәм рухи байлыкларны төп кыйммәт дип саный икән*? дигән проблемалы сорау биреп, укучыларны фикерләүгә этәрәбез. Алар шигырьдә авторның Татарстанны ярату сәбәпләрен туган җирнең матурлыгында, туган җирдәге халык, туган тел, халыкның данын билгеләүче шәхесләрдә күрүен, табигать кешенең рухын баетучы чыганак булып күзаллануын, рухи яктан бай, горур, ата-баба мирасына, телгә, гореф-гадәтләргә хөрмәт саклаган халык туган җир бизәге була алуын, рухы бай кешеләр матди байлык тудыруда да алдынгылыкны бирмәвен билгеләргә тиеш булалар.

Алга таба шигырьдә яңгыраган идеягә тукталып, автор әйтергә теләгән фикерне ачыкларга кирәк.

Шигырьдә лирик «мин» Татарстанны яратуын, аның берән горурлануын сөйли. *Шигырьне укыганда син бу хисләрне үзеңнеке итеп кабул итәсеңме?* дип, укучыларны лирик герой, «лирик мин» төшенчәсен аңлауга китерәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Шигырьдә Тукайларың, Сәйдәшләрең, Җәлилләрең дигән исемнәр телгә алына. Син бу шәхесләрне беләсеңме?* дип,

укучыларны Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев, Муса Җәлилләрнең кем булуы турында әңгәмәгә алып чыгабыз.

Тагын бер эш төре буларак, укучыларның Татарстанны ни өчен яратуларын әйттереп, шагыйрьнең фикерен дәвам итәргә кушып була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне яттан өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Тау башына салынгандыр безнең авыл (Г. Тукай. «Туган авыл»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — Габдулла Тукайның «Туган авыл» шигыре аша туган ягыбызга карата ярату хисләре, гражданлык хисләре формалашу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару, гомумиләштерүләр ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Габдулла Тукайның «Туган авыл» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген күрсәтә алу.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 20—23.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Шигырьнең эчтәлеге буенча сөйләшү.

2. Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган бер урын була. Безнең өчен ул — туган ягыбыз. Туган ягын, авылын, шәһәрен яратмаган кеше юктыр, дип башлап, туган як турында әңгәмә үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә туган җир турында сүз барачагын фаразлыйлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Габдулла Тукайның «Туган авыл» шигырен өйрәнүне аны укудан башлыйбыз. Татарстанның атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов башкаруында аудиоязма тыңлатырга мөмкин. Укып чыкканнан соң, укучыларның беренче тәэсирләрен сорашканда, аны тыңлаганда нинди күренешләр күз алдына килүен, нинди тавышлар ишетелүен, нинди хисләр кичерүләрен ачыклыйбыз.

Хисләрне һәм аларның сәбәпләрен строфалап билгеләтәбез. Өстенлек иткән хисне ачыклыйбыз.

Лирик геройның үзенең туган авылында нинди төп эшләрне башкаруын күзәтеп, укучылар аның укуын, Коръән өйрәнүен, җир сукалавын билгелиләр. Мөселманнарның изге китабы Коръән турында аңлатып китү сорала, дәреслектә бирелгән мәгълүмат ярдәмгә килә ала.

Нәни Тукайның кайсы авылда яшәве турында сүз баруын ачыкларга кирәк булачак. Бу шигырьдә сүз Кушлавыч авылы турында бара, чөнки шигырьдә *Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган*, диелә. Дәреслектәге «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасында бу авыл турында мәгълүмат та бирелә, аның белән таныштырабыз.

Шигырьдә әйтелгән төп фикерне кеше һәм аның туган җиренең аерылгысыз, бербөтенне тәшкил итүен, аның туган яктан башка яши алмавы белән бәйлибез. Укучылар туган илне яратырга, хөрмәт итәргә һәм сакларга кирәклеген аңлыйлар.

Бу дәрестә шулай ук инверсия турында төшенчә бирү дә каралган. Белемнәрне ныгытып, шигырьдә инверсиягә мисаллар таптырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Туган авыл» җырын (А. Монасыйпов көе) тыңлатырга, дәреслектә бирелгән рәсемне карарга мөмкин.

Укучылар салмак җыр көенең туган авылны хикәяләп тасвирлауга, геройның уйларга бирелеп, сабый чагын хәтерләвенә бик тә туры килүен әйтәләр. Музыка шигырьдәге лирик геройның рухи халәтен тирәнтен ача алган, дип нәтиҗә ясыйлар. Рәсемдә туган авыл тасвирлана, әмма хисләр тулысынча ачылып бетмәгән, дип билгели алалар.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Туган җирнең төсе нинди? (Фәнис Яруллин. «Туган ягы кирәк кешегә», Резеда Вәлиева. «Гүзәл җирем»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган җиргә мәхәббәт хисен аңлау, аның матурлыгын күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару, үз позициясен, фикерен дәлилләү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Фәнис Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә», Резеда Вәлиеваның «Гүзәл җирем» шигырьләренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлекләре аңлау.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина

Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 23—26.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.

2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

«Туган як ни өчен кирәк?» темасына әңгәмә оештырып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге дәрестә ике шигырьне үзләштерү күздә тотыла.

Ф. Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә» шигырен өйрәнү аны уку һәм анализлауны үз эченә ала. Шигырьне анализлаган вакытта һәр строфа *Ни өчен кешегә туган ягы кирәк?* соравыннан чыгып тикшерелә һәм шигырьнең идеясе әйтелеп, нәтиҗә ясала. Бу очракта дәреслектәге сорау-биремнәр дә ярдәмгә килә.

*Резеда Вәлиеваның «Гүзәл җирем» шигырендә туган җир ничек сурәтләнгән?* дигән сорауга укучылардан туган җир — иң гүзәл җир, анда нинди генә төсләр, моңнар юк, сандугачлар, кәккүкләр моңлана, кичләре серле тынлыкка, иртәләре сихри нурга күмелгән, туган җирдәге ямь, андагы тәм мәңге онытылырлык түгел, дигән җавап көтәбез.

*Резеда Вәлиеваның «Гүзәл җирем» шигыреннән:*

*Гүзәл җирем!*
*Туган илем!*
*Оныта алмам гомеремдә*
*Якты ямең, татлы тәмең!*

*Мәңге минем күңелемдә! — дигән юлларын укыганда, син бу шигырьдәге лирик герой хисләренең кайсы авторның нин-*

*ди әсәрендәге лирик герое белән уртаклыгын тоясың?* дигән сорауга җавапларында укучылар Г. Тукайның «Туган авыл» шигырен атыйлар.

Әлеге әсәрләр белән бәйле рәвештә дәрестә гипербола һәм метафора төшенчәләре үзләштерелә.

Лирик әсәр — ул хисләр дөньясы, дип аңлатып, шигырьнең хисләр ташып чыкканда тууын ассызыклыйбыз. Шуңа күрә аңа гадәти сурәтләү генә түгел, ә арттыру, матуррак, тәэсирлерәк итәргә омтылу хас. Арттыру кайвакыт чиктән ашып китә, бу очракта аның образ тудыруның бер чарасы — гипербола булуын аңлатабыз.

Дәреслектә метафора төшенчәсенә билгеләмә бирелә. Рус мәктәбендә укучыларга да бу билгеләмә җиткерелергә тиеш.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта әлеге тема кысаларында алда өйрәнелгән шигырьләрдә гиперболаларга тукталып эш итәргә мөмкин. Мәсәлән, *Резеда Вәлиеваның «Гүзәл җирем» шигырендә лирик геройның нинди хисләре гипербола дәрәҗәсендә калку итеп сурәтләнгән?* дигән сорау биреп, алган белемнәрне ныгытабыз.

Яки Г. Тукай «Туган авыл» шигырендә туган җиремне яратам гына дими, ә *сөям җаным-тәнем белән*, ди.

Шигырьдә гипербола аерым гыйбарәләр белән генә дә чикләнми. Ул ниндидер хисне зур итеп, гадәтилектән арттырып сурәтләү дә була ала. Әйтик, туган ягын бөтен кеше дә ярата. Көн дә таң ата, вакыты белән яңгырлар ява. Ә Р. Рәкыйпов «Мин яратам сине, Татарстан» шигырендә аны бары Татарстанда гына була торган матурлык дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли:

*Мин яратам сине, Татарстан,*
*Ал таңнарың өчен яратам,*
*Күк күкерәп, яшен яшьнәп яуган*
*Яңгырларың өчен яратам.*

Метафора төшенчәсе белән дә нәкъ шул тәртиптә эшли алабыз.

Бу этапта шулай ук *Сез туган ягыгызны сагынасызмы?* соравын биреп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгып була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга. Ф. Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә» шигырен яттан өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз илаһи бит, изге (Дәрдмәнд. «Кил, өйрән...», Равил Фәйзуллин. «Туган тел турында бер шигырь»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — телләр өйрәнүгә кызыксыну уяну, телнең чисталыгы төшенчәсен аңлау, туган телгә хөрмәт хисе белән карау, дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, эшне планлаштыру, үзбәя; үз позициясен, фикерен дәлилләү, тыңлап аңлау, аңлап уку, нәтиҗә чыгару, гомумиләштерүләр ясау; фикерләрне төгәл һәм ачык итеп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Дәрдмәнднең «Кил, өйрән...», Р. Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» әсәрләренең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 26—30.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру. Мотивлаштыру.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру

**II. Актуальләштерү.**

Шәйхи Маннурның «Яхшы бел» шигыре белән таныштырып әңгәмә оештырырга мөмкин.

*Татарча да яхшы бел,*
*Русча да яхшы бел.*
*Икесе дә безнең өчен*
*Иң кирәкле затлы тел.*

*Тел кешене дус итә,*
*Бер-берсенә беркетә,*
*Бел, балам, син рус телен*
*Һәм онытма үз телең.*

Түбәндәге сораулардан файдаланып, укучылар белән әңгәмә үткәрәбез: *Ничек уйлыйсыз, без ни өчен татар телен яхшы белергә тиеш? Ни өчен рус телен дә яхшы белергә кирәк? Әти-әниең, әби-бабаң нинди телдә сөйләшәләр? Тел кешеләрне ничек дуслаштыра ала?* яки (тагын бер вариант буларак) *Туган телне сайлап буламы?* дигән проблемалы сорауга нигезләнеп фикерләшергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую**

*Укучылар, ничек уйлыйсыз, бүген дәрестә без нәрсә турында сөйләшәчәкбез икән*? дип сорап, дәреснең максатын билгеләтәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

Укучыларга Дәрдмәнднең «Кил, өйрән...» шигырен яттан сөйлибез. Алга таба яхшы укый торган укучылардан укытабыз һәм шигырьнең мәгънәсен үз сүзләре белән сөйләтәбез. *Шигырь сезгә ошадымы? Кайсы ягы белән?* дигән сорау биреп, укучыларның шигырьдән алган беренчел тәэсирләрен сораштырабыз.

Шигырьне анализлаганда, түбәндәге сорауларга таянырга мөмкин: *Шагыйрь нинди һөнәрне яхшы дип саный? Шигырьдә автор нәрсәгә өнди? Телләр өйрәнүне ул нинди һөнәр, ди? Шул ук вакытта нәрсәне онытмаска куша? Ни өчен*? *Катыштырма вәләкин телгә телне, тел уйнатмак — наданлыктан әсәрдер*, *дигәндә, шагыйрь нинди күренешне наданлык билгесе дип саный? Шигырьдә нинди күренешләр каршы куела? Ни өчен?* һ.б. Укучылар белән тел уйнату, төрле телләр сүзләрен катнаштырып сөйләшүнең зарарлыгы турында тормыштан мисаллар китереп сөйләшеп була.

Р. Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигыр»ен өйрәнгәндә видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин. Шулай ук түбәндәге сорауларны бирә алабыз: *Шигырьдә нинди гамәл халык рухын рәнҗетә дип билгеләнә? Кеше әйткән һәрбер сүз нинди сыйфатлар белән зурлана? Кеше*

*туган телдә сөйләшкәндә нинди хис кичерә? Күп телләр белү ничек бәяләнә? Картлык көндә нәрсә күңелгә шатлык хисе бирә?*

Р. Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» әсәренең төп идеясе кеше үзенең туган телен яратырга, сакларга, аны киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш дигән фикердән гыйбарәт.

Бу шигырьдәге:

*Киләчәкнең башы — бүгенгедә.*
*Нинди шатлык картлык көнеңдә —*
*оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,*
*матур итеп туган телеңдә!*

дигән сүзләрне ничек аңлыйсыз, дигән сорауга укучылардан түбәндәге җавапны көтәбез: Туган тел — кешегә әти-әнисе, әби-бабасы тарафыннан тапшырылган иң кыйммәтле бүләк. Туган телебездә безнең милли дөньябыз, әхлагыбыз чагыла. Һәм һәр кеше аны үзенең балаларына да өйрәтергә, тапшырырга тиеш. Оныгың туган телеңдә сөйләшми икән, димәк, син шушы кыйммәтле бүләкне тапшыра алмаган буласың, милләтнең киләчәгенә дә куркыныч яный дигән сүз. Шуңа күрә һәркем телне сакларга тырышырга тиеш, шул чакта телнең, милләтнең киләчәге өметле, якты булачак.

Бу дәрес кысаларында, өйрәнелә торган шигырьләргә бәйле рәвештә, идея төшенчәсенә билгеләмә бирү дә күздә тотыла.

Татар телендә белем бирү мәктәпләрендә Р. Фәйзуллинның дәреслектә бирелгән тормыш юлы һәм иҗаты турындагы кыскача мәгълүмат белән таныштырырга мөмкин. Ул алдагы дәреснең темасы белән бәйләнеп китәчәк.

**V. Яңа белемнәрне беренчел ныгыту**

Бу этапта *Сез мәктәптә нинди телләр өйрәнәсез? Аларны өйрәнү сезгә ни өчен кирәк? Телләр өйрәнү сезгә кызыклымы? Телләр белгән — илләр белгән, диләр безнең халыкта. Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?* кебек сораулар кулланып, әңгәмә үткәреп була.

Дәрдмәнднең «Кил, өйрән...» һәм Р. Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» әсәрләре кайчан иҗат ителгән? Аларның икесе өчен дә уртак идеяне әйтегез. Фикерләре-

гезне шигырьдән мисаллар белән раслагыз, дигән биремне тәкъдим итеп була. Укучылар бу шигырьләрнең икесе ике чорда язылганганлыгын аңларга тиешләр. Дәрдмәнд XX гасыр башында иҗат итсә, Р. Фәйзуллин XX гасырның икенче яртысында әдәбиятка килә, бүген дә актив иҗат белән шөгыльләнә. Шуңа да карамастан, аларның әсәрләрен уртак идея берләштерә. Ике шагыйрь дә башка телләрне өйрәнүнең мөһимлеген, әмма туган телне онытырга, бозып сөйләшергә ярамаганлыгын искәртә. Мәсәлән, Дәрдмәнд: *Бүтән телләр белү — яхшы һөнәрдер; тел уйнатмак — наданлыктан әсәрдер,* дип яза. Р. Фәйзуллин *Күп телләрне белү — яхшы шөгыль, туган телең үги калмаса,* ди һәм телне бозып сөйләүне яман чиргә тиңли.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга. Р. Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» әсәрен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Гимнга лаек һөнәрләр (Равил Фәйзуллин. «Гадиләргә гимн»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — төрле һөнәр ияләрен хөрмәтләү, һәр эшнең дә кирәкле, әһәмиятле булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, монологик сөйләм төзү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 30—41.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. Төрле һөнәрләр турында әңгәмә үткәреп, укучыларның аларга мөнәсәбәтен сорашып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн» шигыре сыйныфта укыла. Ул шактый күләмле әсәр, шуңа күрә аны уку өчен дә вакыт күбрәк китәчәк. Поэмада аңлашылмаган сүзләр дә күп, аларның мәгънәләрен ачыклау өчен билгеле бер вакыт кирәк булачак.

Әсәрдә укучылар күптөрле һөнәр ияләре белән очрашалар. Шунысы үзенчәлекле: автор аларны һөнәр исемнәре белән генә атамый, укучы кайчак кайсы һөнәр иясе турында сүз баруын үзе уйлап әйтергә тиеш була. Һәм шунысы кызыклы: шагыйрь аларны аерып бирми, ә бергә туплап, җыелма образ тудыра. Әлеге образны бер сүз белән Гадиләр дип кенә атый. Алга таба шул Гадиләр образы белән генә эш итәбез.

Әсәрнең идеясе авторның җәмгыятьтә файдалы эш башкарган һәр кеше — бөек, һәм данга лаек, Җир йөзендә нинди генә ачышлар ясалмасын, кешелек нинди генә үрләр яуламасын, нинди генә байлыклар табылып үзләштерелмәсен, дөньяның таткасы көн дә халыкка хезмәт күрсәтүче бөек гади һөнәр ияләрендә, дигән фикеренә барып тоташа.

Дәреслектә әлеге әсәргә карата уңышлы гына иллюстрацияләр бирелә. Укучыларның игътибарын аларга юнәлтеп эшләргә кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапны укучыларның кем булырга теләүләрен сорашу үткәреп була. Бу эш укучыларның сөйләмен үстерүгә дә хезмәт итәчәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне укырга. Үзе теләгән һөнәр иясе турында 8—10 җөмләдән торган хикәя язып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Укытучы — һәркемнең юлдашы, һәр эшнең юл башы (Фәнис Яруллин. «Сез иң гүзәл кеше икәнсез»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — укытучыны хөрмәт итү, аның кеше тормышындагы ролен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, монологик сөйләм төзү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ф. Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 41—43.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. Һөнәрләр турында сөйләшүне дәвам итеп, укытучы һөнәре турында әңгәмәгә алып кереп китә алабыз. Иң элек, Э. Мөэминова сүзләренә, И. Хисамов музыка язган «Хәтерлим мин әле бүгенгедәй» җырын тыңлатырга мөмкин. Экранда сүзләре күренеп барса, яхшы була.

*Хәтерлим мин әле бүгенгедәй,*
*Сентябрьнең бере җиткәнен.*
*Хәтерлим мин әле бүгенгедәй,*
*Көтә-көтә арып беткәнем.*

*Иң беренче булып килим диеп,*
*Өскә матур яңа күлмәк киеп.*
*Хәтерлим мин әле бүгенгедәй*
*Ашыга-ашыга чыгып киткәнем.*

*Ләкин миннән бик күп алда килеп,*
*Хуш киләсең, әйдә, әйдә диеп.*
*Хәтерлим мин әле бүгенгедәй*
*Укытучы апам көткәнен.*

*Шушы көннән башлап безнең өчен*
*Кызганмады үзенең бөтен көчен.*
*Безне сөйде, безгә белем бирде*
*Рәхмәт аңа изге эше өчен!*

Әйе, укучылар, укытучы — ул аң-белем бирүче, тәрбияче. Беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып, соңгы кыңгырау чыңлаганга кадәр безнең янәшәдә һәрчак яраткан укытучыларыбыз атлый. Алар безне белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәтне яратырга өйрәтә, дип нәтиҗә чыгарабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар, алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге этап Ф. Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигырен сәнгатьле итеп укудан башлана. Әсәрне анализлау укытучыга хас сыйфатларны барлауны күздә тота. Укучы шулай ук шигырьдә әйтелмәгән, ләкин үзе белгән укытучыларга гына хас сыйфатларны өстәп әйтә ала. Укытучы обра-

зын тудырган шагыйрьнең нинди чаралардан файдалануын да күзәтергә мөмкин.

Шигырьдә әйтелгән төп фикерне — идеяне аерып чыгарабыз.

Бу дәрестә шулай ук чагыштырмача авыр саналган теманы — шигырь төзелешен өйрәнү күздә тотыла. Теоретик материалны аңлатканда дәреслек материалыннан файдалана алабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Белемнәрне ныгыту максатыннан, тест эшләтергә мөмкин.

Шигырь төзелешенең өлешләре булган төшенчәләрне генә сайлап ал:

**а) ритм;**

ә) лирик герой;

**б) рифма;**

**в) строфа;**

г) образ;

**д) тезмә.**

Ритмга хас төп билге нинди? Дөрес җавапны сайла:

а) тезмәләрдән тору;

ә) охшаш мәгънәле булу;

б) охшаш яңгырашлы булу;

**в) тигез кабатлану.**

«Иң гүзәл кеше икәнсез» шигыренә тәкъдим ителгән характеристиканы сайлап алыгыз:

а) бу шигырь 8 иҗекле, 4 тезмәле строфалардан тора;

ә) бу шигырь 9 иҗекле, 2 тезмәле строфалардан тора;

**б) бу шигырь 9 иҗекле, 4 тезмәле строфалардан тора;**

в) бу шигырь 8 иҗекле, 2 тезмәле строфалардан тора.

Фәнис Яруллинның «Иң гүзәл кеше икәнсез» шигырендә рифманың нинди төре кулланылган? Дөрес җавапны сайлап ал:

а) юл аралаш;

**ә) янәшә;**

б) аралаш;

в) камаулы.

Шулай ук бу этапта тагын бер эш төре буларак «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» җырын (Ә. Хәйретдинов көе, Ф. Яруллин сүзләре) тыңлатырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Дәһшәтле утка керәмен... (Фатих Кәрим. «Ватаным өчен», «Сибәли дә сибәли»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган илгә мәхәббәт, тугрылык хисләрен аңлау, дусны югалту ачысы хисенә төшенү, әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерен телдән һәм язма текстларда белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ф. Кәримнең «Ватаным өчен», «Сибәли дә сибәли» шигырьләренең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 43—47.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Әлеге этапта, өйрәнеләчәк белемнәрне актуальләштерү максатыннан, Бөек Ватан сугышы турында сөйлибез: Бөек Ватан сугышы беткәнгә тиздән сиксән ел була. Бу канкойгыч сугыш турында без ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, күз алдына җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен гомерләрен биреп, яу кырларында мәңгегә ятып кала. Сугыш ул — коточкыч фаҗига.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапларда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагы фаразлана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы дәресләр Ф. Кәрим, Л. Лерон иҗатларында сурәтләнгән образларны, вакыйгаларны өйрәнүгә юнәлтелгән. Әдәби текстлар буларак Л. Леронның «Фашист очып үтте», татар мәктәпләрендә Ф. Кәримнең «Ватаным өчен», «Сибәли дә сибәли», шигырьләре алынды. Укучылар, аларның эчтәлегенә нигезләнеп, сугыш картинасының бирелешен, сугышның кеше күңеленә тәэсирен, әсәрләрдә патриотизм хисенең чагылышын билгеләргә, табигать һәм кеше халәтенең бәйләнешен күрсәтергә тиешләр. Аннан соң табигать образына билгеләмә бирәләр. Ф. Кәримнең «Ватаным өчен», «Сибәли дә, сибәли» шигырьләрендәге сугыш фаҗигасының, Л. Леронның «Фашист очып үтте» шигырендәге дошманга хас кансызлыкның А. Пластовның «Фашист самолёты очып үтте» картинасында бирелешен аңлатып, хикәя төзергә өйрәнәләр.

Бу дәрестә Ф. Кәримнең «Ватаным өчен» һәм «Сибәли дә сибәли» шигырьләрен өйрәнү күздә тотыла.

Яңа темага керешкәнче, фашизмның нәрсә аңлатуын, фашистларның кем булуын ачыклап китәргә кирәк:

Фашизм — яхшылыкка капма-каршы куелган төшенчә. Фашистлар бер милләтнең өстенлеген раслый, демократияне һәм кеше хокукларын кире кага. Мәрхәмәтлелек, изгелек — фашистлар өчен чит нәрсә.

1941 елда фашистлар Германиясе Советлар Союзына һөҗүм итә.

Сугышның беренче көннәреннән меңләгән совет кешесе Ватанны сакларга күтәрелә. Татар халкының язучы-шагыйрьләре дә, кулларына корал тотып, фронтка китәләр. Шул язучылар арасында танылган яшь шагыйрь Ф. Кәрим дә була. Биредә аның турында кыскача мәгълүмат биреп китү урынлы булыр. Укучылар аның белән дәреслектә бирелгән материаллар аша таныша алалар. Укытучы сөйләсә, тагын да яхшырак.

Әлеге дәрестә Ф. Кәримнең ике шигыре белән танышу планлаштырыла.

«Ватаным өчен» шигырен сәнгатьле итеп укыйбыз, укучыларның беренче тәэсирләрен сораштырабыз.

Шигырьне өйрәнү сорауларга җавап бирү рәвешен ала. Иң элек, шигырьдә строфалап бирелгән хисләрне һәм аларны тудырган сәбәпләрне ачыклыйбыз.

Беренче строфада үкенеч хисе сурәтләнгән, чөнки лирик герой сугыш утының иң дәһшәтлесенә керә һәм кояшны — яшәү, тереклек символын бәлки соңгы тапкыр күрә.

Икенче строфада лирик геройның горурлану хисләре урын алган.

Бу хис өченче строфада да дәвам итә.

Дүртенче строфадагы ышаныч хисе лирик геройга үлемнең юкка түгеллеген аңларга булыша.

Лирик герой Ватаны өчен дошманга каршы сугышырга әзер. Ул үзенең хаклы булуына ышана һәм безне дә ышандыра. Әгәр ул сугыш кырында үлеп калса, шигъри юллары бу үлемнең үкенечле булмаячагын дәлилли.

Ф. Кәрим язган хатының соңгысы булуына борчыла. Ул үзенең үләсен алдан белгән кебек. Борчылуы аның вакытлыча гына. Лирик герой үзе үлсә дә, балалары булуга, тормышта эзе, җырлары калуга шатлана. Ул шуларны уйлап юана.

Шул рәвешле, укучылар, Фатих Кәрим «Ватаным өчен» шигырендә сугыш һәм фаҗига төшенчәсен үкенеч, горурлык, ышаныч, нәфрәт хисләре аша күрсәтә, дигән нәтиҗәгә киләләр.

Ф. Кәримнең «Сибәли дә сибәли» шигыре дә сугыш турында. Вакыйга сугыш кырында бара. Солдатлар разведкадан кайтканда, бер иптәшләре дошман пулясыннан һәлак була. Аларга бик авыр: һәлак булган иптәшләрен күмәргә тиешләр. Аларның бу үлем белән килешәселәре килми. Бер сүз сөйләшми кабер казыйлар, сугышчан иптәш белән саубуллашалар. Укучылар менә шушы күренешне, халәтне аңларга тиешләр. Биредә дәреслектә бирелгән иллюстрация дә ярдәмгә килә ала.

Шулай ук түбәндәге сораулар да укучыларга шигырьне, лирик геройның күңел халәтен аңларга ярдәм итәчәк: *Шигырьдә елның кайсы фасылы тасвирланган? Шагыйрь ни өчен нәкъ менә шул ел фасылын сайлап алган? Шигырьдә вакытны, чорны, урынны сурәтләгән фаҗигалы сүзләр бармы, аларны барлап карыйк. Төн, җил, яңгыр образлары нәрсәне аңлата?*

Аерым игътибарны шигырьдә табигать образының бирелешенә юнәлтәбез, аның әсәрнең мәгънәсен ачудагы ролен билгелибез. Бу вакытта *Шигырьдә табигать күренешләрен сурәтләгән урыннарны тап. Ул күренешләр синдә нинди тойгылар уята? Табигать күренешләре лирик геройның хис-кичерешләрен ачыкларга ничек ярдәм итә? Нинди тел-сурәтләү чаралары шагыйрьгә табигать күренешләрен төгәл итеп тасвирларга булыша?* кебек сорау-биремнәр ярдәмгә килер.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Табигать образы турында төшенчә бирелә: табигать образы — ул әсәрдә тасвирланган табигать картинасы. Табигать образларының әсәрдә вазифалары күптөрле була ала. Алар вакыйгаларның фоны булып тора, геройларның эчке кичерешләрен көчәйтә, аларның кәефен һәм үсешен тоярга ярдәм итә. Шул рәвешле, аларны тулырак ачуга хезмәт итә.

Әсәрләрдә табигать образларын җанландыру, аларны кеше халәте белән тәңгәлләштерү образ тудырырга ярдәм

итә. Табигать кеше белән бергә кайгыра, шатлана. Язучы табигать образлары аша кешенең эчке кичерешләрен белдерә. Мәсәлән, кояш нурының биюе — ул шатлыклы моментлар, караңгы төн — куркыныч халәт. Кеше образын табигать образы белән бәйләп бирү персонажның хәл-халәтен тулырак ачарга булыша.

Әйтелгәннәргә мисал итеп, Ф. Кәримнең «Ватаным өчен» шигырендә табигать күренешләренең ролен ачыкларга мөмкин. «Ватаным өчен» шигырендә лирик герой табигатькә ышана. Шигырьдә табигать матур яктан гына сурәтләнгән. *Кала бар матурлык, ак чәчәкләр кала болында,* дип язса да, соңыннан ул зур ышаныч белән болай ди: *Чәчәкләргә төренеп эзем кала, җырым кала үткән юлымда.* Димәк, табигать лирик герой яклы. Ул аны дошманга каршы сугышка рухландыра.

Табигать сугышка керүче солдатның халәтен аңлый. Солдат хат яза. Бу вакытта табигать кояшлы, болыннарда ак чәчәкләр үсә. Шуңа күрә солдат дәһшәтле утка керсә дә, үзен тынычландыра. Безне үзем үлсәм дә балаларым, Ватаным кала, сугыш кырында үлү — бөек җыр ул, дип, ышандыра.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Фашизмның яшәргә хакы юк (Ләбиб Леронның «Фашист очып үтте» шигыре);

«Фашист самолёты очып үтте» (Иҗади эш: Аркадий Пластовның «Пролетел фашистский самолёт» («Фашист самолёты очып үтте») картинасы буенча инша).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — фашизмга карата нәфрәт хисенә төшенү, аның ерткычлыгын, кансызлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-

үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, үз позициясен, фикерен дәлилләү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Л. Леронның «Фашист очып үтте» шигыренең идея-проблематикасын аңлау, картина буенча инша язу күнекмәләрен үстерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 47—50.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерү.

2. *Яшәү хакы гыйбарәсен ничек аңлыйсың?* дигән проблемалы сорау куеп, сөйләшүгә алып чыгабыз.

Шуннан соң укучыларга Аркадий Пластовның «Фашист самолёты очып үтте» картинасын күрсәтеп, *Картинада йөзтүбән яткан, үлгән малайның бу дөньяда яшәргә хакы бар идеме?* дигән сорауны бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сугыш китергән фаҗига, сугышның авырлыгы, иң беренче чиратта, хатын-кызлар, балалар җилкәсенә төшә. Заводларда һәм кырларда хатын-кызлар, яшүсмерләр, балалар озакка сузылган көрәшкә кушылдылар. Аларның күбесе ирләре, әтиләре урынына басты. Менә картинада сурәтлән-

гән малай да, мөгаен, фронтка киткән этисе урынына көтү көтәргә чыккан булгандыр дип, теманы өйрәнүгә керешеп китәбез.

Л. Леронның «Фашист очып үтте» шигырен уку. Бу вакытта видеодәрес материалыннан файдланып була. Аудиоязмасы электрон дәреслектә дә урнаштырылган, аны тыңлатырга мөмкин.

*«Фашист очып үтте» шигырен укыгач, нинди картиналар, күренешләр күз алдыгызга килде?* дигән сорауга укучылар: “Көзге көн. Малай көтү көтә. Бернинди куркыныч янамый кебек. Сыерлар, сарыклар тыныч кына чирәм ашап йөри. Малай янында көчек чабып йөри. Самолёт тавышын ишеткәч, эт шомланып өреп куя. Куркыныч янавын *Саргылт яфракларны җилләр алып китте бөтереп* дигән сүзләрдән аңларга була. Самолёттан малайга аталар, ул үлә», — дип җавап бирергә мөмкиннәр.

*Бу шигырьне тыңлагач,сездә нинди хис туды?* дигән сорауга җавап биргәндә, укучылар курку, кызгану һәм нәфрәт хисләре тууын билгелиләр.

*Шигырьдә сугыш фаҗигасы ничек күрсәтелгән?* Бу әсәрдә малайның үлеме сурәтләнә. Ул әле бала, ул яшәргә тиеш иде, ләкин фашист фашист пулясы аның гомерен өзә.

*Сезгә бу шигырьне тасвирларга кушсалар, нинди төсләр кулланыр идегез?* дигән сорауны биреп, картина белән эшләүгә күчәбез.

Картинаны карап, дәреслектә бирелгән сорауларга җавап биргәннән соң, Л. Леронның шигырен әлеге картинада сурәтләнгәннәр белән чагыштырабыз.

А. Пластовның «Фашист самолёты очып үтте» картинасында һәм Л. Леронның «Фашист очып үтте» шигырендә көзге көн сурәтләнгән. Картинада көз сары, кара төсләр белән бирелгән (шигырьдә *саргылт яфракларны җилләр алып китте бөтереп* дигән сүзләр бар). Икесендә дә йорт хайваннары: сыер һәм сарыклар сурәтләнгән. Ак болытлар арасына кереп киткән кара самолётны шигырьдә дә, картинада да күрәбез. Йөзтүбән ятып үлгән малай икесендә дә кызгану хисе тудыра. Эт образы картинаны да, шигырьне дә тулыландырып тора.

Эт, хуҗасына ияреп, агачлыкка көтү көтәргә килгән. Ул малайны ярата. Картинада да аның янәшәсендә. Ак болытлар арасыннан дошман самолёты күренгәч, нәрсәдер сизгәндәй, эт өреп куя. Л. Леронның «Фашист очып үтте» шигырендә дә нәкъ шулай.

Картинадагы этнең, хуҗасының егылганын күреп, ярсып-ярсып өргәне ишетелә сыман. Хуҗасын югалту аңа бик авыр. Ул әле аның үлгәненә ышанмый да кебек. Анда өмет хисе бар. Бәлки әле аның хуҗасы яраланган гынадыр һәм алар бергә өйгә кайтырлар. Эт бик кызганыч, чөнки ул үзенең дустын югалта.

Шигырьдә самолётның калкып чыгуы, утлы авазның йөгерүе, кайтавазның тынлыкны чәрдәкләп үтүе, бугазындагы төерне йота алмаган эт шигырьдәге күренешне фаҗигалы итеп күрергә ярдәм итә. Малайның башыннан аккан кан, аның уңайсыз ятуы, этнең өзгәләнеп өрүе, ак болытлар арасындагы кара самолёт, үлгән хайваннар картинаны куркыныч, кайгылы итеп кабул итүгә этәрә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта иншаны яза башлыйбыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Иншаны язып бетереп килергә кушыла.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Бәлеш нинди хисне белдерә? (Шәүкәт Галиев. «Пәрәмәч»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — өлкәннәрнең сүзен тыңларга кирәклеген аңлау, вакытны юкка сарыф итүнең зыянга булуын төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләрнең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ш. Галиевнең «Пәрәмәч» шигыренең эчтәлеген белү, комик ситуация сурәтләнешенең төп мәгънәсен аңлау.

**Материал:** Материал: Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 50—54.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта өй эше тикшерелә, белгәннәр кабатлана.

«Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган әрәм» булган мәкален тәкъдим итеп, шуның мәгънәсенә төшенү буенча эшләргә була, шул рәвешле сөйләшүгә алып чыга алабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшү нигезендә укучылар теманы, максатны билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырьне берничә вариантта укырга була: укытучы үзе укый, электрон дәреслектән аудиозманы тыңлатабыз яки видеодәрес материалыннан файдаланабыз. Шуннан соң укучыларның беренче тәэсирләрен сорашып алабыз. Шигырьне анализлаганда, дәреслектә бирелгән сорау-биремнәргә өстәмә рәвешендә түбәндәгеләрне дә тәкъдим итеп була: *Шигырьнең нигезендә нинди комик вакыйга ята? Шагыйрь бу вакыйганы ничек сурәтли?* Бу сорауларга җавап биргәндә, укучылар шигырьдә көлке тудырган төп вакыйганы, ягъни малайның кибеттән алып кайтып килгән камыры ташып чыгу вакыйгасын билгелиләр. Камыр савыттан, малайның кепкасыннан, хәтта кесәләреннән дә ташып чыга.

*Малай ни өчен шундый көлке хәлдә кала?* дигән сорауга укучылар әнисе ашыгып кайтырга кушса да, иркенләп йөргәнгә күрә, дип җавап бирәчәкләр.

*Соңгы строфада «бәлеш» һәм «пәрәмәч» сүзләре нинди мәгънә белдерә?* соравы укучыларның игътибарын сүз уйнату алымына юнәлтәчәк. Әлбәттә, алар, малайны күргәч, өлкәннәрнең шаккатуларын белдерә.

«Пәрәмәч» шигырендә төп фикерне аерып чыгарабыз, ягъни өлкәннәр сүзен тыңларга кирәк. Шул рәвешле, дәрес башында каралган мәкальне искә төшереп, икесен бәйлибез.

*Шәүкәт Галиев үзенең «Пәрәмәч» шигырендә комик ситуацияне нинди максат белән сурәтли?* дигән сорауга укучылар өлкәннәр сүзенә колак салмауның көлкегә калдырырга мөмкинлеген күрсәтү өчен, дип җавап бирәчәкләр.

Бу дәрестә Шәүкәт Галиевның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү дә күздә тотыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Шәүкәт Галиев «Пәрәмәч» шигырен нинди максат белән язган дип уйлыйсыз? Ул — малайның шундый көлке хәлдә калуын тасвирлау гынамы? Сезне бу шигырь нәрсә турында уйландырды?* дип, укучыларны фикерләшүгә алып чыгабыз. Укучылар шигырьдә малайның көлке хәлдә калуы турында гына сүз бармавын төшенергә тиешләр. Шагыйрь бу әсәрен өлкәннәр сүзен тыңларга өндәп иҗат иткән. Бу ситуациядә камыр гына ташыган, ә икенче очракта зуррак бәла килергә мөмкин, дигән нәтиҗә ясала.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Иң матур хатирә, иң якты хис (Һади Такташ. «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны»)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган җиргә мәхәббәт, аңа соклану хисенә төшенү, сагыну хисенең көчен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә һәм дәлилли белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Һ. Такташның «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны» шигыренең идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 55—59.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү.

2. Туган җир турында мәкальгә нигезләнеп, әңгәмә үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырьне анализлау барышында игътибарга алынырга тиешле фикерләр түбәндәге сорауларга җавап биргәндә ачыклана:

*Шигырьгә бирелгән эпиграфта «җыр» метафорасына нинди эчтәлек салынган?* **(Үткәннәр турында матур хатирәләр.)**

*Шигырьдә лирик герой тормышының кайсы чоры турындагы хатирәләрен бәян итә?* **(Туган якта үткән балачак еллар.)**

Үзәктә торган хисне билгеләгәндә, укучылар туган җирдә үткән матур балачак елларын сагыну хисен беренче планга чыгаралар.

*Лирик герой ни өчен моңлана?* (Чөнки гомер агышын туктатып, гамьсез балачак елларын кире кайтарып булмый.)

*Лирик геройның моңлануын, үкенечле сагынуын шагыйрь текстта нинди ысуллар белән аңлаткан?* (*Их!* ымлыгын, *Калыйм мәллә монда югыйсә?* соравын кабатлау аша.)

Тексттан лирик геройның яшәү максаты салынган юлларны таптырабыз, шуның эчтәлегенә нигезләнеп, укучыларны фикерләтәбез.

Шулай ук лирик геройны шатландырган уйны билгеләтеп, укучыларның моңа карата фикерләрен тыңлыйбыз.

*«Әй, җырлыйсы килә шушы җырны» шигыре нәрсә турында?* соравына җавапта укучылар аның үткәнне сагыну турында булуын ачыклыйлар. Шигырьнең үзәгендә торган туган җир образын билгелиләр.

Әсәрдә *талир тәңкә* төшенчәсе очрый. Дәреслектә аңа тулы аңлатма бирелә, шуның белән таныштырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Һади Такташның «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны» шигырен язуга нинди вакыйга сәбәп булган дип уйлыйсыз?* соравына укучылар шагыйрь туган авылына кайткан булган, күрәсең, шунда ул каз бәбкәсен күргән, соңгысы аңа үзенең малай чагын исенә төшергән, шагыйрь үткәннәрен сагынган, туган авылыннан читтә яшәвен уйлап моңсуланган, шуннан ул, хисләнеп, шушы шигырьне иҗат иткән, дип җавап бирә алалар.

Алдагы дәресләрдә өйрәнелгән зур теманы йомгаклап, дәреслектә бирелгән *Лирик әсәр иҗат итү өчен, нинди шартлар үтәлергә тиеш?* проблемалы соравына җавап эзлибез һәм нәтиҗә ясыйбыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Иң зур хезмәт — үз халкыңа хезмәт (Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. «Әбүгалисина» повесте);

Хыял дөньясы чынбарлыкка якынмы? (Фантастик әсәрләрдә образлар системасы. Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» повесте);

Әгәр мин тылсымчы булсам... (Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» повестенда Әбүгалисина образы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — белемнең әһәмиятен аңлау, туганлык хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — К. Насыйриның «Әбүгалисина» повестеның эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 60—90.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максатыннан, түбәндәге өзек белән таныштырабыз.

*Хәлвәфрүш Әбүгалисинага ялынып, ихфа гыйлемен өйрәтүен үтенде. Әбүгалисина башта:*

*— Син ихфа гыйлемен теләсә нинди тиешсез урында файдаланып һәлак булырсың, — дип, бу гыйлемне өйрәтергә теләмәде. Ләкин егет бик нык вәгъдәләр биргәч, аны, күзләренә ихфа сөрмәсе сөртеп, кеше күзенә күренми йөрергә өйрәтте.*

*Көннәрдән бер көнне Хәлвәфрүш, күзенә ихфа сөрмәсе сөртеп, сарайга китте. Юлда барганда, аңа кешеләр килеп бәрелделәр. Кемгә бәрелгәнен белмәделәр, куркышып, йөгерә-йөгерә китеп бардылар.*

*Егет сарайга барып керде, аны беркем дә күрмәде.*

*Өзектә сүз нәрсә турында бара? Нәрсә ул ихфа белеме? Кем ул ихфа белемен үзләштергән Әбүгалисина? Ул уйлап табылган геройммы, әллә реаль шәхесме? Аның турындагы әсәрне кем язган? Шуларны беләсең киләме?* сораулары ярдәмендә укучыларда теманы өйрәнүгә кызыксыну уятабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы ике-өч дәрес фантастик әсәрләрдә образлар системасын өйрәнүгә багышланган. Текст буларак К. Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре алына. Программа буенча К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗатына, эшчәнлегенә кыскача күзәтү ясау да каралган. Укучылар фантастиканың жанр хасиятләре белән танышалар, фантастик образга хас сыйфатларны әсәрләр мисалында карап барлыйлар. Шулай ук теоретик белем рәвешендә антитеза төшенчәсен үзләштерәләр. Әсәрләрнең төп идеясен билгеләп, күтәрелгән мәсьәләләрне анализлыйлар. Боларның, нәтиҗәдә, укучыларга иҗади эш башкарганда ярдәме тиячәк.

К. Насыйриның биографиясе белән таныштырганда, иң элек, портрет белән эш оештырып була:

*Портретка игътибар итегез. Бу кеше турында нәрсәләр әйтә аласыз? Ул кайсы чорда яшәгән, нәрсә белән шөгыльләнгән дип уйлыйсыз?* дигән сорауларга укучыларның

җаваплары тыңлана. К. Насыйриның замандашы булган Габдулла бине Таҗетдиннең галимнең портретын ачыклаган сүзләре белән таныштыру урынлы булыр:

*Габделкаюм әл-Насыйри әфәнде урта буйлы, зур башлы булып, чәчен җитүрәк йөртә иде. Борын һәм авыз килешле, төсе ак түгел, бәлки бодай төсендәрәк, йөзе ачык түгел, караңгырак иде. Күзләре зәгыйфь булудан, язуны күзенә бик якын китереп карый иде. Мыекны җитүрәк йөртә иде. Сакалы сирәк булып, артык озын җибәрми иде. Йөрүе әкрен, алдына карап, турырак басып йөри иде. Киемнәре артык кыска да, озын да түгел иде. Хәлен белгән адәмнәр, элек русча укып йөргән вакытларында европачарак та киенгән, диләр.*

Алга таба К. Насыйриның тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге белән таныштырабыз. Аның белемгә омтылучан, бик тырыш, кешелекле, фидакяр зыялы булуын ассызыклыйбыз. К. Насыйриның галим булып китүендә ата-бабаларының белемле, укымышлы кешеләр булуы да зур роль уйнаган. Укытучылык эшен ташлап, фәнни хезмәт белән шөгыльләнә башлавының сәбәбе — иске карашлы җәмгыятьнең татар балаларын русча укытуга каршы килүендә. Искелек тарафдарлары К. Насыйрига каршы чыкканнар, ә алдынгы фикерле яшьләр аны таныганнар, хезмәтләрен югары бәяләгәннәр, чөнки ул дөньяны фәнни яктан аңлатырга тырышкан. Ул әдәби әсәрләр язган, башка халыклар әдәбиятын татар теленә тәрҗемә иткән, әдәби тәнкыйть белән дә шөгыльләнгән.

Укучыларга К. Насыйриның *Һәр нәрсәнең чиге бардыр. Әмма акылның чиге дә соңы юктыр. Акыл һәм тәҗрибә бер-берсенә ярдәмче булып, җир белән су кебектер. Ә су белән җир бер-берсеннән башка бернәрсә дә үстерә алмыйдыр...*, дигән сүзләрен аның эшчәнлеге белән бәйләп аңлатырга кушабыз.

Бу вакытта төрле атаклы шәхесләрнең К. Насыйри турында әйткән фикерләрен куллана алабыз. Мәсәлән,

*Безнең Ломоносов һәм кайбер вакытларда аның белән чагыштырып йөртелә торган тыйнак Каюм Насыйри, гениаль Леонардо да Винчи һәм аның белән чагыштырылмый*

*торган Каюм Насыйри — өчесе дә бер яктан охшашлар: алар барысы да энциклопедистлар булганнар. Алар үзләренең кыска гына гомерләре дәвамында тормыш тарафыннан нык таләп ителгән барлык фәннәргә һәм сәнгатьләргә дә нигез салып калдырырга ашыкканнар.*

Тюрколог Николай Дмитриев

Өстәмә рәвештә Казандагы Каюм Насыйри музеена виртуаль экскурсия оештыра алабыз.

Алга таба укучыларга дәрес башында укылган өзекнең Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» повестеннан алынуын һәм әлеге әсәрнең фантастик жанрда иҗат ителүен хәбәр итәбез.

Фантастика турында аңлатма биреп китәргә кирәк булачак (бу вакытта видеодәрес материалыннан файдалып була).

Фантастика — грек теленнән кергән сүз. Күзаллау осталыгы дигәнне аңлата. Фантастик әсәр тормыш-чынбарлыкны үзенчәлекле итеп чагылдыра, реаль тормышта булмаган сәер хәлләрне сурәтли, уйлап табылган могҗизалы чынбарлыкны тергезә. Фантастикада тормышта була торган әйбер-күренешләр гадәттән тыш, табигый булмаган көчләр, элементлар белән аралаштырылып, үзенчәлекле фантастик образлар дөньясы тудырыла.

Фантастика килеп чыгышы белән ерак гасырларга барып тоташа, чөнки ул мифологиядә, борынгы фольклорда һәм беренче классик язма әдәбиятта чагылыш таба. Ягъни фантастик образлар иң борынгы чорларда барлыкка килеп, мифология һәм халык иҗаты аша әдәбиятка күчәләр. Фантастика, иң беренче чиратта, әкият жанрына охшаган. Аларның икесенә дә хыял, өмет төшенчәләре хас. Әкиятләрдә — ул ерак тарихтан бүгенге көнгә килеп җиткән хыял булса, фантастикада исә — бүгенгедән киләчәккә төбәлгән хыялый өмет.

Фантастик әсәр кешегә моңа кадәр таныш булмаган яңа дөньяны танырга һәм үзләштерергә ярдәм итә, гаҗәп һәм могҗизалы тормыш белән очраштыра. Киләчәк алдында куркып калмаска, киресенчә, аның белән кызыксынырга, интеллектуаль, физик һәм әхлакый яктан аның белән та-

нышуга да әзер булырга өйрәтә. Фантастик жанрда язылган әсәрләрнең үзенчәлекләрен күрсәтү максаты белән, Адлер Тимергалинның «Ерак планетада» әсәреннән өзек белән танышырга тәкъдим итеп була. Анда Ялгызак планетасында яшәүче, кыяфәтләре белән гап-гади агачларга охшаган глорийлар турында сөйләнә. Алар актив хәрәкәт итү сәләтеннән мәхрүм.

*Саргылт кайрылары шоп-шома, корычтан каты. Яшь, нәзек һәм сусыл ботаклары белән бәбәкләре генә гәрәбә төсле үтәдән-үтә күренә. Ә яфраклары пальма яфрагы шикелле зур, калын. Барысы да җайлап кына «кояшка» борылганнар, аның нурларын түкми-чәчми йотып торалар...*

*Глорийларның, агач булсалар да, теоретик белемнәре, теоретик фикерләү колачы искиткеч. Алар телескопсыз, спектроскопсыз, автомат планетаара станцияләрсез дә галәм турында бик күп мәгълүмат туплаганнар. Глорийлар, саф математик юл белән фикер йөртә, шуңа күрә башка дөньяларда да тереклек булырга тиешлеген, ул тереклекнең бүтән төрле кануннарга буйсынырга мөмкинлеген аңлаганнар.*

Өзектә очраган гайре табигый хәлләрне, предметларны, затларны барлыйбыз һәм нәтиҗә ясыйбыз: фантастикада реаль элементлар гадәттән тыш, кешедән өстен, табигый булмаган көчләр, элементлар белән аралаштырыла. Шул рәвешле, үзенчәлекле фантастик образлар дөньясы тудырыла.

Алга таба «Әбүгалисина» повесте белән танышу күздә тотыла. Әсәрне өлешләп укыганда, аның эчтәлеге ачыклана бара, идея-проблематикасы билгеләнә.

Әсәрне анализлаган вакытта фантастик әсәр үзенчәлекләренә, әлеге төр әсәрләрдә образлар оештырылышына игътибар иттерәбез.

*Әсәрдә чынлыкта була алмый торган нинди хәл сурәтләнә?* Әйтик, малайларның Әбүгалисинаның киезе астына бер бит кәгазь салулары, Әбүгалисина белән Әбелхарисның өч сәгатькә генә ачыла торган мәгарәгә бер елга кереп качып, төрле фәннәр үзләштерүләре, күздән югалу, кеше күзенә күренми йөри алу, озак ашамый-эчми тора алулары, ерак араны тиз үтә белүләре һ.б.

Әсәрдә телгә алынган мәгарәне китапханә белән чагыштырып, бүген соңгысының кешеләргә бернинди киртәсез, тоткарлыксыз зур белем туплау мөмкинлекләре бирүен искәртергә кирәк.

Программада билгеләнгән антитеза алымын үзләштерүгә аерым игътибар бирәбез. Бу очракта *Өзектә Әбүгалисина белән Әбелхарис нинди итеп тасвирланалар? Әбелхарис кайсы яктан ачыла? Ни өчен автор аларны капма-каршы куеп сурәтли? Белемнең төрле кулларда төрле максат белән файдаланылуын ассызыклау өчен, Каюм Насыйри «Әбүгалисина» әсәрендә антитеза алымын кемнәрнең каршылыгын күрсәтү өчен куллана?* кебек сораулар ярдәмгә килер.

Бу әсәре белән К. Насыйри белемле булуның әһәмиятен күрсәтеп, бернинди киртәләргә карамыйча укырга, белем алырга чакыра, гыйлемнең үзеңә дә, башкаларга да файдалы булачагын күрсәтергә тели.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Татар әдәбиятында жанр буларак фәнни фантастика инде XIX гасыр башында формалаша башлый. Әлеге жанр үзенчәлекләрен К. Насыйриның «Әбүгалисина», Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз», Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә», «Фәтхулла хәзрәт», «Балалар атавы», Ш. Камалның «Сәмруг кош» әсәрләрендә күрергә мөмкин. Татар әдәбиятында алга таба әлеге жанрны үстерүчеләрдән Адлер Тимергалинны, Радик Фәзовны һ.б ны атый алабыз.

Әлеге этапта *Синең нинди фантастик әсәрләр укыганың бар? Нинди фантастика яратасың?* кебек сораулар биреп, укучыларның бу жанр белән таныш булу-булмавын белә алабыз.

Шулай ук *Фантастик әсәрләргә нинди үзенчәлекләр хас? Әкият белән фантастик әсәрләрнең бер-берсеннән аермасы нәрсәдә?* кебек сораулар белемнәрне ныгытуга хезмәт итә.

**VI. Өй эше бирү.**

К. Насыйриның «Әбүгалисина» повестен өлешләп укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә, сорауларга җавап бирергә.

Иҗади эш буларак, «Фантастика дөньясында» темасына рәсем ясарга, үзе теләгән темага 9—10 җөмләдән торган фантастик әсәр иҗат итәргә тәкъдим итәргә була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кояшны капларлык ялган (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. Гали Рәхим. «Яз әкиятләре»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — икейөзлелек, ялган, аларның зыяны турында белү, экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясенең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 91—97.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Темага алып керү максаты белән, хайваннарның, үсемлекләрнең әкиятләрдә, мәсәлләрдә нинди мәгънәне бирү өчен кулланылуын сораштыра алабыз. Әйтик, куян — куркаклык, төлке — хәйләкәрлек, кырмыска һәм бал корты — тырышлык, арыслан — көч-гайрәт, бүре — явызлык, тигәнәк — әрсезлекне белдерү өчен һ.б.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты әйтелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы ике дәрестә, Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре», И. Газинең «Кояш артыннан киткән тургай» хикәяләре нигезендә, аллегория һәм шартлы образлылык турында күзаллау булдыру максаты куела. Сайлап алынган әсәрләрнең эчтәлегенә таянып, укучылар аллегория турында теоретик мәгълүмат алалар, аллегорик һәм шартлы образларга салынган мәгънәне ачыкларга өйрәнәләр, хикәянең идея-проблематикасын билгеләү күнекмәләре булдыралар. Анализ барышында предметара бәйләнешләргә мөрәҗәгать итү укучыларның дөньяга карашларын киңәйтәчәк, әсәрләрнең эчтәлеге әхлакый тәрбия бирүгә хезмәт итәчәк.

Укучыларга аллегория турында аңлатма бирәбез. Аллегория термины «читләтеп» һәм «сөйлим» дигән мәгънәдәге грек сүзләреннән ясалган. Тормыш күренешен үз кыяфәтендә тасвирламыйча, башка төрле образлар ярдәмендә шартлы сурәтләүне аллегория, диләр. Андый әсәрләрдә табигать образлары, төрле абстракт төшенчәләр мөстәкыйль образ буларак яши. Без бу образларда кеше холкына хас аерым сыйфатларны күрәбез, ягъни аларда киная була. Биредә *киная, читләтеп сөйләү* дигән төшенчәләрне аңлату сорала.

Аллегориянең сезгә таныш мисаллары — мәсәлләр, дип дәвам итәбез. Мәсәлән, Г. Тукайның сез 5 нче сыйныфта өйрәнгән «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәлендә кешеләрдәге аерым сыйфатларның хайваннар дөньясына караган образлар аша гәүдәләндерелүен күрдегез. Мәкальләрдә, әкиятләрдә, табышмакларда да аллегория күзәтелә.

Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясен укып, сораулар ярдәмендә эчтәлеген ачыклыйбыз. Аллегорик образларны тикшерүгә аерым игътибар бирәбез. Бу вакытта түбәндәге сорау-биремнәр ярдәмгә килә:

*Эт эчәгесе ник кайгыга бата? Канәфер агачына таба үрмәләгән эт эчәгесе нинди образ белән чагыштырыла? Бу чагыштыруда образлар арасында нинди охшашлык күренә?*

*Әсәрдә эт эчәгесенең нинди гамәле сандугачны куркыта? Сандугачның сайраудан туктавы нинди шартлы мәгънәне җиткерә?*

*Эт эчәгесе образы кешегә хас нинди сыйфатны гәүдәләндерә? Ни өчен эт эчәгесе нәкъ менә төн караңгылыгында канәферга таба кара елан кебек шуышкан? Төн образының нинди шартлы мәгънәсе барлыкка килгән?*

Табигатьтә эт эчәгесе һәм канәфер агачының нинди үсемлекләр булуы турында белгәннәреңне искә төшер. Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре» әсәрендә эт эчәгесе һәм канәфер агачына нинди сыйфатлар хас?

Характеристикаларның Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясендәге кайсы образларга туры килүен билгелә.

Мәкерле, ялганчы, максатына кеше хисабына ирешүче, шәфкатьсез: ул — ... .

Йомшак холыклы, тыныч, буйсынучан, беркатлы: ул — ... .

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта дәрес буена алган белемнәрне ныгыту максаты белән, тест эшләргә тәкъдим итеп була. Мәсәлән,

*Аллегориягә бирелгән билгеләмәне тап*:

а) тормыш күренешен үз кыяфәтендә тасвирлау;

ә) әсәрдә уйдырма дөнья тудыру;

**б) тормыш күренешен үз кыяфәтендә тасвирламыйча, башка образлар ярдәмендә шартлы сурәтләү;**

в) әсәрдә хайван образларын сурәтләү.

*Канәфернең эт эчәгесе тарафыннан һәлак ителүе кешеләр тормышындагы нинди тискәре гамәл турында сөйли? Дөрес җавапны сайла:*

а) ялган сөйләүнең башкаларны үпкәләтүе;

ә) ялкаулыкның көлкегә калдыруы;

**б) мәкернең матурлыкны юкка чыгаруы.**

*Канәфер агачының һәлак булуы нинди фикерне җиткерә? Дөрес җавапны сайлап ал:*

а) кешене өмет яшәтә;

ә) мәхәббәтнең гомере кыска;

б) **мәкер мәхәбәтне юкка чыгара.**

*Автор хикәядә игътибарны җәмгыятьтәге нинди проблемаларга юнәлтә? 3 дөрес җавапны сайлап ал:*

**а) көчлеләрнең көчсезләр хисабына яшәве;**

**ә) мәкер;**

б) максатсызлык;

**в) икейөзлелек;**

г) ялкаулык;

д) таркаулык;

*Хикәядә нинди сәбәпләр канәфер агачының үлеменә китерә? 4 дөрес җавапны сайлап ал:*

а) **эт эчәгесенең мәкерле ялганы;**

ә) кояшның үсемлекләргә нурларын тигез таратмавы;

б) **канәфер агачының явызлыкка дәшми калуы;**

в) сандугачның тынып калуы;

г) **канәфер агачының ялганга ышануы, беркатлылыгы;**

**д) эт эчәгесенең икейөзлелеге.**

*Хикәядә канәфернең эт эчәгесе тарафыннан һәлак ителүе кешеләр тормышындагы нинди тискәре гамәл турында сөйли? Дөрес җавапны сайла*:

а) ялган сөйләүнең башкаларны үпкәләтүе;

ә) ялкаулыкның көлкегә калдыруы;

б) мәкернең матурлыкны юкка чыгаруы.

*Канәфер агачын һәлак итү хисабына кояш яктысына үрелгән эт эчәгесенең язмышы ничек төгәлләнер дип уйлыйсың? Кояш нурлары аңа бәхет китерерме?*

*Әсәрдә канәфер агачының эт эчәгесе кылган мәкергә мөнәсәбәте нинди? Ул үзен башкача тотса, эт эчәгесе максатына ирешә алыр идеме? Тормышта явызлык, мәкерне җиңү өчен нишләргә кирәк?*

Шулай ук укучыларны *Син нинди кешеләрне Гали Рәхимнең «Яз әкиятләре» әсәрендәге эт эчәгесе образына ох-*

*шатыр идең? Синең әйләнә-тирәңдә андый кешеләр бармы?* сораулары ярдәмендә сөйләшүгә алып чыгып була.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Нык ихтыярга күкләр буйсына (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. Ибраһим Гази. «Кояш артыннан киткән тургай»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — максатчанлык, ихтыяр көче сыйфатлары турында төшенчә алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — И. Газиның «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясенең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 97—101.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта эшне төрлечә оештырырга мөмкин. Беренчедән, *Син ничек уйлыйсың, ни өчен әдәби әсәрләрдә автор-*

*лар шартлы образларга мөрәҗәгать итәләр?* соравы ярдәмендә теманы өйрәнүгә юнәлеш бирә алабыз. Шартлы образлар әсәрнең образлылыгын арттыра. Алар укучының игътибарын үзенә җәлеп итә. Шуңа күрә автор әйтергә теләгән фикерне дә укучы игътибарсыз калдыра алмый. Шартлы образлар укучыны уйланырга, аларга салынган мәгънәне табарга да мәҗбүр итә, дигән нәтиҗә ясала.

Икенче вариант — *Каты ихтыярга күкләр буйсына* мәкале нигезендә әңгәмә оештырып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

И. Газинең «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясен анализлау барышында түбәндәгеләр ачыклана. Әсәрдә өч тургай күккә оча, ләкин араларыннан берсе генә җиргә кире төшми. Ул арада иң тырышы, үз-үзенә иң нык ышанганы булганга, кояшка омтылган. Әлеге тургай образы аша югары максатка омтылучан, көчле рухлы булу дигән шартлы мәгънә белдерелә. Үз-үзенә ышану, тырышлык, бернигә карамый, максатына бару кебек сыйфатлары тургайга бик югары күтәрелергә ярдәм итә. Кояшка менеп җитә алган тургайны тырыш, үҗәт, максатчан кешеләр белән чагыштырып була.

Артык тырышлык куймаган ике тургай кояшка менеп җитә алмыйлар, җиргә кире төшәләр. Аларны куркак, икеләнүчән, максатсыз кешеләр белән чагыштырып була.

Әсәрдә кояш образы югары максатларны, рухи бөеклекне чагылдыра.

И. Газинең «Кояш артыннан киткән тургай» хикәясе максатка ирешүдәге ныклык турында. Автор әлеге әсәре белән тырыш, максатчан, үҗәт кешеләр үз максатына ирешә ала, дип әйтергә тели.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта эшне күрсәтелгән юнәлештә алып барабыз. Укучылардан хикәя ахырында бирелгән өзекне укытабыз һәм мәгънәсен ачыкларга кушабыз: *Кичке чыктан юешләнгән үләннәр өсләп әкрен генә авылга таба атлый башладым.*

*Атлыйм... Уйлыйм... Кояш артыннан киткән тургай хакында уйлыйм... Ә күлнең аргы башында, җәйге матур төнне котлап, бакалар кешнәшә...* Биредә автор мәгънә ягыннан бер-берсенә туры килмәгән төшенчәләрне янәшә куя: *бакалар кешнәшә,* дип яза. Моның белән ул биеккә омтылмаганнар җырының күңелгә тәэсир итмәвен күрсәтә.

И. Газинең «Кояш артыннан киткән тургай» әсәрендә тургай сайравы тасвирланган өлешне укытабыз. *Никадәр генә биек менгән булсалар да, моңлы җырлары әле һаман җиргә төшеп җитә: челтер-челтер, туррый-туррый, яй-ай....* Тургай — туган якның матур бер бизәге, ул хикәяләүчегә балачактан якын, тургай җыры аның өчен бөеклек, гүзәллек, тырышлык билгесе дә, автор тургай җырының бөтен матурлыгын укучыга да күрсәтергә тели, шуңа аны бик җентекләп тасвирлый, дигән нәтиҗә ясыйбыз.

*Гали Рәхимнең «Яз әкиятләре», Ибраһим Газинең «Кояш артыннан киткән тургай» хикәяләрендә авторлар кешедәге нинди сыйфатларны кире кага? Кайсыларын камил шәхескә хас сыйфатлар дип саный?* сораулары ярдәмендә укучыларны, уйландырып, әңгәмәгә алып чыгабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, хикәя эчтәлегенә туры килгән өч мәкаль табып килергә, эчтәлеге буенча рәсем ясарга кушып була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Үзем турында үзем (Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. «Исемдә калганнар» (өзек);

Иң авыр һәм иң кадерле мизгелләр (Габдулла Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — ятимлек, үгилек төшенчәләренең мәгънәсен аңлау, хәсрәтләнү, сагышлану хисләренә төшенү, әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерүләр ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу; «Исемдә калганнар» әсәренең эчтәлеген аңлау, идея-эстетик үзенчәлеген билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 4—30.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Теманы өйрәнүгә юнәлеш бирү максатыннан, түбәндәге сораулар буенча эшләп була: *Өлкән кеше буларак шагыйрьләр, язучылар балачак темасына мөрәҗәгать итәләр. Олыгайгач, ни өчен алар үзләренең балачакларын искә төшерәләр икән? Габдулла Тукай үзенең балачагы турында ничек яза? Синең бу турыда беләсең киләме?*

Язучы, балачактан ераклашкан саен, үзенең бала вакытын, әти-әнисен, дусларын, шул чактагы кызыклы вакыйгаларны исенә төшерә. Аңа башкалар үзе турында кызыклы әсәр язарга тәкъдим итәргә мөмкин. Укучыга да яраткан язучысының үзе турында язган әсәре белән танышу бик кызыклы, чөнки ул да үзенең балалык елларын искә төшерергә мөмкин, дип нәтиҗә ясала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы өч дәрес Г. Тукай иҗатында автобиографик жанрда язылган әсәрләр белән танышуны, алардагы образлылыкка бәя бирүне күз алдында тота. Әдәби текст буларак Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре алынды. Укучылар аның эчтәлегенә нигезләнеп, андагы образларны, язучыларның шәхес булып үсешенә тәэсир иткән вакыйгаларны, кеше факторларын билгеләргә, геройларның үсеше аларның эш-гамәлләренә бәйле булуын күрсәтергә, әсәрдәге образлылыкка билгеләмә бирергә өйрәнәләр. В. Федоровның «Тукайның Өчиледән Кырлайга китүе» картинасы буенча хикәя, кечкенә Тукай «сәяхәт»енең схемасын төзиләр.

Күп кенә язучыларның әсәрләре автобиографик характерда була, геройларда язучының сыйфатлары һәм аның тормышыннан алынган вакыйгалар да чагылыш таба, дип башлыйбыз сүзебезне.

Г. Тукайның «Исемдә калганнар» повестенда шагыйрьнең балачагы турында мәгълүмат бирелә. Аның кечкенәдән ятим калуы турында сөйләнә. Әсәрне укып чыкканнан соң, укучылар аның төрле гаиләләрдә яшәргә мәҗбүр булуын билгелиләр.

Әсәрне анализлау түбәндәге фикерләрне ачыкларга ярдәм итәчәк: Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрендә вакыйгаларны кечкенә Габдулла исеменнән Г. Тукай үзе хикәяли. Габдулла Тукай — әсәрнең төп герое.

Габдулланы кечкенәдән бәхетсезлек сагалап тора. Аңа биш ай булганда, әтисе үлеп китә. Әнисен Сасна мулласына кияүгә бирәләр. Әнисе аны Шәрифә карчыкта асрамага калдыра. Бу — аның бәхетсез чоры. Әнисе Саснага үз янына алдыргач, ул үзен бик бәхетле хис итә. Саснага барып җиткәч, үзенә ак икмәккә ягылган бал белән чәй эчүләрен, үги әтисенең аңа карата яхшы мөгаләмәдә булуын ул биш минутлык төш дип атый. Ләкин, ни кызганыч, бу бәхет озакка бармый: әнисе үлеп китә.

Алга таба Габдулланы Өчиле — Казан — Өчиле маршруты көтә. Казанда аның тормышы беркадәр җайлана. Яңа

əти-əнисе аны үз итəлəр, яратып тəрбиялилəр. Шулай да үзенең үксез бала булуын ул монда да һəрдаим тоеп тора. Габдулланың Ташаяк ярминкəсендəге карусельлəрдə атынып йөри алмавы вакыйгасы белəн бəйле уй-кичерешлəре шуны ачык күрсəтеп тора. Бу уңайдан Габдулла Тукай турында истəлеклəр китабыннан шул карусельлəр белəн бəйле истəлекне укып таныштырып китеп була. Əсəрдə телгə алынган Хан мəчете турында да мəгълүмат бирергə кирəк. Укучылар хəзерге Сөембикə манарасының элек шулай аталуын аңлыйлар. Шунысы да кызыклы: аны изге дип санап, манара күренеп торырлык җирдə булганда, балаларны йөзлəрен аңа таба борырга өйрəткəннəр.

Янə Өчилегə кайтып төшүе аңа, əлбəттə, шатлык китерми, ул үзенең монда артык авыз булуын ныграк сизə, кабат туганнары тарафыннан кагылып-сугылып яши. Беркадəр вакыт үткəннəн соң, аны Кырлай авылына җибəрəлəр.

Сəгъди абзый Габдулланы Өчиледəн атка утыртып алып кайта. Өйгə кайтып җиткəч, əни буласы кеше аңа катык һəм ипи кисеп бирə. Габдулла аны бик тəмлəп ашый, чөнки аның бабасында туйганчы ашаганы булмый. Ашаганнан соң, рөхсəт сорап, урамга чыга, шунда аны авыл малайлары əйлəндереп алалар. Малайлар аңа бик кызыксынып карыйлар, чөнки аның киеме авыл балаларыныкыннан аерылып тора. Беренче көнне ул аларның барысы белəн дə танышырга өлгерми, соңыннан бу малайлар аның дусларына əйлəнə. Бу эпизодка карата дəреслектə Х. Казаковның иллюстрациясе урнаштырылган. Габдулла əллə кем булып басып тора, аны балалар əйлəндереп алган. Барысы да Казан малаена кызыксынып карый.

Габдулла Кырлай авылында беренче тапкыр мəдрəсəгə бара. Ул искиткеч хəтергə ия була, шуңа күрə бик яхшы укый. Укытучысы хəтта аңа наданрак балаларга дəрес бирергə дə рөхсəт итə. Укучылар аңа хəлфəгə караган кебек карыйлар, бəлеш ашарга да чакыралар. Əти-əнисе аңардан бик канəгать була.

Сабан туе җиткəч, Габдулланы иртəн, кулына кечкенə капчык тоттырып, күчтəнəч җыярга озаталар. Сабантуй күренешендə Габдуллада барлык балаларга да хас булган сами-

милек, эчкерсезлек, хөрмәт итә белү сыйфатларын күрәбез. Ятим бала булганга, аңа тәм-томны башка балаларга караганда күбрәк бирәләр. Әти-әнисе моңа бик шатлана. Капчыгын әнисенә тапшыргач, Габдулла урамга чыгып йөгерә, анда Сабантуйга әзерлек бара: өйдән-өйгә кереп, яулык, ситсы кебек әйберләрне колга башына бәйләп, Сабантуйга бүләкләр җыеп йөриләр. Бүләкләр җыелып беткәч, болынлыкта Сабан туе башлана. Атлар чабыша, көрәш, малайлар йөгерешә, яулыклар алына — болар барысы да Габдулланың күңеленә уелып кала.

Дәреслеккә повестьтан Габдулла Тукайның Җаек чорына кадәрге тормыш аралыгы алынды. Татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары Габдулланың Җаек чоры турында, биографик әсәрләрдә образлылык темасын өйрәнгәндә, Ә. Фәйзинең «Тукай» романыннан алынган өзекләрдән укып беләләр.

Габдулла Тукайның тормышы тарихтан аерылгысыз. Аны ятимлек, ачлык, авыр тормыш сыкмый да, сындырмый да. Бер караганда, ул тормыш арбасыннан төшеп калырга тиеш иде кебек. Әмма авырлыклар аны рухи яктан ныгыта гына. Тарихи чынбарлык аның шәхес булып үсешенә зур йогынты ясый.

Никадәр газаплар кичерсә дә, Тукай бу фаҗигалы, кыска гомер юлын горур атлап уза, шагыйрь буларак гражданлык бурычын үз халкына, аның киләчәк бәхете хакына армый-талмый хезмәт итүдә күрә. Балачак елларына туры килгән авырлыклар аның рухын чыныктыра. Тукай — тарихи шәхес. Аның исеме һәм язмышы мәдәниятебезнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәңгегә бәйләнгән. Хәзерге балалар Габдулла Тукайны бик яхшы беләләр, аның әкиятләрен, шигырьләрен укып, аннан үрнәк алып үсәләр.

Әсәрне укыганда укучыларга таныш булмаган күренешләр күп очрый. Алар турындагы мәгълүматны «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасыннан укып беләбез.

Автобиографик әсәрләрнең үзенчәлекләргә тукталып, әлеге жанрга билгеләмә бирәбез.

Автобиографик әсәрдә аны язу моментына кадәрге вакыт колачлана. Автобиографик әсәр әдипнең тормыш юлы, ижа-

ты турында киңрәк мәгълүмат бирү белән генә чикләнми, еш кына язучының үз әсәрләренә шәхси бәясен, мөнәсәбәтен ачыкларга булыша. Язучының вакыйгаларда катнашкан булуы, үзе яшәгән дәвер турында төгәл, вак детальләр аша сөйли алуы автобиографик әсәрнең тарихи кыйммәтен билгели. Мондый әсәрләрдә язучының хисләре, фикерләре чагылыш таба.

Автобиографик повесть — эпик төргә карый, төп герой — хикәяләүче тормышында булган вакыйгалар беренче зат исеменнән сөйләнә, хикәяләүченең узган тормышы яктыртыла.

**I. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә Х. Казаковның «Үксез бала» картинасы (фрагмент) тәкъдим ителә. Бу этапта әлеге сәнгать әсәре буенча әңгәмә үткәрергә мөмкин.

Х. Казаковның «Үксез бала» картинасында Габдулла Кырлайда Сәгъди абзый йортында сурәтләнгән. Чиста, матур өй эче. Тәрәзә төбендә яран гөле үсеп утыра. Тәрәзәдән кергән кояш нуры өйне җылыта. Сәкедә бәләкәй Апуш ашап утыра. Аның алдында әле яңа гына пешкән, парлары чыгып торган бәрәңге һәм тирән савытка салынган катык. Әмма Габдулланың моңсу, сагышлы күзләре үзәкне өзә. Бу рәсемгә карагач, күңелдә кызгану хисе туа, әмма аның шушы кыска вакытлы рәхәт көннәре өчен куана да алабыз.

Алга таба укучыларга Х. Казаковның «Үксез бала» картинасын Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре белән чагыштырып бәяләргә кушып була. Г. Тукай әсәрендә дә тарихи чынбарлык сурәтләнгән. Рәссам да, язучы да кечкенә Апушның бәхетсез язмышын (берсе — буяулар, икенчесе сүзләр ярдәмендә) аңлаешлы тасвирлый, дип билгелиләр укучылар. Язучы да, рәссам да Габдулла Тукай тормышындагы бу чорны бик уңышлы сурәтләгәннәр.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә. Шулай ук Габдулла Тукайның балачагы буенча сәяхәт картасы төзергә мөмкин. Аны төзегәндә түбәндәге моментларны истән чыгармаска:

1. Габдулла Тукай булган җирләрне барлау.

2. Темага туры килгән рәсемнәр табу.
3. Рәсемнәрне билгеле бер тәртиптә урнаштыру.
4. Матур итеп текст язу, бизәү.

**VII. Рефлексия.**
1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үткән теманы кабатлау;

Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый (Иҗади эш: Лотфулла Фәттаховның «Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый» картинасы буенча сөйләм үстерү).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау, хезмәт сөю, өлкәннәргә хөрмәт белән карауның әһәмиятен төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, үз фикерен телдән һәм язма текстларда белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне, гомумиләштереп, системага сала белү; картина буенча хикәя төзү күнекмәләрен үстерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 30—31.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү, тема буенча үткәннәрне искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максаты хәбәр ителә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Иң элек Г. Тукайның тормыш юлын хәтерләргә кирәк. Кырлай чорына аерым игътибар биреп, Габдулланың нинди гаиләдә тәрбияләнүен, нәрсәләр белән шөгыльләнүен, әтисе булып саналган Сәгъди абзыйның ниндирәк кеше булуын тагын бер кат искә төшерәбез.

Алга таба, Г. Тукайның тормышы сурәтләнгән картина-иллюстрацияләрнең чагыштырмача күп булуын әйтеп, Л. Фәттаховның «Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый» картинасын карарга тәкъдим итәбез. Әлеге картина дәреслектә урнаштырылган, аңа бәйле рәвештә мәгълүмат, сорау-биремнәр тәкъдим ителә. Шуларга нигезләнеп, картина буенча хикәя төзетәбез.

Рәссам турында сөйләп китү урынлы булыр. Лотфулла Фәттахов 1918 елның 27 сентябрендә Түбән Новгород өлкәсендә туган. Ул кечкенәдән шигырьләр, хикәяләр язарга, рәсем ясарга яраткан. Ятим калгач, 13 яшендә ул җәяү Казанга килгән һәм Яңа Бистәдә татар мәктәбендә укый башлаган. Аны сыйныфташы, киләчәктә танылган рәссам Харис Якуповның гаиләсе тәрбиягә алган.

Мәктәпне тамамлагач, Л. Фәттахов Казан сәнгать училищесында укыган. Фин сугышында, Бөек Ватан сугышында катнашкан. Л. Фәттахов — РСФСРның халык рәссамы, Сталин бүләге лауреаты.

Без аның кечкенә Апуш белән Сәгъди абзый сурәтләнгән картинасына сокланып карыйбыз.

Кырлайда Габдулланы Сәгъди абзый авыл тормышы белән таныштырган, хезмәткә өйрәткән. Бу рәсемдә печән өсте сурәтләнгән. Сәгъди абзый белән Габдулла печән чабарга баралар. Сәгъди абзыйның кулында чалгы, ә Габдулланыкында — тырма. Габдулла бик җитди, Сәгъди абзыйны тыңлый, аның һәр сүзенә игътибар бирә. Аларның көне буе печән чабасылары бар. Еракта печән кибәннәре күренә, димәк печән өсте күптән башланган. Печәннең күп өлеше инде чабылган, киптерелгән һәм кибәннәргә өеп куелган.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Үткән теманы кабатлау максаты белән, дәреслектәге *Әдәби әсәрдә һәм автобиографик әсәрдә образлар бирелешендә нинди үзенчәлекләр күзәтелә?* соравын биреп, укучыларны уйланырга мәҗбүр итәбез.

Электрон дәреслектә бирелгән тестларны да эшләтергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Төзегән хикәяне дәфтәрдә язып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Шул вакытта мин кулыма китап алам (Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романында образлылык тудыру чаралары);

Җырлап торам, торган җирем тар булса да (Әхмәт Фәйзи. «Тукай»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — белемгә омтылыш, тырышлык, горурлык хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ә. Фәйзинең «Тукай» романының эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 32—44.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

*Габдулла Тукай тормышында ачылмаган серләр бармы?* соравы белән укучыларда теманы өйрәнүгә кызыксыну уятабыз.

Күренекле татар шагыйре Габдулла Тукай моннан 138 ел элек дөньяга килгән булган. Бу әллә ни зур вакыт аралыгы түгел, әмма аның кулъязмалары, хатлары һәм шәхси әйберләренең бик аз өлеше генә сакланган. Моның төп сәбәбе — шагыйрьнең үз йорты, гаиләсе, нәсел дәвамчылары булмау, кунакханәдән кунакханәгә күчеп яшәве. Хәтта Уңъяк Кабан урамындагы 15 нче йорттан күченгәндә, шагыйрьнең бөтен әйберләренең урлануы һәм өстендәге киеменнән башка бернәрсәсез калуы хакында хәбәрләр бар. Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлы турында әдәбиятчылар, телчеләр, тарихчылар язмаган кайбер фактларны язучылар иҗатында табып була. Г. Тукай турындагы биографик әсәрләрдә тарихи дөреслек тә, автор күзаллаулары, уйдырмалар да урын алган.

Бу урында *Габдулла Тукай турында күбрәк беләсең, аның тормышы белән ныграк танышасың киләме? Язучылар биографик әсәрләрдә Тукай образын ничек тудыра? Тукай турындагы тарихи чыганакларны кайдан ала? Биографик әсәрләр тарихи чынбарлыкка туры киләме?* кебек сораулар биреп, алдагы ике дәрестә өйрәнеләчәк материалга юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Татар телендә белем бирү мәктәпләрендә ике дәрес биографик әсәрләрдә образлар системасын тикшерүгә багышлана. Өйрәнү объекты — Ә. Фәйзинең «Тукай» романы, аерым

алганда, романнан өзекләр. Әлеге әсәрдә образлар системасының бирелеше, төп геройга хас үзенчәлекләр, биографик әсәрдә аерым тарихи шәхесне сурәтләү алымнары өйрәнелә. Укучылар биографик әсәр жанрының үзенчәлекләрен аерырга, төрле әсәрләрдә төп герой образының охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә, чынбарлык белән уйдырманы танырга омтылалар, хикәяләү үзенчәлекләрен күрсәтәләр. Алар тарихи шәхесләр язмышы белән кызыксына башлыйлар, атаклы кешеләрнең шәхси тормышларын иҗатлары белән бәйләп тикшерергә өйрәнәләр.

Биографик әсәрләрдә тарихи шәхесләр образлары әдәбиләштереп, халык теленә якынайтып бирелә. Билгеле бер шәхес турындагы әдәби әсәр фәнни хезмәтләр белән танышуга караганда җиңелрәк кабул ителә һәм укучыны битараф калдырмый. Биографик әсәр иҗат иткәндә язучының таланты, аның фантазиягә, тел-сурәтләү чараларына бай булуы гына җитми, ә фәнни тикшеренү эшләре алып баруы, билгеле бер чор, мохит, яшәеш турында фәнни мәгълүматлар туплавы да мөһим.

Биографик әсәр — атаклы кешеләрнең тормыш юлын язуга нигезләнгән әдәби жанр төре. Биографик әсәрдә тарихи шәхеснең кайсы чорда, нинди шартларда яшәве, рухи дөньясы һәм иҗат юлы яктыртыла. Гадәттә, язучылар, фән эшлеклеләре һәм атаклы шәхесләр тормышы турында биографик әсәрләр языла. Анда аларның кайсы чорда, нинди шартларда яшәве, рухи дөньясы һәм иҗат юлы белән танышырга мөмкин. Биографик әсәрдә чынбарлыкта булган вакыйгалар авторның иҗади фикерләве, сурәтләү алымнары ярдәмендә баетып тасвирлана, ягъни документаль һәм әдәби башлангычлар үзара үреп бирелә.

Ә. Фәйзи яшьтән үк Тукай иҗатын яратып укый, Тукайга багышлап шигырьләр яза. Романга керешкәндә, ул тәҗрибә туплап өлгергән әдип булып, Тукай образын тарихи дөреслеккә туры китереп язарга тырыша. Ул шагыйрь яшәгән, эшләгән урыннар турында архив материалларын барлый, аның чордашлары белән аралаша. Герое заманын җентекләп өйрәнә, Тукай турындагы истәлекләрне, аның

һәм аңа язылган хатларны, документларны барлый. Материалларны анализлап, блокнот-дәфтәрләргә теркәп бара һәм башта мәкаләләр рәвешендә бастыра, докладлар ясый.

Биографик әсәрләрдә образлылыкны тикшерүгә багышланган тема кысаларында үткәрелгән беренче дәрестә Ә. Фәйзинең «Тукай» романыннан алынган беренче өзектә Габдулланың итче Лотфуллага ит алырга бару вакыйгасы җентекләп тасвирлана. Әлеге вакыйга аша Габдулланың укырга яратуы күрсәтелә. Өйдәгеләр белән мөнәсәбәте, кире холкы һәм туры сүзле булуы аңлашыла. Моны автор Габдулланың алъяпкычын артка бәйләп йөрү күренеше аша ача. *Ни өчен ул алъяпкычын артка бәйләп йөри?* дигәндә, бу — Габдулланың туры һәм үзсүзле, тапкыр, шаян булуын аңлата дибез.

Икенче дәрестә өйрәнелә торган өзектә, Җаекта җизнәсе үлгәч, Габдулланың яшәргә мәдрәсәгә күчеп китүе һәм мөстәкыйль тормыш башлавы тасвирлана. Әдәби образ тудырганда артык, кирәксез, очраклы бер генә деталь дә булмый. *Габдулланың җизнәсе йортыннан мәдрәсәгә күчкәндә өтек кенә мендәрен һәм өзгәләнеп беткән кечкенә юрганын алуы белән автор нәрсә әйтергә теләгән икән?* Болар — җизнәсе йортында Габдуллага игътибар булмау, Габдуллага начар мөнәсәбәт күрсәткече.

Биредә автор Габдулла образын җыр-моңга гашыйк, тапкыр сүзле, җор телле, шигъри җанлы, шук-шаян шәкерт итеп ача. Шагыйрь Чулпани, Тукай белән шигырь әйтешкәндә, аның талантын, шигъри осталыгын күреп ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта биографик әсәрләргә хас үзенчәлекләрне укылган роман мисалында ачыклау максаты куела. Әсәрдән реаль факт булып саналган өзекләрне таптырабыз. Тарихи шәхесләр турында мәгълүмат белән таныштырабыз.

Дәреслектә Мөхәммәт Галинең «Тукай белән беренче күрешүем» исемле истәлеге урнаштырылган. Шуның белән танышып, укучы Габдулла Тукай биографиясенең яңа якларын ача.

*Биографик әсәрләрдә тарихи шәхес образын тудырганда автор нинди чаралардан файдалана*? соравын куеп, укучыларны уйландырабыз, нәтиҗә ясатабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Бер мәхәббәтнең тарихы (Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Ибраһимов. «Алмачуар»);

Максатыңа ирешү бәхетле итәме? (Хикәя жанрында образлар системасы. Г. Ибраһимов. «Алмачуар»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — хайваннарга карата мәхәббәт хисенә төшенү, әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу. «Алмачуар» хикәясенең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 45—69.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Г. Ибраһимовның «Алмачур» исемле хикәясе бар. Язучы хикәянең исеменә «Бер мәхәббәтнең тарихы» дип аңлатма да биргән. *Хикәядә кемгә яки нәрсәгә мәхәббәт турында сүз бара дип уйлыйсың?* дигән сорауны куеп, теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Тема хикәяләрдәге образлылыкны өйрәнүгә юнәлдерелгән. Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе нигез итеп алына. Бу хикәягә таянып, укучылар хикәядә образларны, алар белән бәйле вакыйгаларны табалар. Хикәядә образлылык тудыруның бер чарасы буларак пейзаж белән танышалар. Аның әсәрдәге вазифасын бәяләргә өйрәнәләр. Хикәядәге образларның эш-гамәлләре аша аның идеясен ачуга ирешәләр. Хикәядә торгызылган дөнья сурәтенең чынбарлык белән бәйләнешен күрәләр, үзләре нәтиҗә чыгаралар.

Бу белемнәр нигезендә мөстәкыйль рәвештә пейзаж төшенчәсенә билгеләмә бирә алалар. Иҗади рәвештә аны куллана башлыйлар.

Программада Г. Ибраһимовның тормыш юлын өйрәнү каралган. Язучының портреты белән эшләгәннән соң, биографиясе белән таныштырабыз. Сәгатьләр саны әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында иркенләп сөйләргә мөмкинлек бирми, шуңа күрә төп моментларга гына тукталабыз. Презентация кулланырга була.

Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясен өйрәнүгә ике сәгать каралган, әсәр тексты да дәреслектә икегә бүлеп бирелгән. Беренче өлешкә Хафиз белән Әлемгол вакыйгасы, Закирның Алмачуарлы булып, аны үстерүе, тәрбияләве,

ярышка әзерләве турындагы вакыйгалар керә. Икенче өлештә Сабантуйда ат чабышы белән бәйле вакыйгалар турында сөйләнә. Шулай итеп, хикәядә Закирның тормышын үзгәрткән ике төп вакыйга бар, дип әйтә алабыз. Беренче вакыйга — Әлемголның бурлы бия бүләк итүе, икенчесе — Алмачуарның үлеме.

Беренче вакыйганы анализлаганда, түбәндәгеләрне истә тотарга кирәк: Әлемголның Хафизга ат бирү вакыйгасын, башкорт Әлемголның ни өчен Хафизга бурлы бия бүләк итүен ачыкларга ярдәм итә. Әлемгол Сабантуйда тирә-якта дан тоткан көрәшче Хафизны аягын чалып ега һәм батыр кала. Хафиз шуннан соң Сабантуйга башка аяк басмый. Әлемгол Сабантуйдан кайтуга авырый башлый. Үзенең ялгышын таный. Терелсә, Хафизга бурлы биясен бүләк итәргә нәзер әйтә. Әмма терелгәч, бирәсе килми. Ул кабат авырый башлый, тагын шул ук нәзерен әйтә. Терелә һәм Хафизга күк биясен бүләккә китерә.

Бу вакыйгага белән бәйләп, укучылардан түбәндәгеләрне сорашып була: *Әлемголның аяк чалып Хафизны егуын ничек бәялисез?? Әлемголның аяк чалуы Хафизга ничек тәэсир итә? Әлемгол Сабантуйда Хафизны аягын чалып екканнан соң нинди кичерешләр белән яши? Аңа нәрсә хатасын аңларга ярдәм итә? Әлемгол үзе эшләгән гаделсезлекне таныймы? Ул нинди вакыйгада күренә?*

Тексттан Закирның Алмачуарга мөнәсәбәте турындагы урыннарны таптырып укытабыз, Бурлы биянең йортка килүе Закир тормышында зур үзгәрешләргә китерүен билгелибез. Ул аннан туган колыннарның чабышкы булулары турында ишетеп белә. Туачак колынның да чабышкы булачагына ышана. Аны Сабантуйда ярыштырып, беренчелекне алу хыялы белән яши башлый. Аның өчен тормыш бары Алмачуар белән генә бәйле булып кала. Әнисенә, этисенә мөнәсәбәте дә аларның Алмачуарга булган карашларына барып тоташа. Балалар белән уйнау да, балыкка бару да Бурлы биягә якынрак булу, аның колын алып кайтканын күрү өчен генә.

Ат чабышы белән бәйле вакыйгаларга күчәбез. Ярышка Закир бик дулкынланып килә. Аның белән ярышасы атларның һәммәсенең дә бик затлы булулары аны бераз куркыта

да. Арада данлыклы Күк бия дә бар. Менә атларны тезәләр. Ярыш башланып китә. Аерыкул дигән тайгак елгага алар өч ат бергә килеп җитә. Елга ярына күтәрелгәндә, Күк бия белән Алмачуар гына кала. Икенче караганда, Күк бия инде алда чаба. Менә алар янәшә баралар. Закир гайрәт белән бер сугып алуга, Алмачуар, Күк бияне аршын ярым чамасы калдырып, мәйданга керә. Беренче килсә дә, аңа икенче килгән атка тиешле сөлгене бирәләр. Закир моның өчен старостага камчы белән суга. Староста хатасын таный, Закирга үпкә белдерми, егерме тиен көмеш акча да бирә. Бу арада ярыштан килгән Алмачуарга кинәт туктарга туры килә. Бу аның аякларына баса алмаслык хәлгә килүенә һәм үлеменә сәбәп була.

Хикәя Алмачуарның үлеме белән тәгәлләнә. Монда Закирның да гаебе бар. Ул җиңү турында гына хыяллана.

Закир образына хас сыйфатларны барлаганда, аның үзсүзле, максатчан булуын билгеләтәбез.

Укучылардан Әлемгол һәм Закир образларындагы уртаклыкны таптырабыз. Укучылар Әлемголның да, Закирның да җиңү турында гына хыяллануларын билгелиләр. Әлемголның да, Закирның да хыяллары тормышка аша. Әлемголның хатасы: ялганлый, хәрәмләшә (көрәшкәндә аяк чала). Закирның хаталары: старостага камчы белән суга, Алмачуарның исәнлеген кайгыртмый, чабыштан килүгә туктата. Димәк, хыяллары тормышка ашу аларны бәхетле итми, чөнки ул башкаларга бәхетсезлек китерә, күңеләрен яралый.

Бу вакыйгалар гаделсезлек, башкаларга начарлык эшләү, үзең турында гына уйлап, аларны оныту һәрвакыт җәзасын таба, дигән фикергә китерә.

Программада үзләштерүгә каралган пейзаж төшенчәсен аңлатканда укучыларга түбәндәге өзекне тәкъдим итеп була:

*Безнең авылның кояш батышы ягында зур бер сырт бар. Сабан туен һәрвакыт шунда ясыйлар. Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үзалдына дулкынланып тора, — болар хатын-кызлар. Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Болардан читтә бала-чага, карт-коры, сатучы-фәлән, ат, арба, белмим, әллә ниләр кара болыт кебек бөтен сыртны каплап алганнар.*

Бу өзектә нәрсә турында сүз баруын, тасвирланган пейзажның әсәрдәге ролен ачыклаганда, аның вакыйга булачак урынны күзалларга, аның рухын тоемларга ярдәм итүен билгеләтәбез.

Алга таба пейзажга билгеләмә бирелә:

Пейзаж — табигать күренешен, вакыйга бара торган урын, тирәлекне тасвирлый, анда авыл, шәһәр күренеше дә, аның бер өлеше генә дә булырга мөмкин. Ул геройның рухи халәтен ачарга ярдәм итә, укучыны әсәрне, андагы вакыйгаларны кабул итәргә әзерли.

*Әгәр сиңа Закирның колынны Алмачуарны беренче тапкыр яшел үлән ашарга алып чыккандагы шатлыклы хисләрен пейзаж ярдәмендә белдерергә кирәк булса, нинди күренешне тасвирлар идең?* дигән бирем укучыларның күзаллавын үстерә, коммуникатив күнекмәләр формалаштыра.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта сөйләшү объекты итеп хәрәмләшүне, башкаларның бәхетсезлегендә үзеңне бәхетле итүгә ирешү турындагы фикерләрне алырга мөмкин.

*Тормышка ашкан хыял һәрвакыт бәхет китерәме?* проблемалы соравын куеп, әңгәмә оештырып була.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә. Әсәр эчтәлеге буенча табигать күренешен сурәтләгән рәсем ясарга тәкъдим итеп була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Матурлык — рухи халәт ул (Әмирхан Еники. «Матурлык»);

Хисләрнең дә үз йөзе, үз төсе бар (Әмирхан Еники. «Матурлык»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — күңел матурлыгы төшенчәсен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясенең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 69—87.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта өй эшен тикшерергә, белгәннәрне кабатларга мөмкин.

*Тышкы матурлык белән масайма, эчке матурлык белән масай* мәкале буенча әңгәмә оештырып, теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясен өйрәнүгә программада ике сәгать вакыт каралган. Дәреслектә дә әсәр ике өлешкә бүлеп тәкъдим ителә. Һәр өлештән соң урнаштырылган сорау-биремнәр әсәрнең эчтәлеген ачыклауга, образларга характеристика бирүгә, әсәрнең идея-проблематикасын билгеләүгә юнәлдерелгән.

Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясендә бер шәкерт Бәдретдин исемле шәриктәшенең өйләренә чәй эчәргә керү вакый-

гасын сөйли. Ул үзе дә вакыйгаларда катнаша, күргән-белгәннәрен үз исеменнән бәян итә. Хикәянең башында ук автор вакыйгаларның бер карт әдип авызыннан сөйләнгәнлеген искәртеп үтә.

Бу әсәр белән бәйле рәвештә укучылар хикәяләүче образы төшенчәсе белән танышалар. Аны төшенү өчен түбәндәге сораулардан файдаланып була:

*«Матурлык» хикәясендә вакыйга кем исеменнән сөйләнә?*

*Хикәяләүче Бәдретдинне нинди холыклы шәкерт итеп тасвирлый?*

*Хикәяләүчене нәрсә гаҗәпкә калдыра?*

*Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясендә хикәяләүче образы турынданиләр беләсең? Хикәяләүчене нинди шәкерт итеп күзаллыйсың?*

Шунан соң хикәяләүче образы төшенчәсенә билгеләмә бирәбез.

Әдәби әсәрдә кеше образлары ике төрле: объектив, ягъни сурәтләнгән дөньяда хәрәкәт итүче, катнашучы; субъектив — бәян итүче. Субъектив образларга хикәяләүче образы да керә. Ул әдәби әсәрдә барган вакыйгалар дөньясын сурәтли.

Әдәби әсәрдә торгызылган тормыш моделен сурәтләүче, хикәяләүче — хикәяләүче образы дип атала. Ул вакыйгаларда үзе катнашса, «мин» исеменнән сөйли һәм әдәби әсәрнең герое санала. Хикәяләүче үзе күргән вакыйгаларны сурәтләгәндә, вакыйгаларга карата үзенең фикерен, хис-кичерешләрен белдерә. Аның фикер сөреше ярдәмендә хикәяләүчегә хас сыйфатларны билгеләргә мөмкин.

Фәкыйрь генә яшәгән кешеләрнең өйләрендә шәкерт моңа кадәр күрмәгән матур әхлакый сыйфатлар белән очраша. Бу гаиләдә тирән мәхәббәт, бер-берсен хөрмәт итү, ярату белән тулы нурлы күзләр хикәяләүче малайның фикерен үзгәртергә мәҗбүр итә. Ул эчке матурлыкка, күңел дөньясының гүзәллегенә басым ясый.

Күңел дөньясын, эчке матурлыкны, үзара җылы мөнәсәбәтләрне бер күрүдә тою өчен күзәтүче үзе дә нечкә, саф күңелле, шул хисләрне аңлый белүче романтик булыр-

га тиеш. «Матурлык»та хикәяләүче образ романтик, рухи кыйммәтләрне өстенрәк күрүче образ булып җитешә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта укучыларны Бәдретдиннең әнисенә булган мөнәсәбәте турында уйландырып, *Үз анасын зурлаган кеше анасын хурламас* мәкале ярдәмендә сөйләшүгә алып чыгып була.

Укучылар түбәндәге нәтиҗәгә киләләр. Әниләр ямьсез була алмый. Аларда баласы өчен янып яшәгән олы йөрәк тибә. Баласына изгелек теләгән ана, башкаларга начарлык тели алмый. Һәр ананың күңеле яхшылыкта, изгелектә. Шуңа күрә дә әниләрнең тышкы матурлыгы түгел, күңел матурлыгы бик мөһим. Бәдретдиннең әнисе никадәр ямьсез йөзле булса да, малай аннан оялмый, ул әнисен ярата, хөрмәт итә, ул яраткан көйне уйный, дусларына чәйне үзе ясап бирүен үтенә. Бу бала белән ана арасындагы олы мәхәббәт турында сөйли. Үз әнисенә хөрмәт белән караган бала башкаларга да хөрмәт белән карар. Бу — ана тәрбиясеннән килә торган әхлакый кыйммәтләр.

Күңел матурлыгы темасын үзәккә куеп та әңгәмә үткәрергә мөмкин. Укучылар бу сөйләшү барышында кешенең күңеле матур булмаса, бернинди матурлыкның да (хәтта тышкы матурлыкның да) аны бизәмәвен аңларга тиешләр. Күңел матурлыгы — ул кешенең эчке дөньясы, уй-фикерләре, хисләренең матурлыгы. Күңел матурлыгы — күңелебезнең көзгесе ул, тыштан ул һәрчак күренеп тора. Шуңа күрә күңелебез һәрчак саф, пакь булырга тиеш. Кешеләргә яхшы мөгамәлләдә булып, ачык йөз белән, елмаеп карарга өйрәнергә, матур уйлар белән яшәргә кирәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә. Татар мәктәпләрендә укучыларга кеше күңеленең матурлыгы яки Бәдретдиннең күңел матурлыгы турында уйланып, зур булмаган инша язып килергә кушып була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Намусыңны яшьтән үк сакла (Марсель Галиев. «Җиңәсем килде»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — намуссызлык, гаделсезлек, хәрәмләшү төшенчәләренең асылын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Галиевнең «Җиңәсем килде» хикәясенең эчтәлеген аңлау, темасын һәм төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 87—94.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.
2. Теманы өйрәнүгә юнәлеш бирү максаты белән, *Хәйләле эштә хәер юк* мәкаленә нигезләнеп, әңгәмә үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын, максатын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгән күңел матурлыгы төшенчәсе турында сөйләшүне М. Галиевнең «Җиңәсем килде» хикәясен өйрәнү барышында дәвам итәбез.

Дәреслектә әсәр тексты буенча урнаштырылган сорау-биремнәр аны анализлаганда ярдәмгә киләчәк. Укучылар

анализ барышында беркайчан да, беркайда да хәйлә белән җиңеп булмый, дигән фикерне аңларга тиешләр.

М. Галиев Илгизнең парктагы абый белән уены турында язып, җәмгыятьтәге намуссызлык, гаделсезлек, хәрәмләшү, башкалар хисабына җиңүгә ирешергә омтылу кебек күренешләрне кире кага.

Илгиз парктагы абыйны җиңсә дә, бу җиңү аны шатландырмый, чөнки хәрәмләшеп ирешкән уңыш җанына тынычлык бирми. Язучының бу хикәя белән нинди генә хәлдә дә гадел, намуслы булып кала белергә кирәк, дигән фикерне әйтәсе килә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Иредә хәрәмләшү, гаделсезлек турында башлангыч сыйныфларда укылган әсәрләрне искә төшерү урынлы булачак.

М. Галиевнең «Җиңәсем килде» хикәясендә Илгиз үзенең кечкенә буйлы булуыннан уңайсызлана. Аның тизрәк зур үсәсе килә. Шул ук вакытта ул зур уңышларга ирешкән малай итеп тә сурәтләнә. Паркта шахмат уйнап, тормыш сабагы да ала, үзе өчен киләчәккә максат билгели: парктагы абыйны җиңгәнче уйнарга! Укучыларны шушы фикер турында уйландырып, әңгәмә үткәрә алабыз. Сөйләшү барышында укучылар кеше буйга түгел, шәхес буларак үсәргә тиеш, дигән нәтиҗәгә килергә тиешләр. Фикерне дәвам итеп, *Син озын буйлы буласы килгән Илгизгә нинди киңәш бирер идең?* дигән сорау бирә алабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, сорауларга җавап бирергә.

Шулай ук укучыларны түбәндәге сораулар ярдәмендә уйландырып, зур булмаган инша язарга тәкъдим итеп була: *Марсель Галиев үзенең «Җиңәсем килде» хикәясендә Илгизнең шахмат таҗы кигән чемпион булырга хыялланулы турында яза. Ул кайсы очракта максатына ирешә алачак? Авторның бу турыда укучыга җиткерәсе килгән фикере ничек яңгырар? Син шахмат чемпионы буласы килгән Илгизгә нинди киңәш бирер идең?*

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Мәңгелек агышында Чишмә һәм Умырзая (Ринат Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестенда образлар системасы);

Туган җирдә яшәү — зур бәхет (Ринат Мөхәммәдиев. «Беренче умырзая»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган җир, туган туфрак төшенчәләренең асылына төшенү, экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестеның эчтәлеген, образлар аша повестьның идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 95—118.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. «Ни өчен кеше туган җирен сагына?» темасына сөйләшү үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын, максатын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестен өйрәнүгә каралган 2 сәгать повесть жанрында образлылыкны өйрәнүгә юнәлдерелгән. Укучылар повестьтагы образлар, персонажлар белән бәйле вакыйгалар нигезендә теманы билгелиләр. Образлар аша повестьның идеясен аңлауга ирешәләр. Әсәрдәге образлар, вакыйгалар ярдәмендә повестьта күтәрелгән проблемаларны күрсәтәләр. Әлеге белемнәре нигезендә мөстәкыйль рәвештә әсәрдәге проблема төшенчәсенә билгеләмә бирә алалар. Мөстәкыйль рәвештә әсәрнең проблемасын табуга ирешәләр. Укылган повесть нигезендә бирелгән темага инша яза һәм сыйныфташларының иҗатын бәяләчәкләр. Повестьта күтәрелгән проблемага мөнәсәбәтле үз фикерләрен әйтә һәм дәлилли, сыйныфташларыныкына үз мөнәсәбәтләрен белдерә алалар.

Иң элек, повестьтагы образлылыкны тикшерү өчен, бу жанрга кыскача аңлатма биреп китәбез. Повесть — хикәя белән чагыштырганда күләмле жанр. Шуңа анда образлар да күбрәк, сурәтләнгән вакыйгалар да, идея һәм проблема да катлаулырак. Әмма төп идея аларны бергә туплап, бер ноктага җыя. Әсәрнең идеясен табу өчен, андагы вакыйгалар белән танышырга кирәк.

Әсәрдә төп урынны алып торган ике вакыйга бар: беренчесе — Чегән чишмәсенә мөнәсәбәтле, икенчесе беренче умырзаялар белән бәйле. Төп вакыйга башкаларын үз янына туплый.

Чишмә янына чегәннәр еш килгәнгә, ул Чегән чишмәсе дип аталган. Табигатьнең бик матур урынына урнашканга авылны халык Нурлы Алан дип атаган.

Төхфәт карт: «Безнең нәсел тамырында Чегән чишмәсенең шифасы йөгерә», — ди, чөнки аның әтисе Айтуган һәм әнисе Гөлйөзем ул туганчы ук бик яшьли авырып китәләр. Яшәүдән өметләре өзелергә торганда, алар авылындагы чишмә тугаена чегәннәр килеп туктый. Айтуган, язмышын белергә теләп, алар янына бара. Карт чегән аңа әлеге чишмә

суын эчәргә куша. «Нурлы Аланда жить и умирать — стыдно», — ди ул. Чишмә суын эчә башлагач, алар сәламәтләнеп китә. Шуннан аларның алтынчы балалары Төхфәт туа. Чишмә Төхфәтнең әти-әнисенең гомерен озайткан, аларның нәсел дәвамчысы Төхфәткә тормыш бүләк иткән. Төхфәтнең авызына капкан тәүге су тамчысы Чегән чишмәсе суы була.

Бабасының чишмә суы турындагы сүзләрен ишеткәч, Рәхимҗан чишмә суын алып кайта. Кич түгәрәк табын артында гаилә белән чәй эчәләр. Һәркемнең йөзендә елмаю, канәгатьлек сизелә. Суны, чишмәдән су алып кайткан Рәхимҗанны мактыйлар. Уллары Рәхимҗанның бабасы күңелен бер сүздән аңлавын күреп, өлкәннәр канәгатьләнү кичерәләр.

Рәхимҗанга бабасы авыл чишмәләре турында сөйли. Аның сүзләре Рәхимҗанның күңелендә зур үзгәрешләр тудыра. «Юк, ю-ук, чишмәләр турында гына сөйләми иде, ахры, бабасы», — дигән уй үтә аның күңеленнән. Бабасы туган җирнең тарихын, кадерен белү кирәклеге турында сөйли.

Төхфәт картның сүзләрендә туган җирнең иң изге җир икәнлеген аңлатырга теләү, аны зурлау, мактау һәм аның белән горурлану сизелеп тора. Ә Фаязның күңеле шәһәргә ашкына. Ул әле яшьлеге белән тормышны матди байлык, киенү рәвеше, шәһәрчәлек белән бәйләп күзаллый. Бу — Төхфәт һәм Фаязның фикерләвендәге төрлелек кенә түгел, өлкән буын һәм яшьләр арасындагы каршылык та.

Төхфәт карт та, чегән дә кеше дөньяга килгән, беренче сулышын алган, авызына тәүге тапкыр су капкан урынны туган җир дип күзаллыйлар. Туган җир — иң изге җир. Кешенең аны онытырга хакы юк, дигән фикердә торалар.

«Беренче умырзая» повестенда бөтен вакыйгаларны берләштереп торган төп тема — кешеләрнең туган җиргә мөнәсәбәте.

Повестьта чишмә образы белән бәйле урыннарда аның шифалы, кешеләргә батырлык, матурлык бирүче, көчле (аны кар да басып китә алмый, ул үз юлын дәвам итә), үткәннәр һәм бүгенгенең шаһиты, кешеләрнең яшерен теләкләрен, күңел хисләрен уртаклашучы сердәше булуы кебек үзенчәлекләре әйтелә.

Чишмә әсәрдә саф су чыганагы, яшәү чыганагы булып аңлашыла. Чишмә кирегә акмаган кебек, узган тормыш та да кире кайтмый. Шушы сыйфатларына нигезләнеп, автор чишмәне тормыш, яшәешкә метафора буларак куллана.

Рәхимҗан урманга сыйныфташлары белән беренче умырзая чәчәкләрен эзләп бара. Алар чәчәкләрне бер-бер артлы, күңелләреннән генә үзләренең иң зур теләкләрен әйтеп өзәләр. Беренче умырзаяны өзгәндә телләгән теләкнең кабул булуына ышанып, һәркем умырзая өзгәндә теләк тели. Әмма аны сер итеп саклый. Рәхимҗан, Фаяз, Фаягөл һәм Зәйнәп эчтән генә үз теләкләрен әйтәләр. Чегән чишмәсе буенда умырзаяларны язгы ташуга агызалар.

Язның беренче чәчәге умырзая образы белән Рәхимҗан һәм аның дусларының зур тормыш юлына аяк баскандагы беренче хисләре, беренче теләкләре арасында параллель уздырылган.

Беренче теләкләрнең шаһиты булган умырзаяларны язгы ташу вакытында Чегән чишмәсе янында агызу Рәхимҗан һәм аның дусларының язгы ташкын кебек олы тормышка килеп кушылуларын аңлата.

Әсәрдә чишмә — тормышка, умырзаялар Рәхимҗан һәм аның дусларының теләкләренә метафора буларак бирелгән. Умырзаялар туган җир туфрагында бөреләнә, Рәхимҗаннар аны чишмә янында ташуга агыза. *Туган җиреннән аерылган хыялларның язмышы нинди? Алар тормышка ашамы?* Әсәрдәге геройлар язмышы белән дәлилләп бир, дигән биремне үтәгәндә, укучылар туган җирдән аерылган хыяллар да тормышка ашмый, Фаягөл укырга керә алмый, Рәхимҗан белән Зәйнәпнең дә юллары аерыла, Фаязның да хыяллары җимерелә, дип билгелиләр.

*Бабасы Төхфәт Рәхимҗанның күңелендә туган җиргә мәхәббәт чаткысын ничек кабыза? Автор туган җиргә мәхәббәт гаиләдә тәрбияләнергә тиеш дигән фикердә тора, дип нәтиҗә ясау дөрес булырмы*? дигән сораулар бирәбез. Укучылардан түбәндәге җавап көтелә: «Бабасы Рәхимҗанны гаилә, туган җир тарихы белән таныштыра. Туган җирнең байлыгын, матурлыгын күрергә, кадерен белергә өйрәтә. Автор туган җиргә мәхәббәт орлыклары гаиләдә салынырга

тиеш, дип нәтиҗә ясый. Рәхимҗан бу тәрбияне бабасыннан алды. Туган җиргә мәхәббәт — буыннан буынга тапшырыла торган изге хис».

Бу теманы өйрәнү барышында проблема төшенчәсен үзләштерү күздә тотыла.

Әсәрдә укучыны уйланырга этәргән сорау, хәл ителергә тиешле мәсьәлә күтәрелгән проблема була. Тема белән проблема үзара бәйләнгән. Проблеманы хәл итү язучының карашлары, әсәрнең идеясе белән дә тыгыз бәйләнештә. Күләмле әсәрләрдә (әйтик, повестьларда) берничә проблема күтәрелергә мөмкин. Әсәр проблемасы ?, !, ?!, ... (күпнокталар) белән бирелгән җөмләләр ярдәменә ачыктан-ачык күренеп торырга да, әсәрдәге вакыйгалар эченә яшерелгән булырга да мөмкин булуын аңлатабыз.

Шуннан соң конкрет мисалда проблеманы таптырабыз:

*Бабасы сөйләгәннәрдән рухланып китеп, беркөн Рәхимҗан әйтеп салды:*

*— Нигә мәктәптә туган авыл тарихын укытмыйлар икән?... Син сөйләгәннәрне, бабай, күпләрнең ишеткәне дә юк бит, — диде.*

*— Бервакыт безнең Нурлы Аланның да тарихын өйрәнерләр әле: Болгар чорыннан ук килгән зур тарихы булган аның. Кайчандыр шактый ук билгеле шәһәр-крепость булган бит ул. Нурлы Алан-Кирмән дип тә йөрткәннәр аны, — диде бабасы.*

*Рәхимҗанның бабасы Төхфәт белән сөйләшүенән нинди проблема аңлашыла?* Укучылар мәктәпләрдә туган җир тарихын өйрәнүгә игътибар җитмәү проблемасын күрсәтергә тиеш булалар.

Алга таба укучылар белән бергә «Беренче умырзая» повестенда күтәрелгән проблемаларны ачыклыйбыз. Алар — буыннар арасындагы бәйләнешне саклау; кешеләрнең туган җиргә карата битарафлыгы; яшь буынның туган җир кадерен, аның тарихын белергә тиешлеге.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Проблема төшенчәсе белән эшләүне дәвам итеп, түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә була:

Өзекне укыгыз. *Рәхимҗанның күңел кичерешләре аша автор нинди проблема күтәрә? Шул хакта сыйныфта фикер алышыгыз.*

*Озын улак буйлап инешкә таба су йөгерә. Вак ташлар аша сикереп-уйнап йөгерә, нәни дулкыннар таратып челтери чишмә. Кая ашыга, кая шулай ашкына икән ул... Рәхимҗан төшкәнче дә шулай аккан, тимер кисмәкне тутыргач та шулай агачак. Ул туганчы ук шулай уйнаклап аккандыр чишмә, әтисе туганчы, бабасы туганчы да... Кайчаннан бирле ага икән ул шулай? Киләчәктә дә аның сулары берөзлексез сәфәрдә булырмы...*

Шул чишмәгә төшә торган юлның беркемгә дә кирәге калмавы, аның онытылуы проблемасы күтәрелә. Рәхимҗан чишмә турында уйлана. Әмма ул чишмә агышы гына түгел, тормыш агышы, үткән һәм бүгенге аша киләчәккә тоташу турында уйлану буларак кабул ителә.

Әсәрдә Рәхимҗан язмышын авыл белән бәйли. Бабасының эшен дәвам итә. Бу — проблеманың ничек хәл ителүен аңлата? Бу — буыннар арасындагы бәйләнешнең өзелмәвен, туган җир кадерен аңлаган яшь буынның барлыгын аңлата.

Шулай ук бу этапта түбәндәге өзекне укытып, әңгәмә үткәрә алабыз.

*Төхфәт бабайның күңеле нечкәреп куйды. Ләкин ул моны Рәхимҗанга сиздерергә теләми иде. — Кешеләрнең йөрәге мүкләнүдән генә куркырга кирәк, башкасы куркыныч түгел, һәммәсенә дә чират җитәр, улым. Җитәр! Йөрәге мүкләнгәннәр кулына калдырасы килми шул авылны. Саклыйсы иде аны, тамыры нык әле аның... Тамыры нык!*

*«Йөрәге мүкләнү» дигән гыйбарәне ничек аңлыйсың?* Укучылар аны тормышка битарафлык белән бәйләп сөйлиләр.

Дәрестә укучыларда патриотизм хисен тәрбияләү максатыннан, Туган илгә — Россиягә соклану, аны ярату, аның белән горурлану, сугышта һәлак булган батырларны искә алуны оештырып була. Укучылар Төхфәт картның һәр сүзендә тирән мәгънә ятуын аңларга тиешләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә. «Беренче умырзая» әсәре герое Рәхимҗанга үз киңәшләреңне язарга, әсәр эчтәлегенә нигезләнеп, рәсем ясарга кушып була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Батырлык кечкенә булмый (Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы. Муса Җәлил. «Сандугач һәм чишмә»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — батырлык, дустыңа тугрылык, теләктәшлек хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасының эчтәлеген аңлау, темасын һәм төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 119—124.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.
2. *Батыр ярасыз булмас*, дигән татар халык мәкале нигезендә әңгәмә үткәреп, теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын, максатын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә башта лиро-эпик жанрлар һәм баллада турында төшенчә бирергә кирәк. Укучылар балладаның лирик һәм эпик башлангычлар бергә кушылу нигезендә барлыкка килгән, төгәл сюжетка ия, хисси як та көчле жанр булуын аңлыйлар.

М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасында да вакыйга бар. Ул хикәя формасында сөйләнә. Геройларның эш-гамәлләре тасвирлана. Шул ук вакытта хис-кичерешләр дә урын алган.

Нәни генә сайрар кош, үзен аямыйча, илне саклаучы батырны коткарып кала. Дошман Чишмәне агулый. Әсәрдә Сандугачның үлеме дә табигать һәм илнең, шул исәптән кешенең исән-имин яшәвен тәэмин итә. Сандугач Туган ил азатлыгы, табигать матурлыгы өчен көрәштә үзен корбан итә.

Балладада Чишмә һәм Сандугач образларына мәгънә салынган. Чишмә — туган ил, елан — дошман, Сандугач — кыз образы.

Дошман агулап киткән Чишмә үзенең каралган суы өчен түгел, ә суын эчеп агуланачак ил батырын уйлап хәсрәтләнә; сюжет кискен һәм хәрәкәтчән; халык авыз иҗатыннан килгән Сандугач һәм Чишмә җанландырыла, ягъни кешеләр кебек уйлый, сөйләшә, аңлый, ярата, сөя белә; Батырның гадәттән тыш батырлыгы һәм Сандугачның фаҗигалы үлеме тасвирлана.

Сандугач һәм Чишмә образларын тикшергәндә, аларга салынган мәгънәне табабыз.

Сандугач — кечкенә генә кош. Ул һәр иртәдә үзенең дусты Чишмә янына ашыга. Аның хәлен белә. Без аның кайгыртучан булуын күрәбез. Дустына авыр кайгы килгәндә дә ул югалып калмый, аңа ярдәмгә ашыга, һәм үз гомерен куркыныч астына куеп, чишмәдән су эчәргә җыенган батырны коткара. Сандугач — батыр кош. Сандугач — таң җырчысы, матурлык, нәзакәтлек билгесе, сөю, мәхәббәткә тугрылыклы җанлы табигать иясе.

Чишмә табигатьнең иң матур җиреннән ага. Һәр иртәдә дусты Сандугач аның саф суында коена. Ул характер сыйфаты ягыннан Сандугачтан көчсезрәк. Чишмә — җансыз табигать вәкиле, сафлык, чисталык билгесе.

Чишмә сусаганнарны су белән сыйлый, батырларның яраларын юа. Сандугач һәм Чишмә — икесе дә халык авыз иҗатыннан алынган образлар.

Табигать һәм кеше бер-берсе белән гармониядә яшәргә тиеш. Кеше табигатьсез, табигать кешесез яши алмый, чөнки табигать кешене дөньяга яраткан. Табигатькә зыян килә икән, монда, һичшиксез, кешенең дә гаебе зур. Әсәрдә ил дошманының Чишмәне агулавын күрәбез. Сандугачның үлеме дә табигать һәм илнең, шул исәптән кешенең исән-имин яшәвен тәэмин итә, ягъни Сандугач туган ил азатлыгы, табигатьнең матурлыгы өчен көрәштә үзен корбан итә. Патриотизм хисе югары ноктага җиткерелә.

Әсәрдәге төп фикер — туган ил өчен гомереңне дә кызганмау.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта әсәр белән автор язмышы арасында параллельләр үткәрергә мөмкин. М. Җәлилне без башкаларны көрәшкә әйдәүче буларак беләбез. Ул да әсәрдәге сугышчы егет кебек яралана, дошман кулына эләгә, әмма югалып калмый, әсирлектә дә дошманнарга каршы көрәшен дәвам итә. Сугышчы егет агуланган чишмәдән су эчкәндә, Сандугач, аны коткарып калу өчен, үзенең гомерен дә кызганмый. Моны күргән егет, нәфрәтләнеп, дошманга каршы көрәшкә күтәрелә. Чын патриотларча ул үзен аямыйча сугышуын дәвам итә. М. Җәлил дә — патриот шагыйрь, чөнки ул Туган илен ярата, аның өчен гомерен дә бирергә әзер була.

М. Җәлилнең 5 нче сыйныфта өйрәнелгән «Кызыл ромашка» шигырен искә төшереп, охшашлыклар табарга кушып була. «Кызыл ромашка» шигырендә дә, «Сандугач һәм Чишмә» балладасында да герой яраланган килеш сугышка китә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Сәхнә — тормышның көзгесе (Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре. Галиәсгар Камал. «Беренче театр»);

Биби көләме, көлдерәме? (Көлкеле образлар тудыру алымнары. Галиәсгар Камалның «Беренче театр» комедиясе);

Яңалык каршылык тудыра (Галиәсгар Камалның «Беренче театр» комедиясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — театрга мәхәббәт хисе уяну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позициясен, фикерен дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Камалның «Беренче театр» комедиясенең эчтәлеген аңлау, идея-проблематикасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 125—149.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.
2. *Искелек белән яңалык көрәшендә нинди ысуллар кулланып була?* темасына әңгәмә үткәрергә мөмкин. Бу вакыт-

та укучыларда алда өйрәнеләчәк әсәр белән бәйле күзаллау булдырылачак.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын, максатын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Драма әсәрләрендә образлар системасына хас үзенчәлекләре» темасы астында каралган дәресләр Г. Камал әсәрендәге образларны, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, юморның функциясен өйрәнүгә юнәлтелгән. Укучылар драманың эчтәлегенә нигезләнеп, XX гасыр башында татар халкына хас яшәеш картинасының бирелешен, милләтнең үсешенә комачаулаган факторларның чагылышын билгелиләр, драматург кулланган юморның милләт тормышын сурәтләүдә иң кулай ысул булуын күрәләр. Әдәбият теориясе буенча проблема, характер, тип төшенчәләрен аерырга өйрәнәләр. Комедия жанры, тәнкыйди реализм методы турында төшенчә алалар. Нәтиҗәдә, Галиәсгар Камалның «Беренче театр» комедиясе буенча мизансцена, әсәрнең өзеген сәхнәләштерү эшләре тәкъдим ителәчәк.

Г. Камалның «Беренче театр» комедиясендә шәһәрдә беренче татарча спектакль куелган вакыт тасвирлана. Хәмзә бай спектакльне куйдырмаска йөри. Аның гаилә әгъзалары исә театрга барырга җыеналар. Вәли гаиләсендә, театрга бармас өчен, Гафифә күлмәк сайлаган була, Хәбибрахман гаиләсендә акча җитмәүне сәбәп итәләр. Театрга барырга һәр гаилә үзенчә әзерләнә. Әсәрдә гаиләдәге билгеле бер кешеләр тәнкыйтьләнә.

Хәмзә бай кияве Вәлинең театрга бик тә барасы килә, ул театрга билетлар да алып куйган. Киенеп-ясанып хатынының әзерләнгәнен көтә. Хатыны Гафифә театрга барырга курка. Ул кияргә матур күлмәгем юк, дигән сәбәп табып, театрга бармыйча калырга уйлый. Ләкин Вәли бик каты тора. Гафифә театрга өстендәге күлмәген киеп китә. Яшьләр барыбер Хәмзә байдан шүрлиләр, шуңа күрә Бибигә «кодаларга киттеләр» дип әйтергә кушалар.

Факиһә Вәли җизниләре нишли, шуны кабатларга ярата. Вәлиләрнең театрга киткәнлеген белгәч, ул да тиз генә театрга барырга карар кыла. Факиһә Хәмзә байдан курыкмый.

Хәбибрахман исә театрның нәрсә икәнен аңларга да теләми. Хатыны оялткач кына барырга була. Ул әтисеннән курка. Беренче өлештә Гафифәнең күлмәк сайлавы бездә елмаю тудырса, бу өлештә Хәбибрахманның аңгыралыгы, хатыныннан, әтисеннән куркуы, тиенләп акча санавы, күсе күрдем дип, балалар кебек диван артына качуы көлкеле ситуация барлыкка китерә.

Комедиядә без Хәмзә бай приказчигы Фатих белән очрашабыз. Ул үзенең халәтеннән бер дә канәгать түгел. Хәмзә байның өйдәме, юкмы икәнен тикшерергә кергән Фатих, Биби белән шаярып сөйләшә. Биби белән «эләгешеп» ала. Биби аңа Коръән укучы шәкертнең дә театрга киткәнен әйтә. Фатихның да театрга барасы килгәне сизелә. Хәмзә бай өйдә булмагач, ул тиз генә чыгып китә.

Балалары, хезмәтчесе — барысы да театрга киткәч, Хәмзә бай кайтып керә. Шәһәр буенча театр куйдыртмаска йөргән Хәмзә бай, гаилә әгъзаларының театрга китүен белгәч, бөтен ачуын Бибидән ала. Биби дә аптырап калмый, Хәмзә байга башта Фатихның, аннары балаларының театрга җыенып китүләрен әйтә. Хәмзә бай битен дә юмыйча, балаларын алып кайту теләге белән, театр куелган урынга чыгып йөгерә.

Укучыларга *Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәренең юморга нигезләнгән булуын дәлилләгез. Әсәрдә көлке чыганагы нәрсәдә?* дигән бирем һәм сорау тәкъдим итәбез.

Әсәрдә вакыйгалар кабатланып килә. Юмор ярдәмендә автор татар тормышындагы тискәре күренешләрне тәнкыйтьли, алардан көлә. Персонажларның сөйләмендә кызыклы гыйбарәләр куллана: киезката — кислота, театрга — төятергә. Автор комедия жанрында гына эчке мәгънәне тулы ачып бирә торган тормыш материалына юлыга. Җәмгыятьтә алдынгы карашлар таралган бер чорда, искелеккә ябышып яту — үзе үк көлке чыганагы. Г. Камал комедия чараларын оста кулланып, үткен, ачы итеп көлү аша үз хөкемен чыгара. Шуңа күрә Г. Камалның «Беренче театр» әсәрен комедия дип атый алабыз.

Әлеге әсәрне өйрәнү барышында укучылар характер, тип төшенчәләрен үзләштерергә тиеш булалар. Г. Камалның «Бе-

ренче театр» әсәрендә образлар күп. Ләкин алар характер дәрәҗәсенә үк күтәрелмәгәннәр.

Характер — аерып торучы билге, сыйфат төшенчәсе. Эш-гамәлләрендә һәм сөйләмендә ниндилеге күренеп, башкалардан аерылып торган геройлар характер дип атала, ягъни шәхси сыйфатлары көчле, истә калырлык персонажга характер дип әйтәләр.

Әдәбиятта чагылыш тапкан иҗтимагый-тарихи һәм милли тормыш-көнкүреш рәвеше аерым бер чорларга хас типлар, типик образлар туугa сәбәп була. Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбияты — укымышлы, зыялы мулла; надан, кара мулла; надан шәкерт; русча укыган һәм әхлаклы яшь егет яки кыз типларын бирде. XX гасыр башы әдәбиятында милләтпәрвәр, доносчы, тоткын, кечкенә кеше һ. б. типлар алга чыга.

Әсәрнең һәр образына характеристика биргәндә, аның характер дип аталган персонажга туры килү-килмәвен ачыклыйбыз.

*Вәли гаиләдә нинди? Ни өчен вакыйгалар Вәли сүзләре белән башланып китә? Ни өчен ул үзен мужик дип атый? Ни сәбәпле ул Хәмзә байдан курыкмый? Вәли хатынына карата нинди мөнәсәбәттә?* кебек сораулар Вәли образын характерларга да, аның характер дәрәҗәсенә күтәрелгән персонаж булуын аңларга да ярдәм итә.

Вәли гади гаиләдә үскән. Ул — үзе әйтмешли, мужик. Бабасы белән сука сукалап үскән. Атасы 12 яшендә калага килгән. Алдынгы карашлы, укымышлы, кызыксынучан, дөньяда нинди вакыйгалар барлыгын белеп тора. Театр беренче тапкыр куела, шуңа күрә дә барасы килә, билетларны да алдан алып куйган. Вакыйгаларның Вәли сүзләре белән башлануы, аның Хәмзә байга каршы килергә сәләтле кешеләрнең берсе булуы белән аңлатыла. Шат күңелле, әйбәт кеше. Вәли Хәмзә бай тәрбиясе алмаган, шуңа күрә аннан курыкмый.

*Вәлинең хатыны Гафифәне характер дип атап буламы? Гафифәгә нинди сыйфатлар хас? Ул акыллы хатынмы? Әтисенең иркә кызы ни өчен аннан курка?* сораулары Гафифәгә характеристика биргәндә ярдәмгә килә.

Гафифә — Хәмзә байның кызы. Әтисе аңа карата кырыс булган, шуңа күрә ул аннан курка. Беренче карашка, куркак, иркә, күлмәк сайлаучан, кыланчык яшь хатын булып күз алдына килеп баса. Ире Вәли аңа нинди күлмәк кирәк икәнен дә белә. Ал, кызыл, яшел күлмәкләр ярамый. Вәлигә тыйнаграк төс, фасон ошый. Гафифә — үз кадерен төшермичә, үз дигәненә үз чаралары белән җайлаша торган акыллы татар хатыны. Ире алдында күлмәк сайлавы — яратып кигән күлмәген өстендә калдыру өчен көрәш алымы. Гафифә — тормыш итү җаен тапкан, иренең сүзен тыңлый торган, акыллы, сабыр татар хатыны.

Укучылар Гафифәне характер дип атап булмый, ул башкалардан әллә ни аерылып тормый, чөнки шул заман хатын-кызларына хас күп кенә сыйфатларга ия, аны башка кешеләрдән аерып торган сыйфаты да юк, дигән нәтиҗәгә киләләр.

Г. Камалның «Беренче театр» комедиясендә Хәбибрахман гаиләсе дә үзенчәлекле. Хәбибрахман — уңышлы кулланылган образ. Бу образ аша автор тормышта мондый кешеләр күп булса, алга китеш булмаячагын әйтеп, укучыны кисәтә. *Ни өчен шундый үткен Хәмзә байның улы үзен шулай тота? Хәбибрахманның үз фикере бармы? Хәбибрахман бәхетлеме?* дип, Хәбибрахманны характерларга кушабыз.

Хәбибрахман — Хәмзә бай улы, бераз томана, үз-үзен дә яклый алмый, әкрен холыклы, беркатлы. Театрга бармас өчен, хәйләләп, диван артына качып калмакчы була. Әтисеннән дә, хатыныннан да бик курка. Шул ук вакытта ул шук, җае чыкканда шаярып алырга да тартынмый. Аның театрга барырга теләмәве — тискәре, үз сүзен сүз итәргә яратучы кеше булып күренергә омтылуында. Хәбибрахман тормыш мәшәкатьләреннән читтәрәк торырга ярата. Бу очракта рольләр алмашынган: активлык, инициатива хатын-кыз кулына күчкән. Аның аңгырарак булып күренүе, әтисе тәрбиясендә үсеп, яңалыкларның тормышта кирәклеген аңлап бетермәве белән аңлатыла. Хәбибрахман — иске тормыш кагыйдәләренә ябышып яткан надан, караңгы, кырыс Хәмзә бай тәрбияләгән кеше. Автор бу образ аша Хәмзә бай кебек кешеләрнең акыллы, фикерле балалар тәрбияли алмавын ассызыкларга тели.

Әсәрдә Хәбибрахманның хатыны Факиһә — үрнәк алырлык образ. Ул акыллы, үз сүзен сүз итә торган яңа татар хатыны.

Укучыларга бу образны характерлаган вакытта түбәндәге сорау-биремнәрне тәкъдим итәбез: *Факиһә образында татар хатын-кызларына хас булмаган сыйфатларны ачыкла. Факиһә ни өчен Хәмзә байдан курыкмый? Факиһә ирен ярата-мы? Факиһәдә безне нәрсә сокландыра?*

Факиһә — Хәбибрахманның хатыны. Ул тәрбияләнгән гаилә турында бернәрсә дә билгеле түгел. Ул турыда язылмаса да, Факиһәне алдынгы карашлы гаиләдә үскән дип әйтергә була. Ул кыю, хөр табигатьле, яңалыкны кабул итәргә әзер. Хәмзә байдан да курыкмый. Ирен театрга барырга кыстый, тегесенең теләге булмаса да, Факиһә үзенекен эшли: аны барыбер алып китә. Факиһә тупас кыланмый. Ул ирен үгетләп, ялварып күндерә. Башка хатын-кызлардан аермалы буларак, ул үткен, иренә әйтәсе сүзен әйтә, яңалыкка омтыла, тормышта оста итеп, хәйләкәрлек белән үз дигәненә ирешә белә. Аның кыюлыгы, тәвәккәллеге, үз теләгенә ирешә алуы сокландыра.

Әдәбиятта чагылыш тапкан иҗтимагый-тарихи һәм милли тормыш-көнкүреш рәвеше аерым бер чорларга хас типлар, типик образлар туууга сәбәп була. Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбияты — укымышлы, зыялы мулла; надан, кара мулла; надан шәкерт; русча укыган һәм әхлаклы яшь егет яки кыз типларын бирде. XX гасыр башы әдәбиятында милләтпәрвәр, доносчы, тоткын, кечкенә кеше һ. б. типлар алга чыга.

Г. Камал комедиясенең герое Хәмзә бай — шул чор кешеләренең уңай һәм тискәре сыйфатларын үзенә җыйган образ. Г. Камал безнең алга шул заманның типик кешесен китереп бастыра.

Укучылар типның аерым бер төркем кешеләргә хас мәгълүм сыйфатларны үзенә туплаган герой булуын аңларга тиешләр.

Хәмзә байның прототибы бар. Ул — Г. Камалның каенатасы (хатынының әтисе). Хәмзә бай — иске фикерле Казан бае. Өйдә үзен хуҗа итеп тота. Бөтен кешене орыша, чама-

дан тыш холыксыз, берәү белән дә исәпләшми. Театрны булдырмас өчен шәһәр буйлап йөргән Хәмзә соңга кала: «Куймагыз, рөхсәт юк!» дип тавыш куптаруы файдасыз, спектакльгә инде рөхсәт бирелгән; өйдәгеләрне театрга барудан туктатырга да соңга калган, ул кайтып кергәнче үк чыгып китеп өлгергәннәр. Хәтта ул үзе дә: «Барам да якаларыннан өстерәп алып кайтам», — дип чыгып китә. Хәмзә бай хакимлекне югалтуын сизә. Хәзер аңа берсенең дә исе китми: кибетчеләрнең дә, чәч алучының да, үз гаилә әгъзаларының да. Әнә шулар байның кәефен кыра. Ул — конкрет чаралар күрергә күнеккән эшлекле кеше.

Г. Камалның «Беренче театр» әсәрендәге Биби — бик кызыклы образ. Ул катнашучыларның барысын җыеп тора, чөнки алар барысы да аның белән мөнәсәбәткә керәләр: сөйләшәләр, ачуланышалар.

Сәхнәдә Хәмзә байның аралашкан бердәнбер кешесе — Биби. Ул — Хәмзә байның асравы, аңгыра, әмма үз кирәгенә хәйләкәр, астыртын һәм кыю кыз. Аның портретын Вәли үзенең монологында бер җөмлә белән бирә: ...*Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче кичәсе төсле кап-кара.* Бибигә кайбер иркенлекләр дә бирелгән, ул, урынлы-урынсыз ачуын китерсәләр, үч ала белә. Биби башкаларга караганда акыллырак та, зирәгрәк тә. Кирәк булганда, курыкмыйча үз фикерен әйтә белә. Кыскасы, ул — «акыллы юләр». Үзен кимсеттерә торган мескеннәрдән түгел.

Фатих — Хәмзә байның кибетчесе, бик шаян егет. Бибидән өйдәгеләрнең театрга киткәнен белеп алгач, ул да тамаша карарга китә. Хәмзә байдан курыкмавы күренеп тора. Фатих безнең күз алдына яңалыкка омтылырга теләге булган өйләнмәгән егет булып килеп баса.

«Беренче театр» әсәрендә төп каршылык: искелек белән яңалык арасындагы тартыш. Каршылыкның бер ягында — театр куйдыртмаска йөрүче Хәмзә бай, икенче ягында балалары, якыннары. Каршылыкның төп сәбәбе — беренче театр куелу. Бу каршылык Хәмзә бай гаиләсендәге кешеләрнең бер-берсен аңламауларын күрсәтә. Комедиядә искелек яклы кешеләр тәнкыйтьләнә.

Әсәрдә яшьләр белән картлар, икенче төрле әйтсәк, ата белән бала арасындагы проблема турында сөйләнә. Яшьләр яңалык яклы, ә картлар — искелек тарафдарлары. Бу тартыш көлкеле ситуация тудыра.

Искелек һәм яңалык арасында проблема туа. Искелекне яклаучылар яңалыкка юл бирмиләр. Ә яңалыкны яклаучыларның бирешәсе килми, алар төрле юллар белән аны тормышка кертеп җибәрергә тырышалар. Искелек яклылар кызганыч.

Әсәрнең проблемасы: иске һәм яңалыкка омтылган карашларның капма-каршы килүе.

Әсәрнең төп фикере — тормыш бер урында гына тормый, яңалыкка омтыла. Кайбер кешеләргә яңалыкны кабул итү авыр, шулай булса да, алар яңалыкның кирәклеген барыбер аңлаячаклар. Нинди генә киртәләр очрамасын, яңалык һәрвакыт җиңеп чыга.

Автор әсәрдә яңалыкка омтылуның бик пассив булуын күрсәтә. Комедиядәге кайбер образлар яңалыкны кабул итәргә әзер түгел. Автор алардан көлә, тәнкыйтьли. Укучыга яңалык белән кызыксынырга, аңа омтылырга куша. Чынбарлыкны көлке аша чагылдыра. Шуңа күрә Г. Камалның «Беренче театр» әсәрен комедия дип атый алабыз.

Комедиядә көлкеле вакыйгалар тасвирлана. Ул кеше характерындагы йомшак яки кимчелекле якларны арттырып күрсәтә, тормыштагы кире сыйфатларны кискен тәнкыйтьли.

Комедия — тормыш-көнкүрештәге, аерым кешеләр характерындагы кимчелекле яклардан көлеп, конфликт һәм характерларны, вакыйга-күренешләрне һәм хәрәкәтне көлкеле, кызыклы формада сурәтләгән жанр.

Шулай ук бу әсәрне өйрәнү кысаларында тәнкыйди реализм төшенчәсен үзләштерү дә күздә тотыла. Исеменнән үк күренгәнчә, тәнкыйди реализм җәмгыятьтәге һәм кешеләр яшәешендәге чынбарлыкның уңай якларын күрсәтүдән бигрәк, төп игътибарын җәмгыятьнең караңгы, тискәре күренешләрен ачып бирүгә юнәлтә һәм шуның белән болай яшәү рәвешенең алга таба яхшыга илтмәячәген раслый. Ул аерым кешеләрдәге кимчелекләрне түгел, ә кеше бәхетенә каршы

булган иҗтимагый тәртипләрне, хәл, күренешләрне тәнкыйтьләп, аларның үзгәрергә тиешлеген сәнгать чаралары ярдәмендә күрсәтеп бирә.

Татар әдәбиятында тәнкыйди реализм дип аталган юнәлешнең формалашу вакыты 1908—1910 елларга бәйләп карала.

Тәнкыйди реализм — кешене әхлакый камиллеккә өнди, башкаларга ярдәмчел булуга чакыра, типик характерларны типик шартларга куя торган иҗат агымы. Тәнкыйди реализмның төп сыйфатлары:

— иске тәртипләрне кире кагу;

— аерым шәхесне түгел, тирәлекне, җәмгыятьтәге билгеле бер катлауларны тәнкыйтьләү;

— өч принципка нигезләнү: кеше тирәлектә яши, аның тормышы җәмгыять белән тыгыз бәйләнгән, ул — тарихи чор җимеше;

— гуманистик һәм җәмгыяви идеалларның югары күтәрелүе.

Укучыларга «Беренче театр» әсәрендә тәнкыйди реализм сыйфатларын табып, шул турыда фикер алышырга тәкъдим итеп була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бүгенге көн белән бәйләп, тормышта яңалыкка әзер һәм искелеккә каршы чыккан кешеләрнең булуы турында, бу күренешең сәбәпләрен ачыклап, әңгәмә корырга мөмкин. Укучылар хәзерге тормышта да яңалыкка каршы кешеләрнең очравын билгелиләр. Моның сәбәпләре: яңалыктагы билгесезлектән курку, тормыштагы искелекне кычкырып, кем беләндер бәхәсләшеп кенә җиңеп булмау. Соңыннан яңалыкны башта өйрәнергә кирәк, аннан соң гына аның уңай, тискәре якларын күрергә мөмкин, дип нәтиҗә ясала.

Әсәр тулысы белән укылып анализлангач, рольләргә бүлеп укырга тәкъдим итәргә була.

Г. Камалның «Беренче театр» комедиясеннән сайлап алыган өзек буенча мизансцена төзетергә, сәхнәләштерергә куша алабыз.

Соңгы дәрестә *Драма әсәрләрендә образлы дөнья сурәтләнешендә нинди үзенчәлек күзәтелә?* соравын биреп, укучы-

ларны уйландырабыз, нәтиҗә ясатабыз. Бу вакытта дәреслектә урнаштырылган материал ярдәмгә килер.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә, сорауларга җавап бирергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Нәтиҗәләр чыгару. Контроль эш.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — белемгә омтылышның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, иптәшләреңең җавапларын бәяләү, үзбәя; үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне гомумиләштереп системалаштыру.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, дәресне оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар соңгы дәрес буларак, аның кабатлау, үткәннәрне искә төшерү дәресе икәнлеген билгеле алалар.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Кабатлауны төрлечә оештырырга мөмкин. Анда һәр укучы катнашырга (димәк, сорауларның авырлары да һәм җиңелрәкләре дә булсын), дәрес формасы да кызыклы булырга тиеш. Мәсәлән, алдан карточкалар әзерләп, аларга бу бүлектә укылган әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын язып куярга була. Һәр партада утырган (төркемдә булган) укучылар бер карточканы алалар һәм бу әсәр турында белгәннәрен әйтәләр (башка төркемнәр дә өсти ала). Бу укылган әсәрләрне тиз генә искә төшерергә ярдәм итә. Шул ук алым белән аерым әсәрнең темасын, төп фикерен искә төшерергә, бирелгән өзекнең кайсы әсәрдән булуын ачыкларга һ.б. биремнәрне үтәргә була.

Дәреслектәге рәсемнәрне экранга чыгарып, аларның кайсы авторның нинди әсәреннән булуын ачыклатырга, яки укучыларга алдан ук төрле әсәрләр буенча рәсем ясарга кушып, күргәзмә оештырырга һәм алар буенча сөйләшү үткәрергә мөмкин.

Укучыларның аерым сүзләрнең мәгънәсен хәтердә калдыруларын ачыклау өчен, сорауларны да төрлечә әзерләргә була.

Биремнәр бик төрле булырга мөмкин, әмма кабатлау үтелгән материалның иң әһәмиятле өлешләрен укучының хәтеренә сеңдеререргә булышырга тиеш.

Дәреснең икенче өлешендә ел дәвамында үзләштергән белемнәр буенча контроль эш эшләтәбез.

**VI. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

## ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР ИСЕМЛЕГЕ

www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki — Дәреслекләрнең электрон формалары.

www.antat.ru/ru/tatzet — Татар теле: зур электрон туплама.

https://magrifat.antat.ru — Укытучылар, әти-әниләр һәм балалар өчен мәгълүмати ресурс.

https://photo.miras.info/№ — «Татарское визуальное наследие» сайты

www.belem.ru — Татар мәгарифе порталы.

www.balarf.ru — Интерактив мультимедия китапханәсе.

http://tatarile.tatar — «Татар иле» укучылар өчен электрон энциклопедиясе.

www.ganiev.org — Русча-татарча тавышландырылган онлайн сүзлек.

www.tatarhistory.ru — Татарстан тарихы буенча электрон атлас.

www.tatarcartoon.ru — «Татармультфильм» берләшмәсе эшләгән анимацион фильмнар җыентыгы.

Учебное издание

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна
**Абдуллина** Дилария Маратовна

РОДНАЯ (ТАТАРСКАЯ) ЛИТЕРАТУРА

**6 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования, работающих с обучающимися,
владеющими родным (татарским) языком

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы
**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**6 нчы сыйныф**

Методик әсбап
Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *А. А. Дәүләтова*
Рәссамы *Д. Л. Нәүрузова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Подписано в печать с оригинал-макета 21.08.2024
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$.